PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2016 ГЫЙНВАР № 1

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

МӘСКӘҮ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕНӘ ЫШАНАМЫ?

эш эзләп – башкалага

ЯЗМЫШНЫ ҮЗГӘРТКӘН ОЧРАШУ

ачылмаган сер булмас

ВЕНЕРА ШАКИРОВА СЫЙЛЫЙ:

чүлмәктәге гөмбә ашы

Резеда ШӘРӘФИЕВА:

«МӘХӘББӘТСЕЗ ГОМЕР – ЯШӘҮ ТҮГЕЛ УЛ!»



PRESSA.RU









ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ. ЕЛ ИР-АТЫ: ХАТЫН-КЫЗ КАРАШЫ РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕ





Бәйге Татарстан Президенты ярдәме белән уза. Конкурсны гамәлгә куючы – «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы. Конкурсның партнерлары – ТР Профсоюзлар Федерациясе, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, ТР Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле.

Зональ ярышлары февраль аенда Казанда ● Әлмәттә ● Биектауда ● Мамадышта ● Яшел Үзәндә ● Чистайда ● Чаллыда ● Түбән Камада үтә. Бәйгенең финалы Казанда Халыкара хатын-кызлар көне алдыннан узачак.

Тулырак мәгълүмат: www.syuyumbike.ru











Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Хашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Резеда Шәрәфиева

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 22.01.2016 ел.
Заказ М-95.
Тираж 6264.

Учредитель:
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU

Эльвира ҺАДИЕВА

Кышкы Казанга өмет

Бары Сез...
Мин Сезгә башкача дәшалмам!
Аерып,
Арада күпмеләп яшь калган.
Хыяллар:
Сездә бар, бар миндә – игездер.
...Күк никтер Казанга
Ак күлмәк кигезде.
Бу буран
Сөюне күмгәндә еларны?
Кисешә бер мәлдә
Елларны, юлларны?

Ә Казан – мең СҮЗСЕЗ һәм
Сезсез – ап-актан.
Бары Сез...
Барыбер яратам!



Рүзәл МӨХӘММӘТШИН

Гыйнвар

Боз каткан тәрәз.
Ак карлы урам.
Котырыпмы-котырына ачулы буран.

Җил битне ерта.
Өшегән куллар.
Һәм бу салкын мәңгелеккә кебек тоела...

Гыйнвар болытларны күктән куып,
Үз кулына ала һәммәсен.
Ә мин салкын кыштан җылы көтәм, –
Алай була ала, янәсе...

Шулкадәр салкын! –
Иреннәр ката.
Рамнардагы пыяланы суык чатната.
Арган аяклар
Февральгә атлый.
Тик әле күн куртка җанның җылысын саклый.

Гыйнвар гына тына алмый дулап,
Сызып ата көннең һәрберсен.
Ә мин һаман җылы өмет итәм,
Алай була ала, әйтерсең...

Тик үтә күрсен
Чак кына көннәр,
Һәм бу көрт-көрт суыклыкны кабат яз үбәр!

Кояш йомшарыр,
Аннан әз-әзләп
Эрер боз да күңелләрдә, бозлы тәрәз дә...

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



36
СЕРЛЕ ЧӘЧӘК
А. Юнысова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

8
КЕСӘСЕНӘ КҮРӘ ЯРДӘМЕ



12
МӘСКӘҮ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕНӘ ЫШАНАМЫ?
Г. Зыятдинова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



18
ҮТКӘННӘРДӘН БЕР КАЙТАВАЗ
Л. Пронэр



22
БЕЗНЕҢ ҺӘМ СЕЗНЕҢ ФИРҮЗӘ
Г. Хәсәншина



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



30

МИН БИТ СИНЕ ШУНДЫЙ ЯРАТАМ!
Н. Кәримова

ЯШӘЕШ 



44

ЕРАК ИКӘНЕН ДӘ БЕЛӘМ...
М. Имашев



50

ШУЛАЙ УК: 

16

БАЛАГЫЗ КИТАП ЯРАТАМЫ?
А. Сәлахетдинова

40

ӨМЕТСЕЗЛЕК – ҮЛЕМГӘ ТИҢ
М. Авзалова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



56

КОРАМА ДИП КАРАМА

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

КИЯҮГӘ ЧЫКМЫЙМ!
замана проблемасы

КАР... КАЙНАР ИКӘН.
Хикәя

«ӨЧЕГЕЗ АРАСЫННАН СИНЕ ГЕНӘ ЯРАТАМ».
Язмыш

СӘЛИМӘ+ИЛДУС.
Йолдызлы гаилә

ХАТЫНЫМНЫ УРЛАП КАЙТТЫМ.
Без һәм алар



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Яшьлегем таңында, килен булып, бусагасын атлап кергән өй өр-яңа булмаса да, кайнатам-кайнанамның күңел җылысы белән өртелеп, һәрвакыт якты һәм ямьле булды (хәзер инде төпчек энебез белән киленебез бу нигездә яңа йорт төзеделәр).

Биш бала табып үстереп, «Ана даны» медаленә лаек булган әнкәбез Мөкатдимә Гарәфетдин кызы яшь киленен үз баласы кебек каршы алып, күңелендә аның өчен дә җылы урын тапты. Ул, малайны-киленне аермыйча, һәрчак гадел булырга тырышты, яңа тормышка аяк басканда үгет-нәсыйхәтен дә дөрес итеп бирә белде. «Эшләп тапкан мал кадерле», «Иске яңаны саклый» кебек тирән мәгънәле сүзләр белән сөйләшә иде.

Кайнанам гөлләр үстерергә бик һәвәс булды. Гөлләр серен белә иде ул. Яз көне аның тәрәзә төпләрен эре-эре ал чәчәкле кыңгырау гөлләр бизи, ә ак, шәмәхә чәчәкле миләүшәләре ел буе күзне иркәли иде. Бу гөлләр арасында син дә үзеңне оҗмах бакчасына эләккәндәй бәхетле сизәсең.

Авылда тормыш көтү хуҗалыкта мал асрау белән бәйле. Әткәм-инәм дә терлек асрады. Сыерны ташлатып торганда (хәзер генә авыл кибетләрендә сөт ризыклары сатыла, ул елларда сатуда сөт юк иде), гаиләсе сөтсез интекмәсен өчен, инәй зур эмаль чиләккә сөт җыя, салкынга куеп аны бозланганчы катыра иде. Тәмлерәк булсын дип, шикәр комы да куша. Өй алдыннан шул бозлы сөтне алып кереп, куе итеп ясалган сөтле чәй эчә идек.

Инәм сәламәт, көчендә чагында төрледән-төрле ризыклар әзерләргә яратты. Сөтне кызарганчы кайнатып, эремчек ясап куя. Шикәр, бал кушсаң, чәй эчәргә бер дигән затлы сый була. Күрше-күлән хуҗабикәләрдән ишетеп-өйрәнеп, без кайтышка сыр да ясап куя иде!

Әткәй-инәм, үзләре тигез булып тормыш көткәндә, умарта тоттылар. «Бусы – юкә балы, бусы – карабодайныкы», – дип, җәйнең хозур көннәрендә яңа балдан авыз итүләр, озак итеп, гәпләшә-гәпләшә, чәй эчүләр – кабатланмас мизгелләр булып, гомерлеккә истә калды.

Кайнанам тагын бер изге гамәл кылып калдырган икән. Ул җәй җитү белән бөтен оныкларын үзләренә җыя иде. Кем балалар бакчасыннан, кем мәктәптәге укуыннан бушап, Азнакай районының болыннар кочагына сыенып утырган Сөендек авылына каникулга кайта иде. Алар кечкенәдән бер-берсе белән дуслашып, туганлыкларын тоеп, әби-бабаларының җылы кочагында үстеләр. Бу төп йортка өеп-өеп кучтәнәч кайтарганны да хәтерләмим мин. Әткәминәм хәзинәдә барына канәгать булып, шушы ишле балаларны карап, тәрбияләп тордылар.

Көз җиткәч, авыл һавасында ныгып, кояшта каралган балалар калага, өйләренә таралышалар иде. Чын каникул менә шундый була ул!

Әткәм Нәҗип Вагыйзь улы – Татарстанның атказанган механизаторы, озак еллар буе «Алга» күмәк хуҗалыгында ремонт мастерское җитәкчесе, механик булып эшләде. Сүз уңаеннан, аның исеме «Язмышыбыз Азнакай. Азнакай – наша судьба» (Казан, 2014) исемле, районыбызның күренекле кешеләре турындагы энциклопедик белешмә-китапка кертелгән.

Язмыш сынауларыннан сынмаган, тормыш юлыннан янәшә атлап, алтын туйларын да билгеләгән әткәй-инәй балалары, гаиләсе, авылдашлары өчен якты йолдыз булып янып яшәделәр.

Гөлсинә САФИНА.
Чаллы.



Мин – татар хатыны. Әти-әни кушкан исемем Алевтина. Хәзер мине Алия дип йөртәләр. Алия исеме үземә дә бик ошый. Татар хатыны булу да ошый. Ә болай, милләтем белән мари кызы мин.

Мари Иленең Фадейкино авылында туып-үстем. Вакыты җиткәч, мари егетенә кияүгә чыктым, бала-

быз туды. 1993 ел минем өчен бик бәхетсез ел булды. Февраль аенда газиз баламны җир куенына салсам, Сабантуй көнне иремне ток сугып үтерде. Электрик иде. Идән астындагы су җылыту системасын көйлим дип тотынган җиреннән фаҗигагә тарыды. Моңарчы куркынычсызлык техникасын бик төгәл үтәгән кеше никтер бу юлы саксызлык күрсәткән. Адәм баласы күрәчәген күрми, гүргә керми, диләр бит. Ирем исән чакта яңа өй салып кергән идек. Бар мөлкәтне иремнең әти-әнисенә калдырып чыгып киттем. Бу йортта мине тотарлык берни дә калмаган иде инде.

Алардан киткәч, Шиньша авылындагы май заводына эшкә урнаштым. Шунда эшләгәндә Рәис исемле татар егете белән таныштым. Таныштым дип, бергә эшләгән кеше белән алай махсус танышасы да юк инде. Аның миңа битараф булмавын тиз абайладым. «Йөрмә, син – егет кеше, мин – тол хатын. Безнең уртаклык юк», – дип, хисләрен сүндерергә тырыштым. Ул да аңлады шикелле, башкача игътибар күрсәтмәде.

1996 елның октябре иде. Эш урыныма Рәис килеп керде. «Накладнойларга кул куярга чакыралар. Сине алырга килдем», – ди. Кул куясы булгач, барырга кирәк дип, аның машинасына менеп утырдым. Карыйм, Рәис башка юлдан китте. «Дөрес бармыйсың бит», – дим. Ул бер сүз дә эндәшми. Күрше авылга ук китеп бардык. Шунда гына күңелемә шик керде. Бер матур гына йорт каршына килеп туктадык. Көтү кайтыр вакыт иде. Капка төбендә ап-ак яулыгын таратып бәйләгән олы гына яшьтәге татар әбие утыра. Мин, төшмим, дип, аяк терәп карышам. Капка төбендә утырган әби Рәиснең әнисе икән. Чип-чиста мари телендә: «Монда кадәр килеп, бер чынаяк чәй дә эчми китмәссең инде», – дип, мине өйгә чакырды. Сусаган да идем, аңа ияреп өйгә кердем. Шулай итеп, мин Мари Комыгырҗасы (рәсми исеме – Тат-Чодраял) килене булып яшәп калдым. Икенче көнне әти килде. (Әни ул вакытта авырып, хастаханәдә ята иде.) Татарча бик яхшы белә иде безнең әти. Рәисне бик ошатты. Мулла чакыртып, никах укыттык. Рәискә ул вакытта 30 яшь иде. Өйләнмәгән егет кеше иде ул. Төрле сүз әйтүчесе дә булгандыр, кайнатам миңа берәүдән дә сүз тидертмәде. «Җиде татар хатынын тезеп бастырыгыз, безнең киленгә җиткәне булмас», – дип әйтергә ярата иде. Үзем дә аларны бик яраттым. Кайнатамның куллары калтырый торган иде, шуңа күрә вак эшләрне авырлык белән башкара иде. Берсендә вак балык кыздырдык. Минем, шул балыкны чистартып, кайнатама ашатканымны күреп, күршебезнең исе китте. Рәисләр алты туган иделәр, берсенең дә кырын караганы булмады. Иремнең туганнарын да, телен дә, динен дә, татарларның гореф-гадәтләрен дә яратып кабул иттем. Безнең мари халкында элек чәй эчү гадәте юк иде. Без үскәндә әни (марича – «ава») су кайната да, шуңа кайнатма туглап эчә торган идек. Хәзер татарча куе, сөтле чәй булсын миңа. Гөбәдияләр, өчпочмаклар, кыстыбыйлар – иң яраткан ризыкларым. Бездә таба ашы пешерсәләр, камырын калын итәргә тырышалар, ә татар хатыннары, киресенчә, камырын юка гына итеп, эчлеген күбрәк салып пешерә икән. Хәзер үзем дә шулай эшлим инде. Кайнанамнан бик күп нәрсәгә өйрәндем. Татарча сөйләшергә дә ул өйрәтте. Баштарак тел белмәвем кыенлык тудыра иде, шәһәргә китәргә микән әллә дигән чакларым да булгалады. Картаеп барган кайнаналарымны ташлап чыгып китәргә кешедән оялдым. Рәис белән тату яшәдек. Ике кызыбыз туды. Зөлфия белән Эльмира. Алар татарча да, марича да яхшы белеп үстеләр. Үзләрен татар кызлары дип саныйлар. Хәзер Әтнәдәге техникумда укыйлар. Аларны да, вакытлары җиткәч, Алла боерса, татар егетләренә бирергә язсын иде дип телим.

Рәисемнең генә гомере иртә өзелде. Балаларның үскәннәрен дә күрә алмады. Тумыштан ук йөрәге сау түгел иде. Табиблар операция ясатырга куштылар. Рәиснең операциягә ятарга күңеле бармады. Булдыра алганча, мин аны авыр эштән сакларга тырыштым. Печән чабарга, утын ярырга бик оста идем. Ирләр уянып чыкканчы, минем бер арба печәнем чабылган була торган иде. Ничек кенә тырышсам да, Рәисне саклап калып булмады. Декабрьдә 45 яшен тутырды, 3 май көнне бакыйлыкка күчте. Үлеме кинәт булды. «Ай-ай!» – дип ике генә аваз әйтергә өлгерде. Рәисне җирләгәч, күңелем ислам диненә тартыла башлады. Коръән сүрәләре ятларга керештем. Кайнанамның, ел саен авыз ачтырмый калма, дигән васыяте бар иде. Ул васыятьне дә үтәргә тырышам. Хәер, Рәис исән вакытта да үземне мөселман дип хис итә идем инде. Кайнатам авылыбызның бер кешесе белән зиратны карап-тәрбияләп тордылар. Печәнен дә чабып алалар иде. Шул абзый: «Печән җыям, дип, киленең зиратка кереп йөрмәсен», – дигән. Янәсе, мин мөселман кешесе түгел. «Минем дә шул зиратка барып ятасым бар, мине алай тыймасын», – дидем.

Татар халкын бик яратып, хөрмәт итеп яшим. Безнең якта мари белән татар бер авыл булып, дус-тату көн күрәләр. Үземнең әтием дә безгә килсә, татарча гына сөйләшә, Рәис белән без аларга барсак, Рәис марича гына сөйләшә торган иде. Авылыбыз үзе дә, кешеләре дә бик әйбәтләр. Тик менә яшьләргә эш юклыгы гына бик читен. Без хатын-кызлар тормышны шәл белән алып барабыз. Кулның бер дә буш торганы юк. Айга 1 шәл, 2 косынка бәйлим. Иремнең Казанда яшәүче апасы аларны сатып бирә. Сыер асрыйм, аның да бераз кереме булмый калмый. Менә шулай яшәп ятабыз.

Алевтина ЗЫЯТДИНОВА.
Мари Иленең Морки районы,
Тат-Чодраял авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU




Фото: Ксения Богданова

КЕСӘСЕНӘ КҮРӘ ЯРДӘМЕ

ЯҢА ЕЛДАН ХЕЗМӘТ ВЕТЕРАННАРЫНА СУБСИДИЯЛӘР ТҮЛӘҮДӘ ҺӘМ ТАШЛАМАЛАР БИРҮДӘ ЗУР ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТЕЛДЕ. ДӘҮЛӘТНЕҢ АЗ КЕРЕМЛЕЛӘРНЕ ЯКЛАП КАБУЛ ИТЕЛГӘН АДРЕСЛЫ ЯРДӘМЕ РӘХӘТ ТОРМЫШТАН ТҮГЕЛ.

Яңалыкларсыз яңа ел буламы инде ул?! Бигрәк тә тормышыбызга көннән-көн тирәнрәк үтеп керә барган кризис чорында?! Аның, рухи халәтебезне генә түгел, бар дөньябызны — матди хәлебезне таркатырга, тамырыбызга балта чабарга азапланган санкцияләргә бай беренче елы үтеп тә китте. Сизми калдык, дип әйтә алмыйм. Сиздек. Шактый саеккан кесәбездәге акчаны саный-саный, азык-төлекнең бәясе төшерелгәнен эзләп кибеттә йөргәндә дә, балаларыбызны ял итәргә җибәргәндә дә, хәтта аларны репетиторга йөрткән чакларыбызда да... Инде менә яңалыкның да яңасы... Көтелмәгән дип әйтмәс идем. Бөтенесе шуңа таба бара иде бит инде. Аннары... начар яңалык түгел ул. Ни дисәң дә, моны дәүләтебезнең гаделлеккә таба юл алган дөрес адымы дип бәяләргә кирәк: яңалыкның максаты — аз керемле гаиләләрне, хезмәт ветераннарын барлап, ярдәмне иң беренче аларга күрсәтү. Күктән дә төшкән түгел... Татарстан Дәүләт Советының «Татарстан Республикасы халкын адреслы социаль яклау турында»гы законына кертелгән үзгәрешләр нәтиҗәсе ул. Бүген республикада 232 мең хезмәт ветераны яши. Ел саен алар сафы 9,5 меңгә арта бара. Шуларның кайсы байларча, кайсы уртача, ә кайсы фәкыйрьлектә яши. Менә шул очын-очка ялгап, ипи-сөтлек кенә пенсиясе белән көн күреп ятучы әби-бабайларыбыз хакында бара сүз, ягъни кем чыннан да мохтаҗ — шуларга ярдәм турында. Дөрес, гадел, бер караганда. Материалны әзерләгәндә, редакциягә килгән хатларны, укучыларның үтенечләрен искә алып, Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, Мәгариф һәм фән министрлыкларына, муниципаль органнарның хезмәткәрләренә мөрәҗәгать иттек. Абруйлы оешмаларның абруйлы аңлатмаларын аларга тәгаенләнгән сораулардан башлыйбыз, хөрмәтле укучылар!

Хезмәт ветераннарына льготалар

?«Яңа елдан соң пенсионерларның хәле тагын да мөшкелләнәчәк, моңарчы бирелгән субсидияләр бетәчәк, имеш. «Тагын да мөшкелләнү» ничек була соң ул? Моннан ары да артка тәгәрәп буламы? Чит илләрдә җыештыручы булып эшләүчеләр дә 30-40 ар мең сум (безнең акча белән) пенсия ала. Шулардан үрнәк алсыннар иде...»

Галия Хәйриева.
Түбән Кама шәһәре.

Яңа елның 1 гыйнварыннан кертеләчәк үзгәрешләр яңа елдан бу исемгә лаек булачак хезмәт ветераннарына кагыла. Ә калганнар?! Социаль ярдәмне моңа кадәр ничек алып килгәннәр, шулай алачаклар. Алар өчен барлык төр субсидияләр искечә калачак. Ә менә 2016 елның 1 гыйнварыннан хезмәт ветераннары сафларына басучы пенсионерлар, керемнәре 20 мең сумнан да артып киткән очракта, чыннан да, кайбер льготалардан файдалана алмаячак. Әйтик, торак-коммуналь хезмәтенә түләүгә 50 процентлы субсидия-льгота. Мәсәлән, элек инвалид 1000 квадрат метрлы мәйдан биләп торган фатирына 60 мең сум түләп, шуның 50 процентын, ягъни 30 мең сумын кире кайтарып ала торган булса (әйе, андыйлар да бар), хәзер инде компенсация бары тик норматив буенча гына билгеләнәчәк. Тагын... быелдан керемнәре 20 мең сумнан артып киткән хезмәт ветераннары телефон өчен бирелә торган субсидияләрдән, юлда йөрү өчен бердәм транспорт карталарыннан, шулай ук бушлай колак аппараты алу һәм бушлай теш протезлау мөмкинлегеннән мәхрүм калачак. Аларга бары, пенсионер буларак, ай саен 280 сум акча гына бирелеп барылачак. Кереме 20 меңнән дә артып киткән хезмәт ветераннарының саны бүген бездә 1500 тирәсе.

Балаларга ташламалар

?«Тәрбиягә бала алучы гаиләләрне хөкүмәт ярдәменнән ташламый. Ә менә күп балалы гаиләләрдә үскән балалар, акча җитмәү сәбәпле, күп нәрсәдән мәхрүм. Кайчан да бер ул пособиеләр артырмы-юкмы?»

Фәридә Галиева.
Казан.

Хәзер, чыннан да, Дәүләт Думасында балалар пособиесе турында закон проекты эшләнеп ята. Әйе, әлегә ул бик аз – аена нибары 300 сум... Ул керемнәре яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләргә бирелә. Бу мәсьәлә яңадан каралачак һәм ярдәме дә, тагын да адреслырак булганга, күбрәк булыр дип өметләник. Ана капиталы исә 2016 елда – 453 мең сум, 2017 елда – 480 сум, ә 2018 елда 505 сум тәшкил итәчәк.

Бүген республикада яшәүчеләрнең һәр өченчесенә йә федераль, йә республика бюджетыннан төрле социаль ярдәм күрсәтелә.

Юлга түләүләр

?«Эшләгән пенсионерлар юл картасына акчаны үзләре түләячәк, дип ишеттем. Рәхәт тормыштан эшләмибез бит. Пенсия акчасы җитәрлек булса, бер дә тилмереп эшләп йөрмәс идек. Ни өчен хәтта транспортка түләүләрне дә элеккечә калдырмаганнар».

Разия Миннеҗанова
Казан.

Бу мәсьәләне хөкүмәтебез карады. Пенсионерларга юлга түләүләр, аларның льготникмы, түгелме булуына карамастан, 2005 елдан бирле бирелә. Тик 2016 елдан ул пенсионерның уртача айлык кеременә бәйле булачак: әгәр аның кереме 20 меңнән кимрәк икән, аңа акчалата түләү күләме 427 сумга җитәчәк. Ә инде 20 меңнән артыграк булса, бу сумма 280 сум тәшкил итәчәк. Аңлавыгызча, бердәм айлык социаль юл билеты 427 сум тора. Ә балаларныкы – 258 сум. Шулай итеп, айлык керемнәре 20 меңнән ким булган пенсионерлар, кирәксенгән очракта, социаль билетны кесәсеннән бер тиен акча чыгармый гына да алу хокукына ия. Ә менә керемнәре 20 меңнән артып киткән пенсионер-

PRESSA.RU

ларга 147 сум өстәргә туры киләчәк. Шунысын да әйтик, бердәм акчалата түләүләрдән файдаланучы 512 мең пенсионерның 138 меңе яки 27 проценты, керемнәре 20 меңнән артып киткән кешеләр. Эшләүче пенсионерның уртача кереме – аена 29 мең тирәсе.

Татарстан әниләрен балалар бакчалары өчен түләүнең артуы бигрәк тә нык борчыды.

Инвалид та, хезмәт ветераны да...

«Мин инвалид һәм хезмәт ветераны. Ни өчен мин ике льготадан да файдалана алмыйм?»

Нәҗия Гаязова.
Яшел Үзән районы.

Хезмәт ветераннарын социаль яклау чаралары Татарстан Республикасы законының: «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында»гы 5 нче маддәсендә билгеләнгән. Мәгълүм законның 9 нчы маддәсендә исә безнең законнар нигезендә дә, федераль законнарга таянып та социаль ярдәм алу хокукына ия булучы гражданнарга, үзе сайлаганча, шул ярдәмнең берсе генә күрсәтелә. Шулай итеп, инвалид та, хезмәт ветераны да булган кешеләргә социаль ярдәм йә «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»гы федераль закон, йә «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында»гы үзебезнең закон нигезендә күрсәтелә.

Бакча кыйммәтләнә

«Мин бәләкәчем белән өйдә утырам. Ирем дә көнлекче эшендә. Аның эше бүген бар, иртәгә юк. Без иремнең эш хакына яшибез. Башка акча керер җир юк. Ул аз да түгел, күп тә түгел 18 мең тирәсе. Дүрт кеше ничек яшәргә тиеш дип уйлыйсыз шул акчага? Җитмәсә, тагын балалар бакчасына бәяне арттырып куйганнар. Мәгариф министры бер балага аена уртача 9 мең сум акча тотыла диде. Ә мин менә хосусый бакчаларда 6 гына мең сум тотылуын беләм. Бу нәрсә? Халыкны көпә-көндез кычкыртып талаумы? Әллә, чыннан да, безнең бакчаларда уңай якка зур үзгәрешләр барамы?»

Рәхилә Вәлиева.
Казан.

(Министрлар Кабинетында булып узган брифингта Мәгариф һәм фән министры аңлатмасыннан.) Хәзер мәктәпкәчә белем бирү гомумбелем бирүнең беренче баскычы буларак кертелде. Бу әле беренче мәртәбә шулай. Мондый вазгыять мәктәпкәчә белем бирү-тәрбияләүнең сыйфатын тагын да күтәрүне таләп итә. Биредә һәр бала белән аерым эшләү – безнең төп бурычыбыз. Бәяләр уртача 180–270 сумга артачак.

Элек ата-аналар барлык чыгымнарның 20 процентын түләгән булсалар, хәзер инде яңа закон буенча баланы карауга киткән гомуми чыгымнар өч өлешкә бүленә: белем бирүгә финанс чыгымнары (педагогларга, тәрбиячеләргә эш хакы да, уенчыклар, укыту-методика әсбаплары сатып алуга чыгымнар да бирегә керә); муниципалитетлар тарафыннан түләнә торган коммуналь чыгымнар; һәм өченчесе – бала карауга киткән чыгымнар. Әти-әни менә шуның соңгысы өчен түли. Министрлыкның матбугат үзәге хәбәр итүенчә, балалар бакчасына түләү бәяләренең артуы азык-төлек кыйммәтләнү, әйткәнебезчә, анда эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыру, тагын башка күп кенә чыгымнар белән бәйле.

Адреслы яклыйбыз

«Түләүләргә үзгәреш кертелгән очракта, дәүләттән бирелә торган компенсация дә үзгәрергә тиеш ич. Ул нидән гыйбарәт?»

Наилә Сабитова.
Чаллы шәһәре.

«Яңа компенсация гаилә кеременә бәйле. Дәүләт – халыкны адреслы социаль яклау ягында. Башкача әйткәндә, фәкыйрь тормышлы, аз керемле кешеләргә ул ярдәм итәчәк. Ә менә байлар үзләре түләргә мәҗбүр булачак. Шуңа да безнең өчен гаилә кереме бик әһәмиятле белешмә булып тора. Әлбәттә инде, компенсацияне балалар бакчасы белән килешү төзүче ала. Әгәр дә инде документны әбисе, бабасы, абыйсы һәм башка туганы тутырса, баланың законлы вәкиле булмау сәбәпле, алар компенсация ала алмый. Закон буенча компенсация айның 14 енә кадәр бирелергә тиеш».

Күбесен белмибез дә...

«Татарстанда 70 тән артык социаль ярдәм чарасы бар, дип ишеттек. Аның тулы исемлеге белән кайда танышырга була?»

Нурулла Сәгыйтов.
Казан.

Социаль яклау органнары тарафыннан халыкка күрсәтелә торган дәүләт ярдәменең тулы исемлеге белән сез Татарстанда дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында таныша аласыз. Бүген республикада 1,5 миллион кеше шул ярдәмнән файдалана. Шуларның күбесе ул ярдәмне кеременә карамый ала. Быел Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы льгота алучыларга 14 миллиард сум акча түләде.

Хезмәт күрсәтүләрнең күбесен халык белеп тә бетерми. Шуларның кайберсен генә исегезгә төшереп үтәбез: юлга, мәрхүмне күмүгә тотылган чыгымнарга компенсация, балалы гаиләләргә матди ярдәм, радиациягә эләккән гражданнарга һәм аларның туганнарына ярдәм, эшсезләрне эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү, сәяси репрессиягә эләгүчеләргә ярдәм, реабилитацияләнгән гражданнарга телефон кую чыгымнарын каплау, балаларга һәм 18 яшькәчә булган инвалидларга айлык өстәмә акчалата түләүләр, хәрбиләрнең йөкле хатыннарына бер мәртәбә бирелә торган пособие, берьюлы өч һәм аннан күбрәк бала туганда пособие, «Россиянең мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнүчеләргә ел саен бирелә торган акчалата түләүләр, бала карап өйдә утыручыларга айлык пособие һәм тагын дистәләгән чаралар каралган.

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Яңа ел ялларында Казанга 133 меңгә якын турист килгән. Кунакханәләрнең категорияләренә карап, аерым көннәрдә алар 90 процентка кадәр тулы булган. Казан кунаклар кабул итү ягыннан Мәскәү белән Санкт-Петербургтан гына калыша. Сәяхәт өчен Татарстанны сайлаган кунаклар Казанның истәлекле урыннарында, Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында, Зөя утрау-шәһәрендә, Алабуга дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында булганнар.

■ Казан Кремлендә «Яңарыш» республика фонды әзерләгән Хәйриячеләр китабының VI томын һәм Рәхмәт хатларын тапшыру тантанасы узды. Иганәчеләр бүләкләрне Татарстан Дәүләт киңәшчесе, «Яңарыш» республика фондының Химаячеләр шурасы рәисе Минтимер Шәймиев кулыннан кабул итеп алды. «Яңарыш» хәйриячеләре исемлеген туплаган китапны тапшыру тантанасына муниципаль берәмлек башлыклары да килгән иде. Аксубай, Әлки, Лениногорск, Спас, Чирмешән, Чистай районында гомер итүчеләр хәйриячелек өлкәсендә аеруча активлык күрсәткән.

МӘДӘНИЯТ

■ Монте-Карлода концерт залында татар музыкасын алкышларга күмделәр. Татарстан Дәүләт симфоник оркестры баш дирижеры һәм сәнгать җитәкчесе Александр Сладковский Монте-Карло филармония оркестрына дирижерлык итте. Ул яшь композитор Эльмир Низамовның «Күкләр хәрәкәте» симфоник әсәрен Европа тамашачысына әнә шулай җиткерде.

■ Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында халык язучысы Гомәр Бәшировның тууына 115 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә узды. Анда олуг әдипнең варислары, язучы иҗатын яратучылар, күренекле әдипләр катнашып, хатирәләре белән уртаклаштылар. «Намус», «Туган ягым – яшел бишек», «Җидегән чишмә» әсәрләреннән өзекләр тыңланды, җырлар яңгырады.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисты Гөлнора Гатина яшь опера җырчыларының Италиядәге Комо шәһәрендә узган Concorso Per Giovani Cantanti Lirici D'Europa конкурсында җиңү яулады. Ул шулай ук Италия шәһәрләре буенча оештырылган турнеда катнашачак.

СПОРТ

■ Республикада легендар «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең 90 еллыгына багышланган бәйрәм чаралары дәвам итә. Физкультура-спорт җәмгыяте хезмәткәрләре һәм ветераннары, аларның гаиләләре катнашкан җыр бәйгесе Гала-концерты аңа старт биргән иде. Ярышлар, хәйрия акцияләре, «Динамо – балалар күзе аша» балалар иҗаты конкурсы, спорт журналистларының «Динамо – хәрәкәттә һәм бердәмлектә көч!» бәйгесе, күренекле спортчылар-чемпионнар белән очрашулар, «Динамо» традицияләрендә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы башка чаралар уза.



МӘГАРИФ

■ Иннополис университеты карамагында сәләтле балалар өчен мәгълүмати технологияләр лицее ачылды. Информатика, математика буенча көчле, үз тормышларын мәгълүмати технологияләр белән бәйләргә теләгән балалар шунда белем алачак. Моннан тыш, укучыларны олимпиадаларга әзерләү, робот техникасы буенча өстәмә белем бирү күздә тотыла. Лицей 13 мең квадрат метр мәйданлы заманча җиһазландырылган бинада урнашкан. Анда 24 сыйныф кабинеты һәм химия, физика, биология, технология буенча кабинет-лабораторияләр, китапханәләр, спорт заллары булдырылган. 7-11 нче сыйныфларда 360 бала укыячак. Бер сыйныфта укучыларның саны 15 тән артмаячак.

PRESSA.RU



МӘСКӘҮ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕНӘ ЫШАНАМЫ?



Гөлнара ЗЫЯТДИНОВА

ТЕЛӘСӘМ-ТЕЛӘМӘСӘМ ДӘ, ЧЫНЛЫКТА МИН ГАСТАРБАЙТЕР ИНДЕ. ӘММА БУ СҮЗНЕ ЯРАТМЫЙМ, ШУҢА КҮРӘ ҮЗЕМНЕ «ВАХТАГА ЙӨРЕП ЭШЛӘҮЧЕ» ДИП АТЫЙМ.

Нәкъ алар шикелле бер ай эшләп, икенчесендә ял итмәсәм дә, ике атна саен, шимбә-якшәмбегә Казанга кайтып киләм бит.

Беренче мәлләрдә моңа кимсенә, үземне жәлли идем. Мин бит өйдә утырырга, йорт карарга, кул эшләре белән шөгыльләнергә, аш-су тирәсендә әвәрә килергә хыялланган идем. Ләкин язмыш башкачарак булды... Хәзер уйлыйм, димәк, шулай тиеш – бу минем узасы юлым. Безнең бабайлар да бит гомер буе читтә эшләп мал тапкан. Шәймулла бабам алтын приискаларына барып чыккан. Донбасста шахтага төшкән. Аннан Мәскәүдә метро төзегән. Үзенә биргән ике бүлмәле фатирны алмыйча: «Юк, кирәкми, минем авылым бар», – дип Таузарга кайтып киткән, йорт салган...

Мин дә бүген алар кебек дөнья көтүче, гаилә туйдыручы.

Студент чактан бирле иң зур теләгем Казанда яшәү булды. Мин инде бу хыялым чынга ашты дип йөри идем: улым мәктәпне генә тәмамлый да күченәбез... Тик улым китте, ә мин тагын калдым – эш таба алмадым. Бер бала – Мәскәүдә, икенчесе – Казанда, үзем – Түбән Камада... Нидер хәл итәргә кирәк иде. Түбән Камада үсү мөмкинлеге юк. Ә минем улым белән кызымны укытасым, аякка бастырасым бар. Мәскәүдә эшләүче энемнең: «Монда кил, эш, һичшиксез, табарсың», – диюен башта чынга да алмадым. Хатын-кыз башым белән шулай йөрергәме?!. Сөйләшеп кенә карыйм дип, киттем Мәскәүгә. «Өйдәп баручы белгеч итеп алабыз», – диделәр, хезмәт хакын әйттеләр. Уйланып калдым... Тагын ике атнадан бер чемодан белән башкалага барып төштем.

Офистагы хезмәттәшләремне мин гел өчкә бүләм. Беренче төркем, әлбәттә, мәскәүләр үзләре. Аларны аерым милләт, башка галәмнән, дисәң дә була. Бездән, килүчеләрдән, беренче чиратта киенү рәвеше белән аерылалар. Алар гади киенә, күзгә бәрелеп тормый. (Сүз уңаеннан әйтим әле: татар концертына барырга чыксам, үзебезнекеләрне мин хәзер метрода ук таныйм. Өстендә күрән төстәге чәшке тун икән, димәк, бу ханым синең кебек үк кичке тамашага ашыга, ул да татар җырына гашыйк. Чыгышы белән Сергач ягыннандыр, дисәм дә, мөгаен, ялгышмам әле.) Хәер, бераздан читтән килеп эшләүчеләр дә эшлекле костюмнарын сала, җайлы, уңайлы киемгә күчә. Түбән Камада чакта кышкы аяк киемнәрем генә дә 3-4 пар иде әнә: биек үкчәлесе, үкчәсезе... Хәзер исә тигез табанлы бер итегем бар – җитә! Җомга көнне бөтенебез эшкә джинсы чалбардан килә: бездә генә түгел, бөтен Мәскәү офисларында шундый тәртип. Читкә киттем. Икенче төркем – Мәскәүгә минем кебек илебезнең төрле шәһәрләреннән килүчеләр. Өченче төркем – Сочи төзелешеннән соң кайтып урнашучылар. (Безнекеләр күп араларында: алар Татарстанга инде кире кайта алмый – Сочидагы хезмәт хакыннан соң, Казанда эшләүнең мәгънәсен күрмиләр.) Дөрес, миңа каршы өстәлдә утырган Маша кебекләр – эштән бигрәк, яңа тормыш эзләп килүчеләр дә бар. Әмма безнең арада ул да үзен ят итеп тоймый. Әниләр янына кайтып килгән саен, миннән: «А чакчак привезла?» – дип сорый: Сочида татарлар белән эшләгән, безнең аш-сулардан да, гореф-гадәтләрдән дә шактый хәбәрдар.

Эштә без барыбыз да бертигез. Оешмабызда куелган тәртип зур роль уйный бугай. Эш көне тугызынчы яртыда башлана. Мәскәү өчен ул бик иртә, әмма соңга калу юк! Кичке алтынчы яртыга кадәр эшләргә тиешбез. Ләкин беркем дә бу вакытта чыгып чапмый: җидегә кадәр дә, аннан соң да утырырга мөмкиннәр.

Без, килүчеләр, барыбыз да фатирлар «снимать» итеп торабыз. Мин гомер буе: «Фатирда тору – акчаны җилгә очыру ул», – дип әйтә идем.

Тормыш шул бу: фикерләрең үзгәргәнне кайчак үзең сизми дә каласың.

Мәскәүгә әле килгән генә көннәрдә кулыма Грэм Хилл дигән бер эшмәкәрнең язмасы килеп эләкте. «Мин башта 39 квадрат метрлы фатирда яшәдем, – дип яза ул. – Алты пар күлмәгем бар иде, берничә пар тәлинкә, чынаяк... 1998 елда кинәт кенә баеп киттем. Акча күп! Туздырасы килә! Дүрт катлы йорт сатып алдым. Инде аңа җиһаз кирәк иде. Әмма минем яңа компания оештырып йөргән чагым, эшем күп, вакытым җитми. Миңа кирәк әйберләрне сатып алу белән шөгыльләнергә Сэвен исемле егетне ялладым. Ул кибетләргә йөри, фотога төшерә һәм миңа җибәрә, ә мин кабинетта гына хәл итәм: алыргамы, юкмы... Йорт эче җиһаз, көнкүреш техникасы, электроника, гаджетлар белән тулды. Аудиофильмнар минем өйгә тонналап кайтты бугай. Үземнең автопаркым барлыкка килде. Тормыш күпкә катлауланды, әллә никадәр мәшәкать өстәлде: газон, автомобильләр, страховка, ялланган эшчеләр... Боларның һәммәсен оештырырга, гел күзәтергә, тәртиптә тотарга кирәк иде. (Чынлыкта, алар миңа түгел, мин аларга хезмәт итәм булып чыга түгелме соң?!) Аннан мин Нью-Йоркка күчтем – йортларым икәү булды. Инде бер йорт урынына ике йорт турында уйларга мәҗбүр идем... Тирә-юнемне чорнап алган бу әйберләрнең миңа шатлык та, бәхет тә китермәгәнен аңлар өчен унбиш ел кирәк булды. Кеше өчен иң мөһиме – якыннары белән ике арадагы мөнәсәбәтләр, туплаган тормыш тәҗрибәсе, максатлары. Сине шулар бәхетле итә. Мин кабат кечкенә фатирда яшим. Аның каруы, тыныч йоклыйм...»

Чыннан да, игътибар итсәң, артык әйберләр тирә-юнебездә бик күп безнең! Минем дә моңарчы иң яраткан кибетләрем «Икеа», «Уютерра», «Оби» иде. Барган саен, кирәксә дә, кирәкмәсә дә йә бер сөлге күтәреп кайтам, йә ваза... Хәзер менә күпме кирәк, шуның кадәр генә әйбер миндә. Сөлгеләрем дә икәү генә: бер зур һәм бер кечкенә, урын-җир әйберләре дә бары бер комплект (Түбән Камада торганда агы, чәчәклесе, ефәге... тагын әллә нindиләре бар иде). Артыгы нәрсәгә?! Беренчедән, шулар җитә; икенчедән, урын-җир алыштырам дип сузып йөрмисең: юдың, үтүкләдең, киерттең – туза икән, ташлыйсың да, яңасын аласын... Дөрес, Мәскәүдә дә

Фото: Рамил Гали

PRESSA.RU

«Бәхетле» кибетенә кергән чакларда матур савыт-сабалар карарга яратам. Аерма шунда: сокланып карыйм, әмма алмыйм. Өч бокалыбыз бар. Берсендә эштәге кызлар чәйгә киләбез дигәч, алырга да җыенган идем, аннан тагын кире уйладым. Чит илләрдән истәлеккә сувенир итеп бокал алып кайта торган гадәтем бар. Түбән Камада алар махсус киштәдә тора иде, инде Мәскәүдә дә коллекциям берничәгә артты. Кызларга шул бокалларга ясап чәй эчерттем дә, юып кире урыннарына куйдым.

Кыскасы, кеше почмагында торуым белән инде күптән килештем. Чит илләрдә гомер буе шулай яшиләр әле әнә. Аннан: «Казанда фатирым бар бит», – дигән уй да, бәлки, минем күңелне тынычландырадыр.

Эшем буенча моңарчы да Мәскәүгә айга бер командировкага килеп торсам да, мин бу каланы беркайчан яратмадым. Үзләре бу хакта уйлаганнары бармы икән, белмим, әмма Мәскәү халкы күсе кебек бит ул – бөтен гомерләре җир астында, метрода уза. Алар гел үзалларына гына карап йөриләр: тирә-юньдәгеләрне күрмичә, кешегә күз салмыйча. Башын күтәреп, реклама язуларын укып баручыны очратсагыз, ул башкалага берничә көнгә кунакка килүче яки монда күптән түгел яшәүче булыр. Калганнар – егылсаң, өстеңнән атлап узалар: сизмиләр. Бәрелсәләр, ялгыш та гафу үтенмиләр. Кеше күп булгангадыр, метро – энергияне ала, ардырта. Гел онытмыйм: яңа килгән вакытым иде әле. Яңа ел алдыннан, эштән соң, сәүдә үзәгенә бүләкләр алырга киттем шулай. Һәм бер станциядән икенчесенә күчкәндә халык төркеменнән торган бөкегә эләктем. Миндә паника башланды. Син төркем эчендә торасың һәм шуннан беркая китә алмыйсың: алга да, артка да. Куркыныч!

Әйе, юлда күңелне бушатуы җиңел. Тыңлаучы гына булсын.

Миндә исләргә аллергия, бер ел йөргәннән соң, берсендә метрода һавасызлыктан аңымны җуйгач, машинага күчеп утырдым. Һәм... Мәскәүнең матурлыгын күрдем. Беренчедән, Мәскәү юллары көзге кебек икән – машина җилдертә генә! Болай да әйбәт булган асфальтны кырып, ел саен диярлек яңасын җәеп торалар икән монда. (Мәскәүдән соң Түбән Кама юллары сугыш чорын хәтерләтә: адым саен тәгәрмәч төшеп китәрлек чокырлар – елыйсы килә...) Икенчедән, инде әйткәнемчә, карар, күрер, сокланыр урыннар байтак икән монда! Кичке Мәскәү бигрәк тә матур – бихисап утлар белән җемелди, килгән дусларны Мәскәү урамнары буйлап машинада йөртеп кайтырга яратам. Казанга кайтмаган атналарда бөтен паркларны йөреп чыктым, әйтергә кирәк: алар монда күп, чын, зур парклар, урман кебек. Музейларны, галереяларны карадым. Иң яраткан урыным – Мәскәү дәүләт университеты: аның янында хәтта минем йөрәгем дә башкача тибә башлый.

Ә татар концертларына йөрүемнең сәбәбе сагыну булды бугай. Читкә киткәч, бөтен нәрсәнең дә кадере арта икән. (Мәскәүдәге татар тамашачысын күзәтү – үзе бер тамаша! «Ә хәзер 45 минутлык антракт», – дигәч, беренче юлы аптырап калдым. Нигә шулай озак?! Халык торды да, дәррәү кубып буфетка йөгерде. Чәйгә чиратка бастылар – калган бөтен нәрсәне үзләре белән алып килгән булып чыктылар. Сергач ягында майда ит пәрәмәче кыздыралар бит (ә Мәскәүдә башлыча шул яктан чыккан татарлар яши) – залга, фойега пәрәмәч исе таралды. Сабантуйларда халык төркем-төркем булып, сәхрә ясап утыралар бит, монда да шулай. Табында пәрәмәч кенә түгел, җиләк-җимеш тә бар, башкасы да. Тәнәфесләрнең нигә шулай озак булуын аннары аңладым: Мәскәүдә күрешү читен, бигрәк тә бербереңнән ерак торсаң. Концерт – мондагы милләттәшләргә, туган-тумачага, дус-ишкә очрашу өчен бер сәбәп).

Барам дисәң, Мәскәүдә көн саен нинди дә булса концерт, спектакль... Ярты елдан соң гына игътибар иттем, хезмәт хакымның шактый өлешен билетларга тотам икән! Провинциядән килгән психология: Мәскәүдә күпме торасымны белмим, шуңа күрә бөтен мөмкинлектән файдаланып калырга тырышам. Түбән Камадан да Казанга премьераларга махсус килә идем, ә Казандагы дус кызларым гел: «Өлгереп булмый», – дия иделәр. Алар: «Мин теләсә кайсы вакытта да бара алам», – дип уйлый һәм... бармый. Мәскәүләрне дә тамашаларга йөри дип әйтә алмыйм.

Мәскәүдә тормыш үзгәрәк, мөмкинлекләр башка диимме. Берәр нәрсә кирәк булса, алар кибеткә чыгып чапмый: интернеттан эзләп табалар да, заказ гына бирәләр. Эштә җитәкчем теш пастасына кадәр шулай китертә. Пицца, сушилар турында әйтмим дә, юлга өч сәгать вакыт әрәм иткәнче, 300 сум артыграк түлисең дә... Мәскәүдәге «Бәхетле» кибете генә мондый хезмәт күрсәтми, ә эштәгеләр безнең камыр ризыкларын яраталар, сорыйлар, шуңа күрә бәйрәмнәрдә мин еш кына «Бәхетле»дән пирог ташучы ролен үтим.

Мәскәүдә торуның тагын нинди өстенлекләре бармы? Минем кебек сәяхәт итәргә яраткан кешегә, әлбәттә, монда күпкә уңайлырак: төш вакытында берәр сәгатькә сорап китеп тә виза ясатып, ял көннәрендә берәр илгә барып кайтып була. Яңа мавыгуым – спорт белән шөгыльләнү өчен дә мөмкинчелекләр күбрәк: уникаль спорт биналары, менә дигән тренерлар, еш оештырыла торган ярышлар.

Плюсларын санагач, инде минусларын да әйтергә кирәктер.

Мәскәү кебек зур калаларда ялгыз кешеләр күбрәк шикелле тоела миңа. Казанда, шәһәр үзәген әйләнеп кайтыйм әле, дип чыксаң, 15 минуттан берәр таныш кешене очратмый калмыйсың. Ә монда, көннәр буе урамнарда йөрсәң дә, сиңа «исәнме» дип дәшүче юк.

Мәскәүдә эшли башлаганнан бирле мин гел юлда... Әти белән әни Казанда – алар белән озак күрешмичә тора алмыйм, шулай гадәтләнгән. Аннан балалар да Казанда – аларның нинди уйлар белән йөргәннәрен, ничек сулаганнарын белми торырга ярамый.

Шушы вакыт эчендә поезд вагоннарында, самолет салонында күпме кеше белән таныштым, никадәр яз-

мыш белән очраштым! Беренче мәлләрдә юлдашларымның иң яшерен серләрен шулай җиңел генә ачып куя алуларына шакката идем. Аннан моның сәбәбен аңладым: ул мине беренче һәм соңгы тапкыр күрә, без башка очрашмаячакбыз. Ә белмәгән кешегә ачылырга була.

Үзем белән юлга һәрвакыт китап алам, комачаулаучылар булмаса, укыйм. Вакыт шулай үтә. Кайчак аралашырга кызык кына кешеләр очрый. «Рубин» командасы тренерларының берсе белән бер купега туры килгән булды. Мин белмәгән дөнья, өлкә бит – рәхәтләнеп тыңладым. Ул хәзер Красноярскига барып эшли икән. Моны ишеткәч, үземнең Мәскәүдә генә эшләвем бәхет булып тоелган иде...

Бер әрмән абзый белән кайткан гел истә. «Сез кайдан?» – дип сорап шаккаттырган иде ул мине. «Казаннан», – дим. «Юк, чыгышыгыз кайдан?» – ди. «Түбән Камада тудым», – дим. Ә ул һаман төпченә: «Әти-әниегез кайдан дип сорыйм», – ди. Барыбер белми бит инде, нигә аптырата, дип, җавапсыз калмас өчен генә: «Балтачтан», – дигән идем... «Беләм!» – ди бу. Киров шәһәрендә эшләгән, аннан Казанга күченгән, хәзер Мәскәүдә яши икән. Хатыны, балалары, бөтен нәсел-нәсәбе генә түгел, хәтта сөяркәләре хакында да сөйләде. Нишлисең, бүлдереп булмый бит... Әлеге дә баягы, күңелен бушатасы килгән чагы иде бугай.

Соңгы кайтуымда купедагы күршем Камчаткадан Казанга кунакка килүче булып чыкты. Төрле-төрле балыклардан авыз иттерде (әле өйгә күчтәнәч итеп тә бирде), диңгездә эшләве, көчле штормнарда ничек исән калуы, Камчатканың табигате, вулканнары, гейзерлары турында сөйләде. Боларның барысын да күңелемнең «күрәсе килгән җирләр» киштәсенә салып куйдым...

Билетларны, гадәттә, алдан алырга тырышам, чөнки көне якынайган саен, алар кыйммәтләнә бара. Поездга да, самолетка да. Җайлы: кассаларда чират торуны белмим, барысы да интернет аша эшләнә. Гомумән, бөтен тормыш интернет аша бара хәзер.

...Мәскәү күз яшьләренә ышанамы? Белмим. Синең йөзең елмаюдан балкыймы, әллә битең буйлап күз яшьләре тәгәриме икәнен күрә дисезме аны? Ялгышасыз. Син бу каланы яраттыңмы, монда үз кешегә әйләнә алдыңмы, яңа дуслар таптыңмы – боларның берсендә дә аның гаме юк. Ничек яшисең, максатларыңа ирештеңме, тормышыңнан канәгатьме – ул болардан хәбәрдар түгел. Һәм белергә дә теләми! Чөнки ул ашыга... Төнлә машина белән ифтардан кайтам быел шулай. Юлның бу өлешендә тизлек 80 чакрым булырга тиеш дип күрсәтелгән. Әмма төн уртасында кагыйдәләргә игътибар итүче бер мин генә идем бугай. Мине хәтта бетон ташучы машина да узып китте. Мәскәүдә тормыш та шулай – синнән алда узып гел каядыр йөгерә. Атна башлана да бетә, башлана да бетә... Җиргә ике аягым белән нык басып торучы кеше мин, хисләр белән яшәмим – шуңа күрә җиңелрәктер. Ашыйсы ипиемне шушында эшләп табам, димәк, шушында яшәргә тиешмен. Ә Казаныма әле, һичшиксез, кайтырмын, үз илемә дә кирәк булырмын, дигән өметнең өзелгәне юк...

ЧИТ ҖИРЛӘРДӘ ЯТ БУЛМА

Кеше һәрвакыт яхшыга омтыла: яхшырак урында яшәргә, яхшырак эшкә урнашырга тырыша ул. Шуның өчен күпләр торган җирләрен, моңа кадәр аралашып яшәгән дус-ишләрен, таныш-белешләрен калдырып, чит шәһәрләргә, чит илләргә барып чыга, эшен, һөнәрен алыштыра... Әмма яңа җиргә ияләшеп, үз булып китү өчен һәммә кешегә дә беркадәр вакыт кирәк.

■ Гадәттә, яңа урынга, яңа шәһәргә ияләшү өчен бер ел җитә, дип саныйлар. Әмма адаптация чорының озынлыгы һәркемнең үзенә бәйле. Берәүнеке дә ул җиңел генә узмый. Мондый адымга барган кешегә берьюлы әллә никадәр мәсьәләне хәл итәргә кирәк бит: яңа эш урыны табарга, фатир яки бүлмә сатып алырга (кеше почмагына урнашырга), яңа тормыш ритмына күнегергә...

■ Статистика мәгълүматларына караганда, җиде кешенең бары берсе генә бу сынауларны уңышлы үтә ала.

■ Тәгаен нинди авырлык күтәп торганын белгәндә, сынауларны кичеп, уңышка ирешү мөмкинлеге бермә-бер арта.

■ Бик сирәк һәм бик кирәкле һөнәргә ия булсагыз да, тиз арада яңа әйбәт эш урыны табармын дип артык өметләнмәгез. Яшәү урынын алыштырырга теләгән очракта, күпләр эшне хәзер интернет аша эзли. Вакансияләр сайтын карый, шул шәһәрдә яшәгән танышларына, якташларына мөрәҗәгать итә, алар киңәшләренә колак сала.

■ Нindидер сәбәпләр аркасында даими эшкә урнашу озаккарак сузыла икән, берәр вакытлыча эш табарга тырышырга кирәк.

■ Яңа җирдә фатир (бүлмә) сатып алырга, арендаларга кирәк булганда, моны танышларыгыз яки тагын шул ук интернет ярдәмендә хәл итә аласыз. Әмма сез мөрәҗәгать иткән сайтларның бу өлкәдә тәҗрибәләре бармы-юкмы икәнен, клиентларның нинди фикерләр калдырганын бик җентекләп өйрәнегез. Агентлыкларга мөрәҗәгать иткәндә, торак буенча туган барлык сорауларыгызга да җавап алмыйча, бернинди кәгазьгә дә кул куймагыз. Фатирны агентлыклар ярдәменнән башка эзләгәндә бигрәк тә сак булыгыз. Килешү төземәгән килеш хуҗаларга беркайчан да алдан акча биреп куярга ярамый – бу кагыйдәне онытмаслык итеп хәтерләп калыгыз.

■ Рәсми рәвештә эшкә урнашу өчен регистрация узу мәҗбүри дип санала. Даими булмаса, һичьюгы вакытлыча. Моның өчен Россия регионнарының берсеннән икенчесенә күченгәндә – паспорт өстәләнә, башка дәүләтләргә үк барып чыкканда миграция хезмәтенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу эшне дәүләт оешмалары аша башкарсагыз, күпкә ышанычлырак булыр. «Ярдәм» итәргә атлыгып торган нindидер фирмаларга яки кешеләргә сүз катмавыгыз хәерлерәктер. Күп вакыт әйләнгечтән юл якынрак та була әле ул. Бу – шундый очракларның берсе.

■ Хәтта барысы да җайлы гына булганда да күченү барыбер стресс ул. Һәммә нәрсәне дә өр-яңадан башлыйсы бит: яңа тирәлеккә күнегәсе, яңа эшкә, яңа танышларга... Үкенгән, моңсуланган, нишләргә белмәгән чаклар да булырга мөмкин. Чит шәһәрдә, чит кешеләр арасында үзен ялгыз тою күпләргә хас күренеш. Моңардан коткарса – аралашулар, актив тормыш позициясе генә коткарыр.

PRESSA.RU

БАЛАГЫЗ КИТАП ЯРАТАМЫ?



Фото: авторныкы

Безнең балалар китап ярата! Кечкенәдән аларга иң кадерле бүләк китап булды. Яңа гына 9 яше тулган улыбызга әтисе электрон китап уку җайланмасы — Kindle алды менә. Аның ничекләр итеп сөенгәнен күрсәгез: төрле телләрдә китап укый алачак бит ул хәзер.
Мактануым түгел бу минем. «Улым (яки кызым) китап яратмый, кулына да тотканы юк», — диючеләргә җавап бирүем генә. Безнең гаиләдә өч бала үсә: өчесендә өч төрле холык. Кемнәрнеңдер сүзен кабатлавым түгел, үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм — баланың китап яратуы әти-әнидән, аларның китапны ничек укуларыннан тора.



Алимә
СӘЛАХЕТДИНОВА

Безгә кунаклар килгән иде. Малайлар бүлмәләрен кунак абыйга биреп, үзләре ул көнне зал ягында йоклады. Икенче көнне бик иртә торсам да, миннән дә алдарак уянган ике улым... китап укып утыра иде инде! Кунакларны уятырга, тавышланырга ярамый бит – китапның ләззәтен тоеп, бер сәгатькә якын утырды алар шулай. Моңа бик сөендем. Аеруча кече улым – Салихым өчен: ул моңарчы китап белән бөтенләй кызыксынмый иде кебек. Шулай тоелган гына икән. Күңелендә китапка карата мәхәббәт уты кабынган икән инде. «Тырышуларым юкка булмаган, файдасы тигән!» – дип уйладым эчемнән.

Балада китапка мәхәббәт уяну – интерактив рәвештә уку нәтиҗәсе дип уйлыйм. Хәзерге вакытта иң популяр алымнарның берсе санала бу. Әмма, баксаң, бу алымны безнең әби-бабаларыбыз әллә кайчан белгән инде! Оныклары белән китап укып утырган өлкәннәрне, мөгаен, сезнең дә күзәткәнегез бардыр. Алар бит мондый вакытта, беренче чиратта, бала белән аралаша. Бертуктаусыз аңа нindидер сораулар бирәләр яки баланың сорауларына үзләре җавап кайтаралар, рәсемнәрне тасвирлап, төрле авазлар, тавышлар чыгаралар яисә, бүлдермичә, баланы тыңлыйлар...

Бу хакта «Рожденный читать» китабында бик кызыклы итеп язылган. (Табарга, танышырга тырышы-

гыз әле!) Аны Америка журналисты Джейсон Буг үзенең кызы белән китап уку тәҗрибәсенә нигезләнеп язган. Ахырда, бала туганнан алып 6 яшькә кадәр укырга тиешле китаплар исемлеге дә китерелгән: минем үземә анысының да ярдәме тиде.

Балага китапны ул әле бишектә ятканда ук укый башларга кирәк. Мин үземнекеләрне алдыма куеп китап укый башлаганда алар әле берничә атналык кына иделәр. Озын әдәби әсәр укымадым, билгеле, рәсемле китап кына алдым. Каралы-аклы зур-зур рәсемле китапны, баладан 20-30 см ераклыкка куеп, тыныч тавыш белән тасвирлап чыгарга берничә минут вакыт җитә иде.

Беренче китаплар аңлаешлы, матур сурәтле булсын дип тырыштым. Балаларым үсә барган саен, китап уку вакыты да, китаплар да арта барды. Китапларның нинди телдә икәнлеге мөһим түгел иде – бары тик матур рәсемле булсын! Чөнки кайсы телдә язылса да, мин аларны барыбер татарчага тәрҗемә итеп укыдым. Укудан бигрәк, сөйләү иде бу. Кечкенә сабый да аңларлык ымлыклар, аваз ияртемнәре кушып сөйләү. Китаптагы рәсемнәрдә булган барлык персонажлар, предметлар, геройлар «телгә» килә, эмоцияләремне кушам, сорауларымны яудырам, җавапларын тыңлыйм яисә үзем үк җавап бирәм (монысы – баланың теле әле ачылмаган чакта)...

Гел китап белән генә утыра алмыйсың, кәефсез чагың да була, арган мәлләрең дә, бала үстергәндә вакыт та бик җитми диярсез. Андый очракларда мин рәсемнәрдә кемнәр, нәрсәләр сурәтләнгәнне санап кына чыга идем: бу да балага кызык, ул да аның игътибарын арттыра.

Малайлар үсә төшкәч, без укыган китапларны... сәхнәләштерә башладык. Үзенә күрә кечкенә генә «өй театры» барлыкка килде. Спектакльдә катнашучы «актерлар» – балаларның яраткан уенчыклары: лего, хайваннар, курчаклар, машиналар... Башта балаларга бик таныш булган, йә алар яраткан әкиятләрне сәхнәләштердем. Өйдәге спектакльләрнең нәтиҗәсен мин шунда ук күрдем: улларым китапларны үзләре мөстәкыйль рәвештә кулга алып, карап утыра яки укый башлады! Бер яшьлек Салихның «Ледяная избушка» әкиятен «укуын» видеога яздырган идек, хәзер карыйбыз да рәхәтләнеп көләбез. Тоташ ымлыклардан гына торса да, шактый «бай» эчтәлекле һәм бик хисле ул: «Аю лап-лап, Куян иии-ииии. Төлке ыыымм уух итте!..»

Соңрак әкият күрсәтүгә балалар үзләре дә тартылды. Белгән әкиятләрен сөйләп чыгу алардан зур осталык таләп итә, сөйләмнәрен, тел байлыкларын үстерә. Дүрт-биш яшьләр тирәсендә без гадәти укуга күчтек: алар инде озын-озын әкиятләрне дә сабырлары җитеп тыңлап тора алалар. Укыганда белмәгән сүзләр очраса, туктатып сорыйлар, китапта язганга кушып, искә төшкән, үзләре белән булган вакыйгаларны да сөйләп китәләр, фикерләрен уртаклашалар...

Дөресен әйткәндә, нәкъ менә шушы мизгелләр безнең арада нинди дер бер якынлык урнаштырды. Алар тормышында ни булганын белеп, тоеп тордым. Мәктәптән (яки балалар бакчасыннан соң) хәлләрен сорасаң, гел бер җавап ишетәсең: «Әйбәт!» Никадәр төпченсәң дә, шуннан ары башка бер сүз ала алмыйсың. Ә менә китап укыганда, үзләре дә оныткан хис-кичерешләрен искә төшерәләр, сөйләүдән тартынмыйлар, киресенчә, уртаклашырга телиләр.

Без әле дә кичләрен китап укыйбыз. Хәзер аларга күбрәк татар теленә тәрҗемә ителгән классик әсәрләрне укырга тырышам. Бу айда, мәсәлән, Даниэль Дефоның «Робинзон Крузо» әсәре белән танышабыз.

Олы улым Йосыф китапларны дүрт телдә (татар, рус, словак һәм инглиз телендә) үзе укый. Йота гына! Салих турында алай әйтә алмыйм, шулай да китапханәдән китаплар алып кайта, күптән түгел менә инглизчә укырга да теләге барлыгын белдерде.

Кечкенәбез – кызыбыз Зифа белән әлегә авыррак. Ул әлегә кадәр китап уку теләген белдермәде: тизрәк битне әйләндерергә, китапны ябарга гына тора иде. Уйлана торгач, моның сәбәбе үземдә икәнен аңладым. Абыйларының мәктәпләре, хоккейлары, драмтүгәрәкләре... аркасында Зифаны интерактив укудан мәхрүм иткәнмен ләбаса. «Гаебемне» аңлагач, бу эшкә дәртләнеп тотындым.

Маргарет Браунның инглиз телендәге «My world» һәм «Good night moon» дигән китапларыннан башладым. (Әйткәнемчә, безгә китапның кайсы телдә язылуы мөһим түгел, әмма олы балаларга бу да тел өйрәнергә бер стимул). Әлеге китаплар баланы искиткеч матур рәсемнәре, күп сюжетлылыгы белән хәйран калдырды. Укыган саен нинди дер яңалык белдек, яңа детальләр ача бардык. Без хәтта андагы персонажлар булып сөйләшә башладык: «Тычкан, анда менмә! Егылырсың! Учак янына якын утырма». Бер ай да үтмәде, Зифаны да китап дөньясы әсир итте. Хәзер кызым да көндез театр күрсәтеп, кичен абыйлары белән бергә зур әсәрләр тыңлый.

Интерактив уку – балаларны сөйләшергә, фикерләрен җиткерергә, әңгәмә корырга, уйланырга өйрәтү ысулы ул.

Галимнәр сигез төрле тикшеренү үткәреп, кызыклы бер нәтиҗә ясыйлар – интерактив китап уку баланың IQ күрсәткечен алты һәм тагын да күбрәк баллга күтәрә ала. Интерактив уку белән иртәрәк танышкан саен, баланың күрсәткечләре шуның кадәр югарырак була. Әлеге ысул белән китап укуда, шәхсән минем өчен иң кадерлесе, әйткәнемчә, баланың китап белән мавыгуы гына түгел, ә хәзерге тынгысыз заманда аның белән якын мөнәсәбәт урнашу, ихлас аралашу мөмкинлеге туу ул.

РУДАКЦИЯДӘН: Алимә СӘЛАХЕТДИНОВА – «Сабыйлар» балалар үзәгенә нигез салучыларның берсе, «Бишектән үстерү» дәресләренең методисты. Хәзерге вакытта гаиләсе белән Канадада яши.

PRESSA.RU



«1955 елның 24 мартында Таҗикстанның Дүшəмбе шəһəрендə туган татар егете Ринат АНИМАЕВ бүген Франциянең иң күренекле рəссамнарының берсе санала». Аның шəхси күргəзмəсе ачылу турында сөйлəүче буклет шушы сүзлəр белəн башланып китə... Узган елның көзендə Казанда узган ул күргəзмə өчен рəссам Казан каласы мэры Илсур Метшинга, Казан Ратушасы директоры Динə Латфуллинага, Туризмны үстерүгə ярдəм итү комитетыннан Евгения Лодвиговага һəм «Болгар Банк»ына рəхмəтле. Ə шушы күргəзмəдəн соң булган вакыйгалар өчен исə, мөгаен, язмышкадыр... Үткəннəр белəн ике арадагы пəрдə кинəт күтəрелер дə əтисе тормышындагы кайбер мизгеллəр ачылыр дип кем белгəн?! Хəер, барысын да тəртибе белəн сөйлик əле.

Лия ПРОНЭР, «Россия–Франция мəдəни күпере» ассоциациясенең вице-президенты



ҮТКƏННƏРДƏН БЕР КАЙТАВАЗ

Казаннан соң рəссамның эшлəре Мəскəүгə «күченде». 7 декабрь көнне «Дом на Патриарших» Мəдəният үзəгендə аның күргəзмəсе янə үз ишеклəрен ачты.

Нəкъ менə Мəскəүдəге күргəзмəне оештыру мəшəкатьлəре белəн йөргəн көннəрдə Ринатның электрон почтасына Казаннан, Əминə Арслановадан хат килеп төшə. «Дус кызларым белəн бергəлəп сезнең күргəзмəне карау бəхетенə ирештем. Əле дə шул тəэсирлəр белəн йөргəн көнем», – дип башлана ул. Аннан Əминə ханым, сүзен дəвам итеп, читлəтеп кенə сорау бирə: «Ə сезнең Казанда туганнарыгыз юкмы? – ди ул. – Мин «Сəламəт яшəү рəвеше» клубының оештыручысы булам. Дамира апа инде безгə күптəннəн йөри. Дамира Али кызы Анимаева. Аңа инде 82 яшь, Казанда туган, гомер буе шушында яшəгəн. Сезнең арада ниндидер туганлык җеплəре бардыр кебек

тоела миңа». Ринат башта бер мәлгә аптырап кала: кем булырга мөмкин бу апа, әтисе сөйләве буенча аның бөтен гомере Үзбәкстан белән генә бәйле ләбаса, ә монда бер үк фамилия. Сирәк очрый торган фамилия... Ике арада хатлар йөри башлый. Казан ягына сорау арты сорау ява, телефон аша да хәбәрләшәләр. Ниһаять, Әминә ханым аңа Дамираның әтисе белән әнисе бергә төшкән фотосурәтне җибәрә. Аның мондый яшь, чибәр ир-егет чагын Ринат белмәсә, хәтерләмәсә дә, ялгышу берничек тә мөмкин түгел, бу – ул, аның әтисе. Тик нигә Казанда яшәүче Дамира апа да аны «әти» дип атый һәм исемен «Али» ди? Җавабы булмаган сораулар күңелдә туа торса да, бер нәрсә анык – Дамира апа белән алар бертуганнар... Әтисе үзе белән мәңгелеккә ниндидер сер алып киткән, димәк...

Ринат күп балалы гаиләдә җиденче бала булып дөньяга килә. Әтисе Мансур Анимаев – рәссам, ә әнисе Сәлимә ханым Усманова-Анимаева хуҗабикә була. Балачак хатирәләре турында Ринат үзенең китабында болай дип искә төшерә: «Гаиләбез шактый зур иде безнең. Өебездә тормыш гел кайнап торды: бәхәсләр туган чаклар да булды, хакыйкать тә эзләдек, кайсыбызныдыр мактадылар, шелтә дә эләкте... Әмма әти белән әнине иң мәрхәмәтле, иң шәфкатьле җаннар дип хәтерләп калганмын. Ниндидер тавыш-гауга, яшерен серләр безнең бусаганы беркайчан атлап узмады». Нәкъ илле елдан соң әтисенең берәү дә белмәгән серенә тап булачагы кайдан башына килсен соң аның? Һәм Казанда узган шәхси күргәзмәсе моңа этәргеч булачагы – бигрәк тә.


Күргәзмә турында кабат сүз чыккач, аз гына читкә китеп, аның ничек итеп Казанга килеп эләгү тарихы турында да сөйләп узыйм әле. Мин үзем рәссам Ринат Анимаевның арт-директоры булам. Без аның белән Парижда, биредәге татар диаспорасы очрашуларының берсендә таныштык. (Франция татарлары бер гаилә кебек яшибез без монда. Еш кына күрешәбез, бәйрәмнәрне бергә үткәрәбез. Әле күптән түгел Россия илчелегендә «Европа татарлары альянсы»ның чираттагы съездын үткәрдек. Килгән кунаклар өчен без анда Ринат Анимаевның алтмыш картинасы куелган күргәзмә дә әзерләдек.)

Казан каласына беренче тапкыр аяк басуга ук, Ринатның иҗат эшләрен бирегә китертү хакында хыяллана башладым. Татарстанга минем килүем дә юкка булмаган, боларны хәзер генә аңлыйм... Ул чакта Париждан Казанга Владимир Высоцкийны искә алу кичәсенә чакырганнар иде. Кичә «Социалистик көнкүреш» музеенда узды, без анда җырчының Париждагы эзләре турында сөйләүче кыска метражлы фильм күрсәттек. Әлеге фильмны оператор Николай Головихин белән «Социалистик көнкүреш» музее директоры Рөстәм Вәлиәхмәтов катнашында төшердек. Казанны мин бер күрүдә яраттым: татар халкының искиткеч кунакчыллыгын, борынгы каланың гаҗәеп матурлыгын, аның үткәнен, бүгенгесен, архитектура һәйкәлләрен... Кешеләрен! Шул килүемдә үк әллә никадәр яңа танышлар таптым, соңрак алар миңа Ринат Анимаев белән бәйле проектны тормышка ашырырга ярдәм итте дә инде.

Казанга менә шушылай – шәхси күргәзмә белән кайту Ринатның да күптәнге хыялы иде. Сөйләшкән вакытларда мин бу хакта аңардан күп тапкырлар ишеттем. «Әби-бабаларым туфрагы, әтиемнең туган җире бит бу!» – дип кабатлый иде ул. Казанда Ринат үз гомерендә бер генә тапкыр булган. 1981 елның ноябрь ахырында ул – В. И. Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институты студенты, Татарстанның башкаласына үзенең дуслары белән бергә атаклы рәссам, скульптор, графика остасы, импрессионизм һәм модерн тарафдары Николай Иванович Фешинның йөз еллык юбилеен бәйрәм итү тантанасына килә.

Икеләнергә урын калмый: рәсемнән Ринатка әтисе Мансур Анимаев карап тора.

Казанда туган бөек рәссамның күргәзмәсе ул чакта Татарстанның сынлы сәнгать музеенда уза. Казан сәнгать училищесын тәмамлаган рәссамнарның күбесе белән Ринат нәкъ менә шул чагында танышып кала, соңыннан аралашулар Мәскәүдә, чит илләрдә дәвам итә. Казанга «кайту» хыялы, «мин монда тагын киләм әле» дигән уй күңелгә шул вакытта ук кереп урнаша һәм гомер буе үзенә тартып, чакырып тора. Әйткәнемчә, сиксәненче еллар башы әле бу. Ринат алда



■ Әтисе иҗат иткән картиналар арасында үскән, буяулар тудырган могҗиза белән кечкенәдән очрашкан, киндергә төшкән һәр сызыкка таң калган, сокланган, шуның серен ачарга омтылган Ринатның рәссам һөнәрен сайлавы бер дә гаҗәп түгел.

PRESSA.RU

үзен ни көткәнен дә, тормыш сукмаклары аны кайларга алып барып чыгарасын да, үзенең иҗатта ниләргә ирешәсен дә – берсен дә белми...

Кызганыч, Казан тамашачысына иҗатын, әсәрләрен Ринат үзе тәкъдим итә алмады. Татарстанда шәхси күргәзмәсе эшләячәк көннәр билгеле булганчы ук ул Франциядәге галереялар белән контракт төзергә өлгергән иде инде. Россиядәге күргәзмәләрен аның исеменнән миңа оештырып йөрергә туры килде. Проект өстендә без икәү бергә эшләдек. Күргәзмәнең темасы да үзеннән-үзе шунда ук туды: «Дүрт фасыл» дип атадык без аны. Ринат: «Табигатьнең һәр фасылы матур, берсен-берсе кабатламый, картина өчен сайлаган сюжет рәссамның кәефенә бәйле түгел», – дигән фикердә тора. Рәссамның шәхси коллекциясеннән иң яраткан йөз эшен икәү сайлап алдык та күргәзмә сәяхәткә кузгалды...

Якын кешеләр, газиз җаннар соң булса да, бер очрашырга тиеш!

Ниһаять, күргәзмә үзенең ишекләрен ачты. Казанның үзәгендә урнашкан иң матур биналарның берсендә – шәһәр Ратушасында! Ике ай буе теләгән һәркем килеп аны карый, останың иҗат җимешләре белән якыннан таныша алды.

Инде алдарак сөйли башлаган сүзебезгә кире кайтыйк. Күргәзмә гел көтелмәгән вакыйга – ике якын кешенең бер-берсен табуы белән тәгәлләнде. Әтиләре берәүгә дә ачмаган серне дә чишәргә вакыттыр.

...1933 елның 25 гыйнварында Сара һәм Али Анимаевлар гаиләсендә икенче бала дөньяга килә. Тагын бер кыз. Бәләкәчкә Дамира дип исем кушалар. 1934 елны әтиләрен беренче тапкыр кулга алганны кечкенә Дамира, әлбәттә, хәтерләми. Бу хакта өлкәннәр сөйләгәннәрдән генә белә. Казан шәһәре Башкарма комитетында эшләгән Али Анимаевны ул чакта тоткынлыкта озак тотмыйлар. Әмма нәкъ ике елдан барысы да өр-яңадан кабатлана: бу юлы инде аны төрмәгә үк ябалар. Озакламый исә «атарга» дигән хөкем карары да билгеле була. Нигә, ни өчен, әтиләренең нинди гаебе бар? Гаиләсе бу сорауларның берсенә дә җавап таба алмый. Тик мондый сорауларга җавап эзләп йөри торган вакытмыни?! Коточкыч хөкем карары турында аларга хәбәр китергән хатта аңлаган кешегә төшенерлек итеп язганнар бит – сәяси сәбәпләр аркасында дигәннәр.

Озакламый әниләре ире белән аерылышу турындагы кәгазьгә кул куеп кайта. Нигә икәне аңлашыла инде... 1921–1954 еллар дәвамында СССРда барган сәяси репрессияләр аркасында күпме гаиләләр таркалуын, ул чордагы тоталитар режимның никадәр язмышларны җимерүен кем исәпкә алган да, кем санаган?! Нишләтәсең, ачы язмыш Анимаевларны да читләтеп үтми менә... Берсеннән-берсе кечкенә ике бала белән ялгыз калган әниләре Сараның ничекләр итеп яшәргә тырышу-тырмашуы, авыр көннәрне кичерүе – үзе бер тарих.

Әнисе һәм апасы белән генә үскән Дамира гомер буе әтисе бу дөньяда юк, күптән атып үтерелгән дип яши. Балачагы турында күз яшьләрсез искә дә төшерә алмый ул. Ачлык, ялангачлык, юклык... Ә аннан алар гаиләсенә кабат коточкыч кайгы килә: уналты яшендә апасы үлеп китә. Сугыш тәмамланган елны була бу хәл. Мондый көтелмәгән хәсрәттән тәпчек кыз бер көн эчендә олыгая. Әнисенең бердәнбер ярдәмчесенә, таянычына әйләнә. Һәм гомер буе шулай була. Кайгыда да, шатлыкта да алар бер-берсенә терәк булып яшиләр. Гаилә корырга да ашыкмый ул: башта укый, аннан эшкә урнаша, аннан инде әнисен ялгыз калдырырга теләми. Еллар, бер-бер артлы тезелеп, узалар да узалар. Әтисенең күз алдындагы томанлы сурәте дә вакыт үткән саен ерагая, тоныклана бара. Гаилә альбомын актарганда гына, балачакта әти янәшәсендә бергә үткәргән бәхетле көннәр, онытылыр-онытылмас ул хатирәләр кабат искә төшкәндәй була. Күңелдә үкенечле уйлар кузгалып куя: әгәр әтисен кулга алмасалар, атып үтермәсәләр, әтисе белән әнисе аерылышмасалар, сугыш килеп чыкмаса, аның язмышы ничегрәк язылыр иде икән?!

Әтисе турында бик аз белә Дамира апа. Әтисенең әтисе, ягъни бабасының исеме Исхак икәне мәгълүм. Фамилиясе... анысын әтиләре үзе дә хәтерләми торган була. Казанда ишан булып торган Исхак хәзрәтне революция елларында большевиклар атып үтерә. Ә аның өч баласын – Алины, абыйсын һәм сеңлесен нинди дер танышлары үзләрендә качырып тоталар, ә аннан, бәладән ераграк булсыннар диптер, Үзбәкстан якларына озаталар. Фамилияләрен отып калырга ул вакытта әтиләре кечерәк була шул...

Ә Анимаев фамилиясе... Үзбәкстанда ятим балаларны бер гаилә тәрбиягә ала. Яңа йортта беренче тапкыр өстәл янына утыруга балалар өчесе беравыздан: «Әни, май бир!» – диләр. Күптән күрмәгән ак май ачлык кичергән сабыйларга иң зур нигъмәт булып тоелгандыр инде... «Әни, май!» сүзе аларга озакка ябыша: документлар алганда яңа әти-әниләре туганнарны «Анимаевлар» дип яздыра. Үткәннең кара шәүләсе ияреп йөрмәсен, зыян салмасын, алар кичергән фаҗигане бернәрсә дә искә төшермәсен дигәннәрдер инде. Боларын әтисе сөйләгәннәрдән рәссам Ринат Анимаев хәтерли.

Әтиләре Үзбәкстанда үсә. Әмма күзгә күренмәгән генетик хәтер җепләре аны барыбер әби-бабасы, әти-әнисе туфрагына – Казанга тарта. Унсигез яше тулгач, абыйсы белән сеңлесенә: «Әйдәгез, Казанга кайтыйк!» – ди ул. Тәвәккәлле егет. Шул мизгелдән аның тормышында яңа чор башлана. Казаннан чыгып киткәндәге фамилия күптән онытылган, өстәвенә, ул исемен дә алыштырган. Мансур туган ягына Али Анимаев булып кайтып төшә. Исемен үзгәртүе үткәннәрдән эзне тагын да ныграк яшерү өчен кирәк булдымы икән? Мөгаен, шулайдыр. Кайта, эшкә урнаша, аннан укырга керә. Беренче мәхәббәтен очрата. Тормыш шулай бер эздән агар да агар иде дә бит... Советлар Союзы тари-

хында каһәрле 30 нчы, 40 нчы еллар булмаса... Барысы да кабаттан җимерелә... Казандагы гаиләсенә килеп ирешкән «атылды» дигән хәбәр ялгыш булып чыга – монысының тарихын әлегә Ринат та, Дамира апа да белмиләр. Төрмәдән ул сугыш башланыр алдыннан чыга, әмма Казанга инде кире әйләнеп кайтмый. Бөек Ватан сугышы башлануга фронтка китә. Сугышның буеннан-буена кичеп, медальләр белән бүләкләнеп Җиңү таңын каршылый. Ә аннан... кабат Үзбәкстанга юл ала. Балачагы һәм яшьлеге үткән җиргә. Һәм кабат... Мансур булып. Әтисе белән әнисе туугa үзенә кушкан исемне кире ала һәм тормышны яңадән ак кәгазьдән башлый. Әмма Үзбәкстанда эш таба алмый һәм Таҗикстанга, Дүшәмбе шәһәренә барып урнаша. Язгы җылы кичләрнең берсендә юлында Сәлимәне очрата. Тыйнак, сабыр, тыныч кызны шунда ук үз итә. Сөйкемле татар кызы якташы да булып чыга – ике апасы белән алар Татарстанның Чистай районыннан Таҗикстанга утызынчы елларда күчеп килгәннәр икән. Яшь кыз дип уйлап кына ялгыша: егерме алты яшьлек Сәлимә инде фронтта ирен югалтырга өлгергән, кулында ике кечкенә бала – Миңсылу белән Йолдыз. Алар өйләнешәләр, уртак никахтан тагын биш балалары туа – ике кыз һәм өч малай. Ринат – шушы зур гаиләнең төпчеге. Ишле гаиләсен туендыру өчен Мансур ага көне-төне эштә була: сәнгать остаханәләрен җитәкли, бизәүче булып эшли, бик күп иҗат итә. «Әти һәрвакыт иректе рәссам булу турында хыялланды. – Бу юллар Ринатның балачак хатирәләреннән. – Безнең өйдә, акка буялган диварларда, бөтен җирдә аның эшләре эленгән иде. Әтинең белмәгәне юк: үзенә генә мәгълүм рецептлар буенча буяуларны ул үзе ясый. Моның өчен буяу матдәләрен – пигментларны таулардан җыя, мамык маенда аларны изә».

Ринатта әтисенең 1949 елны ясаган натюрморты сакланып калган. Бер кисәк кара икмәк һәм ике помидор сурәтләнгән анда. Тормышның иң авыр елларының хатирәсе менә шул инде ул... Әтисенең тагын ике эшен бик яхшы хәтерли рәссам. Аның берсендә – җәйге пейзаж: зәп-зәңгәр күктә ап-ак болытлар. Болары тамашачыны күз күрмәгән ерак тарафларга алып китә. Ике якта тоташ стена булып баскан урман. Агачларның куелыгы, караңгылыгы үзенә тарта – әйтерсең лә, үткәндә калган нindидер яшерен серләрне белергә чакыра. Һәм күз кинәт уртага, ташлар арасыннан челтерәп агып ятучы саф сулы чишмәгә төшә. Монысы – матур киләчәккә ишарә... Пейзажларның икенчесендә – кыш. Авыл өе морҗасыннан төтен күтәрелә, кар юеш, йорт янында атлы чана... Еракта калган Ватанны сагыну менә нинди булган ул! Арттарак, урман өстендә кышкы сүрән кояш бата... Иртәгә ул кабат чыгачак, димәк, киләчәккә – матур киләчәккә өмет бар! Рәссам өчен аның һәр картинасы күңел көзгесе кебек: аны әйләндереп алган тирә-юнь күренешләре, гомернең бер мизгелендә тотып алган һәм киндердә туктап калган образсурәт бит анда.

Сәнгать мәктәбенә ун яшендә, әтисе вафат булганнан соң керә Ринат. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Дүшәмбе сәнгать училищесында белем ала. Аннан – Мәскәү. Инде студент чагында ук күргәзмәләрдә катнаша. 1989 елдан бирле ул Франциядә яши, иҗат итә. Аның кылкаләме бик күп билгеле шәхесләрнең портретларын тудырган. Арада атаклы сәясәтчеләр, артистлар... «Аларның һәркайсы белән мине язмыш очраштырды», – дип саный Ринат.

Язмыш... Бу юлы ул менә аңа әтисенең үткәндәге серен ачарга булышты. Ринатның «Казанга кайтам» дигән күптәнге хыялы чынга ашмаса, күргәзмәсен оештырырга булышырлык кешеләр табылып тормаса, аның картиналарын күрергә дип, Ратушага Әминә ханым Арсланова кермәсә, аннан тәвәккәлләп рәссамга хат язмаса... Дамира апаның тормышында да берни үзгәрмәс иде, мөгаен. Бу дөньяда мин япа-ялгызым, дип, яшәр дә яшәр иде... Инде барысы да ачыклангач, Дамира апаның иң беренче теләге, әлбәттә, туганнары белән очрашу була. Озакка сузмыйча, билет алып, Мәскәүгә чыгып китә ул. Мәскәүдә Ринатның ике абыйсы – Эдуард белән Әнвәр, апасы Гөлсем, Ринатның уллары Тимур белән Мансур, оныклары яши. Апаларын Казан вокзалында туганнар барысы бергә җыелып килеп каршылыйлар. Күрешүгә ул үзен Ринатның күргәзмәсенә алып баруларын үтенә. «Дамира апа шатлыгыннан шулкадәр дулкынланды, каушады, елады да елады, хәтта сөйләшә дә алмады – тавышына кадәр утырды», – диде Ринатның апасы Гөлсем.

Тормыш матур дип санаган җирдә хыяллар чынга ашмый калмый...

Күргәзмәне Дамира апа бик озаклап, сүзсез генә карап йөри. Бары аннан соң гына: «Ринатның эшләре миңа шулкадәр якын.... Энемнең җанын, күңелен, холкын тоям, ә рәсемнәреннән бөркелгән җылылык ерак балачагыма алып китә», – ди.

Түгәрәк өстәл янында, кичке аш вакытында туганнар якыннанрак танышалар, Дамира апаны скайп аша Ринат белән дә «очраштыралар». Телдә исә гел әтиләре була... Фотосурәтләр карыйлар, хатирәләр уртаклашалар. Сөйләшеп сүз бетми. Дистә еллар буе ялгыз яшәп, кинәт кенә «апа»га әйләнгән, эне-сеңелләргә баеган Дамира апаның күңел халәтен аңлау авыр түгел...

Гомер – каралама түгел, аны әр-яңадан күчереп «яза» да, сызып ташлап, яңадан башлый да алмыйсың. Шуңа күрә яшәлгән һәр көннең кадерен белү кирәктер. Тормышыбызда булган вакыйгаларны билгеле бер төскә күп вакыт без үзебез буйыйбыз. Ә бит буяуларның ачыграк, яктырак, җетерәк төсләрен кушу да мөмкин ләбаса. Ринат Анимаев иҗат иткән картиналардагы кебек. Яктыга якты тартыла, монысы да әллә кайчан мәгълүм.

РЕДАКЦИЯДӘН: рәссам Ринат Анимаев белән «Рәссам сәхифәсе»ндә таныша аласыз.

PRESSA.RU

БЕЗНЕҢ ҺƏМ СЕЗНЕҢ ФИРҮЗƏ



Гөлнур ХƏСƏНШИНА

«БЕЗНЕҢ ФИРҮЗƏ», – ДИП ЙӨРТƏБЕЗ БЕЗ АНЫ. ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИҢ ЗУР БҮЛƏГЕНƏ – «СӨЕМБИКƏ БЕЛƏЗЕГЕ»НƏ ИЯ БУЛГАН ФИРҮЗƏНЕ БАШКАЧА НИЧЕК АТЫЙСЫҢ?!

Хәер, ул сезнеке дә. «Татарстан–Яңа гасыр» телеканалының Оренбург өлкәсендәге үз хәбәрчесе Фирүзә ӘБСӘЛӘМОВАның ягымлы тавышын күптән таныйсыздыр. «Азатлык» радиосының Оренбург өлкәсе буенча үз хәбәрчесе булып эшләгән чакларыннан ук...

– Менә ул безнең Каргалы!

Билдән кар ерып, эчкә уздык та, тау битенәрәк – кылганнар җилдә тирбәлеп утырган урынга ук күтәрелдек. Моннан авыл уч төбендәге кебек күренә. Каргалы... Бөтен татар дөньясына билгеле атаклы Татар Каргалысы... Фирүзәнең туган авылы...

Оренбург якларына барып чыккан кеше Каргалыны да, аның күз күреме җиткән кадәр сузылган борынгы зиратларын да күрми китми инде. Татарстаннан килгән кунаклар өчен алыштыргысыз «экскурсовод» исә гел бер – Фирүзә. Моннан унбиш ел элек без дә аның белән шулай танышкан идек. «Ырынбур кала»дагы татар эзләре буенча йөртүче, анда гомер итүче милләттәшләребез белән якыннан таныштыручы, әйе, Фирүзә булды. Татар-башкорт зыялылары өчен ул оештырган «Замандаш» клубына редакциябез әллә ничә тапкыр кунак булып барды – Оренбургтагы укучыларыбыз белән күзгә-күз очрашты.

Фирүзә Оренбургтагы татар дөньясы эчендә кайнап яши. «Минем телефон номеры «Ашыгыч ярдәм» машинасыныкы кебек – аны бөтен кеше белә», – дип көлә ул. Әйе, белә һәм нинди генә чара үткәрсә дә, иң элек аңа чакыру сала. Аннан инде бу хакта «Яңа гасыр–Планета» бөтен татар дөньясына ишеттерә.

Үзе хакында сөйләшәбез дип тотынган идек... Ә әңгәмәбез барыбер Оренбург татарлары турында килеп чыкты шикелле. Мин моңа әллә ни шаккатмадым.

Кадр артындагы, кадрга сыймаган юллар. Бу язманы шулай да атап булыр иде.

* * *

Камерага сөйләгәндә күпләр каушый. Без инде анысына иялләшкән – әңгәмәдәшеңне тынычландыруның мең дә бер ысулы бар: кайсын булса да кулланасың. Ә менә мондый очрак бер генә булды! Переволоцкий районы Чесноковка авылында яшәүче эшкуар Рөстәм Исәнбәтов турында сюжет төшерергә җыендык. Алдан шалтыратып үзе белән сөйләштем, ризалашты. Алтмыш чакрым узып килдек, ә ул: «Юк, төшмим!» – ди. Берничек күнми! Мондый «кызык» хәлгә калганым юк иде... Рөстәмнең укытучысы Нурия Камиловнаны белә, аңа шалтыраттым. (Юк, юк, кире борылып китү уема да кермәде. Булмаганны!) Нурия ханым аңа нинди сүз әйткәндер, белмим, әмма Рөстәм минут эчендә үзгәрде дә куйды... Икмәк пешереп сата ул, каз-үрдәк тә үстерә. Бу якның иң зур меценаты дип атыйлар аны. Аңа рәхмәтле кешеләрне шактый очраттык. «Мәктәптә нинди проблема килеп чыкса да, Рөстәмгә мөрәҗәгать итәбез», – диләр укытучылар. Тирәюнь авыллардагы бөтен ятим баланы белә, ярдәм итә икән. Җиңүнең 70 еллыгы алдыннан авылдашларына зур бүләк әзерләгән – Чесноковка уртасындагы һәйкәлне яңарткан.

Икмәк пешерү комбинатын да карадык, үрдәкләрен дә барып күрдек – үрдәк йомыркаларын Франциядән кадәр кайтарта икән Рөстәм! Кыскасы, сюжет кызыклы гына килеп чыкты. Шуннан соң аны «Татар эшкуарлары ассоциациясе»нә алдылар. Ә бер очрашкач, ул: «Сине бүген телевизордан күрдем!» – дип, Казакъстаннан армиядә бергә хезмәт иткән дустым – казакъ егете шалтыратты. «Яңа гасыр»ны анда да карыйлар икән! Күптән хәбәрләшмәгән идек», – дип сөйләде. Сюжетыбызны ничек төшерә башлавыбызны искә алып елмаеп куйдым...

> *Өлкәдәге татар авыллары пөхтәлекләре, яңа төзелгән йортларның күплеге белән аерылып тора.*

* * *

Иң авыр командировка... 2008 елны Беляевка районында урта мәктәп ишелде. Унберенче сыйныфта укучы биш кыз хәрабәләр астында калып һәлак булды. Аларның икесе татар кызы иде... Мин ул чакта «Азатлык»ның үз хәбәрчесе булып эшлим. Санаулы сәгатьләр эчендә фаҗига булган урынга барып җиттек... Ә тагын ун айдан шул ук авылга яңа мәктәп ачылу тантанасын төшерергә бардык. Күз яшьле мондый бәйрәмне башка хәтерләмим – мәрхүм балаларның барысының да әниләре килгән иде. Кызларның берсе – Зинира Исхакова – Алабайтал авылыннан. Без ул көнне зиратка аның кабере янына кердек, мәктәпкә сугылдык, аның партасы артында утырдык. Күз яшьләре ул көнне ирексездән акты да акты...







PRESSA.RU

* * *

Өлкəбездə җитмешкə якын татар авылы бар. Һəммəсен дə йөреп чыктым дисəм... Орск якларына барып җиткəнем юк менə. Оренбургтан дүрт сəгатьлек юл ул. Мирхəйдəр Фəйзинең туган ягы. Закир Рəмиевнең соңгы көннəре шунда узган – ачлыкта, хəерчелектə.... Ул күмелгəн татар зираты өстенə хəзер завод салынган. Кабер ташларын эттереп кенə куйганнар да... Безнең як эшкуарлары анда берəр бинага истəлек тактасы кую турында сүз алып бара.

Элеккеге татар тормышын Каргалыда төшереп булыр иде. Иске базар урыннары, таш коймалар...

Əйе, татар авылларында ят кеше түгелмен. Кайберлəрен инде əллə ничə кат ураганмын. Əле менə Шарлык районы Мостафа авылыннан кайттым. Белəсез инде, Җəлилебез туган җир ул... Соңгы тапкыр өч ел элек килгəн идем Мостафага. Авыл əллə ни үзгəрмəгəн кебек. Əмма бу тышкы яктан гына! Оренбургта, «Хөсəения» мəчетендə имам ярдəмчесе булып торган Мидəт Рəмиев (аның бер як нəсел буыны – Муса Җəлилгə, икенчесе Закир һəм Сəгыйть Рəмиевлəргə барып тоташа) авылга кайтып төплəнгəн. Һəм авылдашларына дин сабагы укыта башлаган. Мостафа халкының яртысыннан артыгы бүген намазда! Башта хатын-кызлар, аннары балалар, иң соңыннан ир-атлар уянган... Шаккаттым: авыл халкы бөтенлəй башка! Тырыш, акыллы халык яши анда, əмма һəркайсы үз эченə биклəнгəн иде. Ə хəзер битарафлык киткəн алардан, бөтен нəрсəдə гамьнəре бар, ачыклар. Башка авылга элəккəн кебек булдым... (Мидəт аганың өч ел буе бушлай укытып йөргəн ишетеп кайткач, өлкəбезнең мөфтие Əлфит хəзрəт Шəрипов белəн очраштым. Аз гына булса да хезмəт хакы билгелəү мөмкинлеге таптылар. Əмма хикмəт башкада!)

* * *

Əйе, журналист өчен иң рəхəте – үз эшенең ниндидер бер сизелерлек нəтиҗəсен күрү.

Узган ел Абдулин районына караган Габдрахман авылында мəктəпне яптылар. (Мөсəгыйт ага Хəбибуллинның туган авылы бу.) Бер мəктəп тə Оренбург өлкəсендə болай авыр ябылмады... (Өлкəнең мəгариф министры əйткəн сүзлəр, укучылар алдында укытучылардан кайбер хəрефлəрне əйттереп каравы тирəсендə купкан ыгы-зыгыны хəтерлисездер əле.)

Оренбургтан Габдрахман авылына кадəр 350 чакрым. Иртүк барып җиттек. Мəктəп ишегенə бик эленгəч, авыл бушап, ятим калган кебек. Егерме ике бала күрше чуаш авылына йөреп укыячак. Аларны алырга автобус килде. Тукталышка халык җыелды. Укытучылар елый... Татар теле моңарчы аларда дəрес итеп укытылган, хəзер түгəрəк буларак кына калачак. Николькино урта мəктəбе директоры Вячеслав Кузьмин: «Башлангыч сыйныфларга татар теле укуны дəвам итəргə мөмкинлек бирəбез», – ди. Шул рəвешле татар теле укытыр өчен башлангыч сыйныфлар укытучысы Лəйлə Кəримова да укучылары белəн күрше авылга «күчкəн». Укучылары Татарстанга килеп, татар теле һəм əдəбияты буенча олимпиадаларда җиңеп кайткан укытучы ул. Ике катлы мəктəптə тирə-күрше авыллардан килгəн җитмешлəп бала укыячак. Лəйлə укытачак сыйныфка да сугылдык. Баксаң, ул монда да бер класс бүлмəсендə берьюлы ике сыйныф укытачак икəн. Нəкъ Габдрахмандагы кебек. Ике мəктəпне берлəштерүдəн укучылар берни отмаган булып чыга түгелме соң? Кичен: «Мəктəптəн алган тəэсирлəрегезне белəсе килə», – дип, Абдулин районының мəгариф бүлеге мөдире шалтыраткач та, иң элек шул хакта əйттем. Ə икенче көнне министрның карарын ирештерделəр: Лəйлə Кəримова берьюлы бер генə сыйныф укытачак. Укытучының ничеклəр сөенгəнен белсəгез иде: «Мин бу хакта егерме ел хыялландым!» – ди.

Сез: «Мəктəпне кире ачтылар», – диюемне көткəнсездер инде... Юк шул, башта ук: «Бу мəсьəлə инде тəмам хəл ителгəн», – диделəр. Кызганыч, Абдулин районында гына да былтыр өч татар мəктəбе ябылды...

* * *

Иң хəтəр командировка... Туксанынчы еллар иде. Шарлык районы Яңа Муса авылына мəктəп турында тапшыру əзерлəргə бардым. Шул авыл кызы Мəрьям Даутова белəн Казанда бергə укыдык – кичтəн килеп, аның əнилəрендə кунарга ниятлəдем. Автобустан төшеп калдым. Коеп яңгыр ява. Күзгə төртсəң күренмəслек караңгы. Атлый гына башлаган идем, кинəт: «Тукта!» – дигəн тавыш яңгырады. Баксаң, электр чыбыгы өзелгəн, шуңа авылда ут беткəн, ə миңа шул чыбыкларга басарга берничə генə адым калган... Гомер бетмəгəч! Бер мəрхəмəтле агай, ул-бу булмасын дип, яңгыр астында үткəн-сүткəннəрне кисəтеп тормаса... Җиде-сигез килограммлы магнито-





фон күтәреп йөргән чаклар әле бу. «Азатлык»та эшли башлагач, цифрлы диктофон бирделәр. Безнең телерадиокомпаниядә беркемдә юк иде андый! «Бигрәк җайлы икән», – дип, аннары компания рәисе Павел Рыков үзенә кайтартты шундыйны. «Татарстан–Яңа гасыр» белән башта биш ел килешү нигезендә генә эшләдек. Машина юк, камера да... Барысын үзеңә табарга. Оренбург өлкәсенең Дума депутаты, Әсәкәй егете Илдус Дәүләтов белән эшмәкәр Нурия Кәримова, кушылып, камера алып бирделәр, рәхмәт аларга. Сүз уңаеннан, мин озак еллар Оренбургның иң яхшы операторы Рафаэль абый Хәялин белән эшләдем! Тарихны аның кебек белгән кешене эзләргә кирәк әле! Каргалыга нигез салган Сәгыйть Хәялин нәселеннән ул. Былтыр алар энесе Равил белән Сәгыйть бабалары каберенә таш куйдылар. Әллә унынчы, әллә тугызынчы буын вәкилләре!

* * *

Кызык хәлләр... Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлап кайтканнан соң, Каргалы мәктәбендә ун ел татар теле һәм әдәбияты укыттым. Аннан туксанынчы еллар җитте – милли күтәрелеш башланды. Радиога татарча тапшырулар алып барырга чакыргач, тәвәккәлләдем. Ул чакта өлкә татарларын бәхет басты – алар көн саен татарча тапшырулар тыңлады. Гөлүсә Мөшәрәпова белән барысына да өлгерергә тырыштык. Безнең якларның «аяклы тарихы» Мәдинә апа Рәхимкулова күңелендәге истәлек-хатирәләрне тасмага шактый яздырдык. Дин әһелләренең вәгазьләрен җиткердек. Оренбург татар театры артистлары белән радиоспектакльләр куйдык.

Каргалыдан Оренбургка эшкә көн саен автобус белән йөрим. Әлбәттә, таныйлар. Беркөнне автобус кузгалуга шофер радионы кабызды. Салонда минем тавыш яңгырый башлады... Бөтен халык сүзсез генә миңа таба борылды... «Алдан язылган ул, туры эфир түгел», – дим...

«Хәерле кич», «Якташлар», «Мое родное Оренбуржье» кебек тапшырулар хәзер зәңгәр экраннан, эфирдан югалды. Университетта, педагогика көллиятендә (мин анда татар теле укытып та йөрдем әле) ачылган татар бүлекләре дә бер-бер артлы ябылды. Сәясәт гел үзгәреп тора шул... Болары инде кызганыч хәлләргә карый...

* * *

Сәер хәлләр... Ике мең кеше яши торган Заглядино авылында Ришат Галимов дигән егет мәчет салдырды. (Оренбург өлкәсендә иң кыска вакыт эчендә – тугыз айда төзелгән мәчет!)

Ришат – өлкәбезнең алдынгы фермеры. Игелек кылу дигәндә, малын җәлләми. Аның бригадирлары да ул алып биргән машинада йөри. Мәчетне тышлатырга да ташларны Кавказдан кадәр кайтарткан. Халык барысы өчен дә рәхмәтле аңа – мәчеткә Ришатның күптән түгел вафат булган әтисе Мөхәммәднең исемен кушу тәкъдиме белән юкка чыкмаганнар. Мәчет ачылышын төшерергә без дә бардык.

Ишелеп-ишелеп юеш кар ява. Килгән кешеләр кулчатырлар күтәрде. Без нишләрбез – камера кызганыч бит... Тәрәзә ачып, шуннан гына төшербез инде, дибез. Эшкә тотындык. Ир-атлар тәкбир әйтә башлаган иде – кар туктады! Могҗиза! Ике янәшә кадр: берсендә – кар ява, икенчесендә – берни юк! Икесе ике көнне төшерелгән дип уйларсың...

* * *

Каргалының кайсы чорында яшәр идемме? Сәүдәгәрләр яңа килеп урнашкан, авылга нигез салган вакыттадыр. Гомумән, һәрнәрсәнең башында тору ошый – сукмакны үзең салу – тапталган юлдан үтүгә караганда, кызыграк... Урынны сайлый белгәннәр безнең бабайлар. Авыл кырыеннан Сакмар елгасы ага. Шәһәргә дә якын. Узган ел Каргалыда Федераль Сабантуй үткәрү авылга яңа сулыш өрде. Өлкә бюджетыннан шактый зур күләмдә акча бүлеп бирделәр. Мәктәпне төзекләндерергә – 75 миллион, клубка – 15 миллион сум, урамнарга яңа асфальт салынды... Кемгә тигән бу бәхет?! Губернатор көн саен Каргалыга килеп, әзерлекне үзе тикшереп йөрде. Бөтен авыл белән тырыштык: иртәгә Сабантуй дигән төнне дә капка буяучылар күп булды.

Әхмәт бай Хөсәеновлар яшәгән чорга да күз салырга бик теләр идем... Каргалыны татар дөньясына заманында алар таныткан. Бертуган Хөсәеновлар кылган игелекне саный китсәкме?! Оренбургта Әхмәт бай төзеп калдырган йортлар бүген дә халыкка хезмәт итә. Ә калада аның исемен йөрткән бер урам юк, беркая истәлек тактасы эленмәгән...

Каргалыда узган ел йөз сабый дөньяга килде. Өч сыйныф дигән сүз бу!

Аның турында фильм әзерләргә күренекле шушы якташыбызның, бөтен татар галәменә билгеле меценатның исемен мәңгеләштерәсе иде дип тә тотынган идем. «Вакытлар бәйләнешы» дип атала ул. (Кабардин-Балкар Республикасының Нальчик шәһәрендә узган «Тынычлык. Татулык. Бердәмлек» IV Бөтенроссия телевизион программалар фестивалендә бу фильм беренче дәрәҗә дипломга ия булды.) Фильмны Оренбург телевидениесеннән берничә тапкыр күрсәттеләр, Әхмәт байга багышланган фәнни конференциядә катнашучылар да карады аны. Йогынтысы булгандыр – ниһаять, Аграр университет бинасына Әхмәт бай Хөсәенов хөрмәтенә истәлек тактасы куйдылар.

Сабантуй алдыннан мәрхүм Рәшит абый Искәндәровның Каргалы тарихы турындагы китабы дөнья күрде. Аны типографиягә тапшырыр алдыннан тагын бер кат карап чыгу өчен «Димур» нәшриятына җыелдык. Шул вакыт нәшриятның директоры Зинаида Мурашко миңа: «Зур бер хыялым бар... Гани бай турында китап чыгарасым килә. Ул да бит халык өчен абыйсы Әхмәт байдан аз эшләмәгән. Материаллар җыя башладым инде. Сез миңа булышырсызмы?» – диде. Әбисе ягыннан тамырлары татар булган бу ханымга, әлбәттә: «Әйе!» – дип җавап бирдем.

PRESSA.RU



КЫЗДАН – ӘНИГӘ

Укучы журналны ничек күрә, ул анда нинди темалар күтәрелүен көтә, аңа кайсы рубрикалар ошый, ә нинди яңа рубрикаларны ул үзе тәкъдим итә... Шушы сорауларга җавап эзләп, журналыбызны тагын да кызыклырак, баерак итәргә теләп башлаган идек «Яңа тема тәкъдим ит һәм бүләк от!» дигән бәйгене. Җаваплар кайдан гына килмәде! Башкортстан, Чуашстан, Мордовия, Красноярск крае, Мәскәү, Төмән, Омск, Саратов, Әстерхан... Җиңүчеләрне онлайн-тавыш бирү юлы белән бергәләп ачыкладык. Алар инде билгеле!

- **1 урын** – Диана Рәхимова (Казан);
- **2 урын** – И. Ергизова (Башкортстан, Бүздәк районы);
- **3 урын** – Гөлнара Ногманова (Әгерҗе районы, Тирсә).

Шушы көннәрдә редакциябездә җиңүчеләрне бүләкләү булды. Диана Рәхимова редакциягә ире Марат һәм улы Азат белән килде. Ул «Казан Ривьерасы»на ике кешелек сәяхәт сертификаты белән бүләкләнде.

Алар гаиләсе «Сөембикә» журналы белән дуслашканга әле өч кенә ел. Диана аша аның әнисе дә безнең журнал белән «танышкан». «Әни дә «Сөембикә»не яратты, – ди Диана. – Яңа санны башта үзем укыйм. Аннан Яшел Үзәндә яшәүче әниемә алып кайтам. Журнал укырга 84 яшьлек бабаем да чират тора әле».

БАЙЛАРДАН БАЙ ИСӘНБАЙ!

Әгерҗе Казанга ерак, ә аның Удмуртия Республикасы чигендә үк урнашкан Исәнбае – Әгерҗегә, район үзәгенә. Хәер, шуның кадәр юл узып килгәч, тагын йөз чакрым арамыни ул?!

«Сөембикә» килү Исәнбайда бәйрәмгә әйләнде. Нәкъ шулай булды! Бу көнне авыл Мәдәният йорты фойесында Казан шәһәре кул осталарының күргәзмә-ярминкәсе эшләде («Авыллар шәһәргә ярминкә белән гел килә, без дә аларны сөендерик әле», – дип, редакция аны Исәнбайда махсус оештырды!). Теләгәннәр Татарстан китап нәшриятында басылган китапларны сатып ала алды. Барлык мәшәкатьләрен читкә куеп, журнал хезмәткәрләре белән очрашуга килүчеләрнең күбесе өчен «Сөембикә»нең якын дус, ахирәт, киңәшче икәнен тоеп кайттык.

Фәтхия Зарипова (мәгариф ветераны):

– Журналны «Азат хатын» чагыннан бирле укыйм. Сезне хатын-кызлар басмасы дип кенә әйтү дөреслеккә хилафлык булыр. Мин үземә охшаган язманың битен гел өстәлдә ачык килеш калдырам:







әтиләре дә күрсен, ул да укысын әле дим. Укый, әлбәттә!

Рәмзия Җиһангәрәева (Кичкетаң авылы):

– Авыл кешесе укымый, диләр. Газет-журнал да укыйбыз, китап та! Зифа Кадыйрованың «Синсез килгән язлар» китабын, акча җыеп, илле данә кайтарттык. Безнең авыл Исәнбайдан алтмыш чакрым – сезнең белән очрашырга да махсус килдем әле менә.

Фаягөл Әхмәтшина (Кадыбаш авылы):

– Сезнең журнал белән кыз чагымда ук таныштым, үзем әни булгач та укыдым, дәү әни чорына аяк баскач та аерылганым юк... «Кульяулыгым – сөеклемә сөю билгесе» бәйгесендә катнашып, беренче урынны алган идем. Редакция миңа Коръән китабы бүләк итте. Кадерле бүләк ул миңа! Кызым Балтач районында кияүдә. «Сөембикә»нең яңа санын укыган саен, журнал турында аның белән телефоннан яртышар сәгать сөйләшәбез.

Рәмзия Зарипова («Әгерҗе хәбәрләре» газетасы баш мөхәррире):

– Бер онытмыйм, «Азат хатын» килгән көнне әти әнигә гел: «Мөнирә, тизрәк укып бетер, аннары минем чират», – дия иде... Журналга язылмыйча калган чагымны белмим. Алай гына да түгел, аны яздырып, бәйрәмнәрдә бүләк итүне гадәткә керттем әле. Туганнар арасында: «Бу бәйрәмгә дә «Сөембикә» буладыр бит?» – дигән сорауны еш ишетәм.

Гүзәлия Исмәгыйлева (Татарстанның атказанган укытучысы):

– Һәр укытучыга эшендә бик зур ярдәмче булганыгыз өчен күптән рәхмәт әйтәсем килеп йөри идем. Менә җай чыкты... Гап-гади хатыннар, авыл апалары катнашырлык бәйгеләр оештыруыгыз өчен дә рәхмәтле без «Сөембикә»гә.

Үзеңне якын иткәннәр, яратканнар янында рәхәт ул! (Иҗатны якын итүчеләр яши монда – очрашуны берничә китап авторы, шагыйрә Әлфирә ханым Низамова алып баруы үзе үк күп нәрсә хакында сөйли.) Безнең дә күңелгә кереп калды Исәнбай! Авыл тарихы белән дә танышырга өлгердек. (Заманында авыл Советы тарихны өйрәнүче кешене командировкага җибәреп, архивларда эшләү мөмкинлеге тудырган!) Йөз елдан артык тарихы булган мәктәпләренең беренче укытучыларын, авылның данын еракларга ишеттергән элекке укучыларын искә төшердек. Республиканың архитектура һәйкәле саналган, бер гасыр элек салынган Тютиев йорты бар Исәнбайда – аны да күрдек. Исәнбай җирлеге башлыгы Фәнил Сираевның беренче сыйныф укучыларының һәрберсе белән аерым исәнләшүенә, һәрберсенең исемен белүенә сокландык, шаккаттык. (Шулай, авылның киләчәге бит бу сабыйлар!) Тагын... Бу якта бик тәмле бәрәңге шәңгәсе пешерәләр – авыз иттек. Исәнбайда гына армиягә китүче егетләр Мәдәният йортында кульяулык калдыра: үзләре әйләнеп кайтканчы ул кульяулыклар шунда эленеп тора. Алты кульяулык эленгән, димәк, авылның алты егете бүген хәрби хезмәттә дигән сүз. Тагын... бу якта күңеле белән матур, эчке дөньясы бай кешеләр яши! Кешеләре белән бай ул Исәнбай!



САРМАН ЯКЛАРЫНДА

Казанны чыгып китү белән үк юл буе Сарман белән бәйле хатирәләрне күңелдә яңартып бардык. Журналыбыз «Азат хатын» булып чыккан елларда ук анда Сарман кызлары, атаклы журналистлар Мәдинә Маликова, Диләра Зөбәерозалар эшләгән. Моннан дүрт-биш еллар элек Саклаубаш халкы белән очрашып, алардан «Бездә хәлләр – ат мөгезе» дигән гыйбарәне ияртеп кайткан идек. Гайре табигый хәлләргә юлыксак, елмаеп, гел шул сүзләрне искә төшерәбез... Тагын... «Сарман вальсы»ның авторы Дамир Гарифуллин да Сарманда яшәп ята бит! Журналист Рәйханә Мирсәяпова «Сөембикә» укучыларын күптән түгел шул җырның язылу тарихы белән таныштырды... Район мәгариф бүлегендә татар теле укытучыларының методик берләшмә җитәкчесе Назилә Мәүләвиева безгә шалтыратып, юл кешеләренең хәлен белешеп торды. Рәйханәдән дә «Көтәбез!» дигән «смс» хәбәр килеп ирешә.

Күр, Сарманның 2 нче гимназиясендә районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр зал тутырып утыра! Сөйләшүебез үзеннән-үзе тәрбия темасына, БДИга, туган телне укытудагы проблемаларга барып тоташты. Кыз балаларны, ир балаларны ничек тәрбияләргә, гаиләне ничек сакларга... Җәлил бистәсеннән килгән Резеда Исхакова татар теле дәресләренең кимүе турында ачынып сөйләде. «Балалар үзара русча сөйләшә» дигән сүзләре сагайтты. «Без Минзәлә педагогика көллиятендә укыган елларда шәһәрнекеләр «деревня» дип көлеп калалар иде. Шуңа күрә шәһәрчә киенергә, рус телендә дә хатасыз сөйләшергә тырыштык. Хәзер инде авыл баласы шәһәр баласыннан калышмый да: һәм киенү, һәм хәбәрдарлык, һәм эчке өзерлек ягыннан», – дип, Саклаубаш мәктәбе укытучысы Әлфирә Габидуллина бу темага үзенчә якын килде. «Җәлил чаткылары» әдәби берләшмәсе әгъзасы Әнисә Минһаҗева: «Телевидение журналистлары ни өчен авылда яшәүче татар әбиләрен ватаҗимерә русча сөйләтеп аптыраталар икән, тәрҗемә итсәләр ярамыймы?» – дип, телгә кагылышлы сөйләшүне тагын да тирәнгәрәк алып кереп китте. Сарман мәчете имамы Рамил Садыйков читтән торып Алабуга педагогика институтын тәмамлаган, Катыш-Каран мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Ул ир-ат укытучылар күбрәк булсын иде дигән теләк белдерде. Гел хатын-кыз тәрбияләгән, хатын-кыз гына укыткан малайлар кыз балалар кебек йомшак булып үсмәсме дип сагаюы иде аның. Баларның китап укымаулары, иншалар язганда фикер һәм тел ярлылыгы сизелү, сәгатьләр буе компьютер каршында утырулар... – бөтенесе турында да уртага салып сөйләштеләр. Журналистларны сорауларга күмеп ташладылар. Сарман гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алсу Салихова әйтмешли, күптән кирәк иде мондый ихлас сөйләшүләр, халык аралашуга, үз фикерен җиткерүгә сусаган икән бит!

PRESSA.RU

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ шигырьләре гадилеге, табигыйлеге белән аерылып тора. Гомере буе колхоз, совхоз рәисе, райком секретаре кебек җаваплы эшләрдә эшләсә дә, ул барыбер табигате, җаны белән нечкә күңелле шагыйрь булып кала. Кырларда туган җырларында да – авыл, Чатыртауның киң офыклары, туган як рухы, милләт язмышы. Тургай моңына манылган җырлар язучы диләр аның турында. Шагыйрьнең «Җир китабы», «Җилкенү», «Өмет ае», «Серле мәгарә», «Чатыртау тылсымы», «Яратканга күрә» шигырь китапларын яратып кабул иткән укучыларны Илдус Гыйләҗевнең яңа шигырьләре белән сөендерәбез.



Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ

КАБАТЛАНСАҢ НИ БУЛА?

Синең хакка

Яшьтәшләрем берәм-берәм китә,
Ә мин йөрим – сәбәп табылмый.
...Сине мактар сүзләр бетмәгән,
Шуңа Ходай миңа кагылмый...

* * *

Ничә еллар ятим йөрим,
Бик еш күңелем тула.
Бозып яшәү кагыйдәсен,
Кабатлансаң ни була?
Вакыт узган саен өтә,
Арта сагыну көче.
Бар микән соң җирдә сине
Онытырлык кеше?!

Аклыкка тиенү

Ык буйларын урап кайттык.
И андагы матурлыклар!
Бер күл күрдек, суның өстен
Каплаган төнбоеклар.
Барысы ак. Биләмәгә
Чит төсләрне кертмәгәннәр.
Дулкын чиртеп борчылдылар,
Димәк, безне көтмәгәннәр.
Токымыңа тугры булу
Аларда да дәрәҗәдер.
Әрсезләрне сафлык нуры
Кире борып җибәрәдер.
Без дә шунда үзгәрдек бит –
Бетте үпкә-торгынлыклар.
Хәзер күңел күлебездә
Үсә ап-ак төнбоеклар...

Кайсыгыз саташтыра?

Әсир иткән матурлыкның
Сәбәбен белим әле.
Әйтче, кайдан алган идең
Ул матур мулинене?

Сәнгать әсәре булган бит
Тышлыгы мендәреңнең.
Күргәзмәгә соратырлар,
Белдерсәм кемдәлеген.

Күз карашың кебек балкый
Төшергән чәчәкләрең.
Кемгә атап чиккән идең?
Юрыйм киләчәкләрен.

Хыялланып йөри торгач
Урталай бүленәмме?
Әллә сине эзләп киләм,
Әллә шул мулинене...

Бал кортлары сынасын

Шушы минем умарталык,
Күрче, нинди хозурлык.
Ямьле дөнья – булыр-булмас
Курортны да узарлык.

Чәбәләнмә, торып чапма,
Бал кортлары күренсә.
Һәркемгә дә тими алар:
Тия, шикле күренсәң.

Чиста йөрсәң, пөхтә булсаң,
Түгел бер дә куркасы.
Уй-телләгең матур булса...
Курыкмый бал «урларсың».

Юкка алып килмәдем бит
Гүзәл алан карарга.
Бал кортлары сынасыннар –
Тырыша күр ярарга...

* * *

Кышкы урман. Чаңгы эзе.
Без янәшә атлыйбыз.
Читкә чыксак, кары бата,
Башка чара тапмыйбыз.

Бик бәхетле көн иде шул,
Озак йөрдек ул чакта.
Ничә туктап, эзне таптап,
Алдым сине кочакка.

Чаңгычылар ачуланыр
Ул тирәдән узганда.
Кичерсеннәр безне берүк
Чаңгы юлын бозганга...

Ял йорты хатирәсе

Шифалы су эчәргә дип
Җыелган кунакларны
Мәйданчыкта каршы ала
Барбарис куаклары.

Бүрткән борай тәлгәше кук
Озынча җимешләре.
Нәкъ сандугач теле инде
Кызарып җитешкәне.

Күрдек бит, күрдек аның да
Өзелеп сайраганын.
Никләр генә көйләренең
Исәбен санамадым?

Истән чыкмый бергә күргән
Барбарис куаклары.
...Сары сандугач шикелле
Җаныма кунакладың...

Кулың җылысы

Бүләк иткән оекбашың
Йомшак, җылы, ак җептән.
Минем ише хыялыйга
Мактанырга бик җиткән.

Ничек бәйли алгансыңдыр
Сыйфатлы, таман итеп.
Төнгә генә киеп-салам,
Туңганда кышлар җитеп.

Идәнгә дә басканым юк,
Саклыйм чип-чиста килеш.
Андый затлы киемнәргә
Соклану, кадер тиеш!

Кул җылыңны, назың тоям...
Үзеңә кайтсын савап:
Бер элмәккә бер рәхмәттән
Исәбен чыгар санап...

Йөземле шигырь

Сөбханалла, үсә икән
Безнең якта да йөзем.
Уңышны мул бирә дисең,
Булсаң тырыш һәм түзем.
Исем китте түр бакчаңда
Йөзем чыбыгын күреп.

Кара-кучкыл җимешләрен
Татып карадым кереп.
Гел йөземгә охшап тора
Синең дә кара күзең.
Учка алдым тәмле йөзем,
Күңел түрендә – үзең!

Чишмә янында

Мин соң чишмә күрмәгәнме,
Күп җирләр гизмәгәнме?
Унны түгел, йөзне беләм
Мул сулы кизләүләрне.

Ник монсына исем китте,
Нәрсәгә аптырадым?
Саркып кына чыккан суны
Йоттым да калтырандым.

Салкын түгел иде юкса
Гөл үскән ярларында...
Каушадым мин... көлемсерәп
Син торгач яннарымда...

Сарана сарылары

Ерактан ук таныйм аны,
Чәчәкләре күгелҗем.
Шул кечкенә «кыңгыраулар»
Алгысыта күңелне.
Казып алам. Суганчалар
Майлы, төче, сарылар.
Сагынганда синсез үткән
Көн санарга ярыйлар.
Сарана ник сары була?
Ансын белмим, сорама.
Мин үзем бит сине көтеп
Саргаючы сарана...

Яшел косынка

«Кыңгыраулы яшел гармун»,*
«Яшел эшләпә»** беләм.
Яшел косынка да күрдем,
Саташам шуның белән.

Бер сәерлек һәм серлелек
Аңымны чорнап алды.
Хисләремне куптарды да,
Әллә кая югалды.

Шуны эзләп йөргән чагым,
Алгысый, ярсый җаным.
Яулык түгел, кирәк миңа
Аны ябынган ханым...

*Фатих Кәрим поэмасы.
**Гамир Насрый комедиясе.



Әлмәтнең Тайсуганында туып-үскән, гомер буе Миңлебай газ эшкәртү заводында оператор булып эшләгән Зәлидә ЗАРИПОВАның лирик шигырьләре инде үз укучыларын тапкан, күбесе җыр-моңнар булып тамашачысына барып ирешкән.
Сезгә аның берничә шигырен тәкъдим итәбез.

И бала!

Күзләр үтеп, озын кышлар җитте,
Көне кыска, озын төннәре.
Һәркемнең дә үз тормышы инде,
Кайда йөри кемнең кемнәре.

Көн үткәнен сизми әле дә ул,
Төннәре шул үзәк ярганы.
Әллә нигә йөрәк ярсый шулчак,
Әллә нигә күңел яралы.

Бу кышымның озын төне бигрәк
Күңелемә шомлы ут сала.
Һәр минутын сәгатьләргә сузып,
Сине уйлый әнкәң, и бала!

Туган җир

Булса да төрле чакларым,
Күтәрдең бит син мине.
Ялгышларымнан аралап
Җибәрдең бит син мине.

Кочагын җәйде таңнарың
Белә-белгәннән бирле.
Күгеңдә – имин зәңгәрлек,
Төнеңдә – йолдыз серле.

Нинди чакларым булса да,
Күтәрдең һаман мине.
Һич тынмас җырлы тургаең
Булып мин калам инде.

Кабул ит, җырым тирбәлә
Офыкларыңда синең.
Хикмәтле булып, изге җир,
Хәтергә сеңдең минем.
И туган җир!

PRESSA.RU



Нәзифә
КӘРИМОВА

МИН БИТ СИНЕ ШУНДЫЙ ЯРАТАМ!

(Хикәя)

Мәүҗидә апаның бер сәер гәдәте бар. Сәер дип инде, бу аның өчен ихтыяҗ, башкача булдыра алмый. Ул авылда булган яңалыкларны, һәр көнне дип әйтерлек, стенада эленеп торган өзмә календарь кырыйларына язып бара. Календарьның бер битен дә өздерми, өскә күтәреп куя иде. Әллә ничәнче елгы календарьлары бар аның. Саргаеп, битләре өскә күтәрелеп торган көдрә календарьлар аның сандыгы почмагында байтак җыелды инде. Көннәрен, елларын куймый ул язмасында, чөнки календарьга куелган дата бар бит инде. «Бүген сыер бозаулады», «Айсылуттиләрнең кара сарыгы бәрәнләде». «Бүген җиргә беренче кар ятты, бер айдан кыш булачак». Якын-тирә күршеләрнең дә елъязмасына урын җиткерә алган ул. «Галимҗан өйләнде». «Бүген Галимҗан кызмача», «Галимҗан салган», «Бүген Галимҗан лаякыл исерек», «Галимҗан ләх». Бу язмалардан соң берничә көннән: «Галимҗанның хатыны аналарына төшеп китте» дигән язма да барлыкка килде. Терәлеп кенә торган күршеләренең тормышына Мәүҗидә битараф түгел иде. Ни дисәң дә, күз алдында үскән балалар бит. Тагы бер язма: «Галимҗан хатынын алып кайтты». «Галимҗан белән Сәвиянең кызы туды. 8 август». Менә бу да мәхәббәт тарихы. Ләкин Мәүҗидә апа икенче бер мәхәббәт турында уйлады. Чөнки бүген «Хисаметдин вафат булды» дигән язма барлыкка килде. Тагын бер елдан дөнья бетәчәк, дип әйтәләр, анысы инде ил белән булыр, Хисаметдин өчен дөнья бер елга алдан бетте, Гөлйөзем дә ялгыз калды. Ничек матур, яратышып яшәгәннәр иде.

Мәүҗидә апа шул хакта уйлады. Гомер буе икесе дә – Гөлйөзем кияүгә чыкканчы да бер урамда, кияүгә чыккач та шулай туры килде – күршеләр булып яшәделәр, дус булдылар, гомер буе серләштеләр, серләрен кешегә чыгармадылар. Календарь битләренә генә сыймас әйтәсе килгән сүзләр – урын аз. Ә күңелгә барысы да сыя. Күңел – дәрья, ярлары юк...

...Әле генә өйләнешкәннәр иде кебек. Ә гомер узган да киткән. Шулхәтле тиз... Хәзер Гөлйөзем дә ялгыз, мин дә күптән ялгыз инде дип уйлады ул. Нигә ирләр шулай иртә китәләр икән? Хатын-кыз түзем, ирләр ялгыз калса, авыррак булыр, дип, Ходай Тәгалә шулай эшлидер инде. Гөлйөзем белән Хисаметдиннең өйләнешүе кызык кына булды. Әле аңа хәтле Гөлйөзем

ялгыш кына бер язмыш юлына кереп чыккан иде. Бик иркә хатын булып гомер кичерсә дә, ул яшьтән үк тәвәккәл булды. Әйткән сүзен эшләми калмый иде.

Бервакыт аны күрше авылда яшәүче апасы кунакка алып китте. Ул авылда булганы бар иде инде Гөлйөземнең. Күрәсең, шул вакытта бер егетнең аңа күзе төшеп калган. Апасы белгән, әлбәттә, тик сеңлесенә генә бер сүз дә әйтмичә, тагын үзе белән кунакка алып киткән. Шул ук кичне күзе төшеп калган теге егет урлап алып кайткан кунак кызын. Апасының исе дә китмәгән бу хәлгә, сөенгән генә. «Әйбәт егет, мул тормышта яшиләр, янымда булырсың, ризалаш инде!» – дип ялварырга тотынган ул. Ләкин Гөлйөзем Гөлйөзем булмас иде! Дүрт көннән үз аягы белән əти-əниләренə кайтып кергән кияүгә барган «яшь килен». Сугыштан соңгы еллар бит! Егетләргә кытлык. Ә ул менә диген егеттән качып кайткан да киткән! Апасы белән дә шул вакыттан соң озак еллар йөрешмәде ул. «Син белгәнсең, мине мыскыл итеп, бер дә яратмаган кешегә тоттырып чыгардың!» – дип үпкәләде ул аңа.

Ул кайткан көнне иң беренче булып ахирәт дусты Мәүҗидә кереп җитте. Хурланып, мендәргә капланып елап ятадыр инде дип, юатырга кергән иде. Кая ул! Гөлйөзем кояш кебек көлеп каршы алды аны.

– И кызый, шулай ук күңел ятмаслык идемени соң? Хәзер ирдән кайткан хатын булдың бит инде. Ишетелде инде авылга да...

– Яратмадым! Сөйләшүен дә, ашавын да!.. Йөзем дип әйтүләренә кадәр яратмадым. Гөлйөзем дип тә әйтми бит! Йөзем, имеш. Нинди Йөзем булыйм мин аңар! Дүрт көн чыдаганга рәхмәт әйтсен. Суга да ияреп бара, токмач кискәндә дә пычак тавышына кырыемда сызгырып тора иде. Туйдырды! Якын да китермәдем мин аны. Кияүгә бару дигән сүзе генә булды инде. Гомер буе аның белән яшәргә туры килсә, үләргә генә кала! Мин кеше сүзеннән курыкмыйм, сөйләсеннәр! Миңа өйләнгән кеше белер әле кем икәнлегемне!

– Әллә авылда яраткан кешең бармы? Миңа теш агартып бер сүз әйткәнең юк бит, ахирәт? – диде Мәүҗидә.

– Яраткан дип инде, бар бирәү. Тик мин аның тел төбен белмим. Кыюсыз нәрсә. Үзең сизмисеңмени? Хисаметдин! Минем якка карарга да оялган егет.

– Ахирәт! Егет сайлый торган заманмыни?!

– Ә мин сайламыйм. Бирәү генә бит ул! Әле менә куркып торам, теге күрше авыл егете килеп, әтиләрдән сорап йөри торган булса, коры кала Хисаметдин! Китәм дә барам үч итеп.

Гөлйөземнең горурлыгын белгән Мәүҗидә, ахирәтенә әйтми генә, менә шул вакытта Хисаметдингә аның тел төбен җиткерде!

Хисаметдиннең сөенүләре! Кияүдән качып кайткан Гөлйөземенә бер генә кич тә өендә кунарга бирмәде Хисаметдин! Шул ук көнне алып кайтты!

– Кире төшереп куй! Безгә ирдән кайткан хатыннар кирәк түгел! – дип зәһәрен чәчте Хисаметдиннең өйдәге ике апасы.

– Сезгә дип түгел, үземә алып кайттым мин аны! Гөлйөземгә сүз тидерәсе булмагыз! – дип, Хисаметдин дә каты торды.

Бәхетләренә, Хисаметдиннең әтисенең энесе гаиләсе белән уллары янына читкә китте. Өйләрен Хисаметдин белән Гөлйөземгә калдырдылар. Шулай итеп, алар көтмәгәндә барлы-юклы әйберләрен җәймәгә төйнәп, башка да чыгып куйдылар.

Гөлйөзем ул вакытларны еш сагынып искә ала, рәхәтләнеп сөйләргә ярата иде. Бу вакытта аның йөзенә назлы елмаю чаткылары чыга, битләре алсуланып китә. Хәтта тавышы да, салмакланып, «бу бәхет булгандыр» дигән аһәңне чыгара иде.

– Башка чыктык, кызый, ашарга юк, кияргә юк, мал-туар да юк! Минем әниләр биргән биш тавык белән бер әтәчебез бар – бөтен малыбыз шул! Апалары Хисаметдингә бернәрсә дә бирдертмәде. Әле бит анда төпчек малай да бар, аны да башка чыгарасы бар, диделәр. Әйбердәмени бәхет. Без яшь идек, икәү бергә идек, бөтен дөнья безнеке иде. Үзең беләсең, Хисаметдин колхозда атлы эшкә йөрде. Эше әйбәт булды аның, гомер буе атлы булдык. Заманасы нинди иде бит! Сабын алырга да акча юк инде. Беркөнне Түбән оч Хәлимә мендәр сүрүедәй ак төстәге берничә метр тукыма алып менгән, «Гөлйөзем, күлмәк тегеп бир әле, нәрсә телисең, шуны бирәм – акчамы, бәрәңге белән түлимме?» – ди. «Бер табак бәрәңге бирсәң дә җитәр», – дидем. «Бер чиләк бирермен», – ди бу! Мин бит бөтен күлмәкләремне үзем теккәнне беләсең инде. Кызый, өстеңдә дә мин теккән күлмәк бугай? Тегенең сүрүен алдым да алсу төскә мандым. Буяу бар иде минем, манып теккәннәрне беләсең инде. Хәлимәгә түшләренә шлапыр куеп, иң өсләре кабарып торган итеп, өч бәбитәкле, билле, киң путалы күлмәк тегеп бирдем! Киеп карады да, күлмәкне шундый ошатты! Син моның шатлануларын күрсәң! Мине кочаклап зыр-зыр әйләндерә! Шушы күлмәк белән кияүгә чыгып куйды Хәлимә! Бәхетле күлмәк тектең син миңа, Гөлйөзем, ди торган иде! Кияве тегеңә, күлмәк итәгенә гашыйк булдым мин синең, дип әйткән ди! Бәрәңгегә өстәп ике тәңкә акча да бирде!

«Бәхетле тормыш шуннан башланды да инде», – дип искә ала торган иде Гөлйөзем. Яши башлагач, баласы да була бит инде. Бик көтте Хисаметдин ул баланы! Ләкин бала туу шатлыгы кара кайгыга әверелде. Балалары вакыт җитми туды аларның. Бары тик өч кенә көн яшәп калды сабый. Исем кушканчы ук гүр иясе булды. Гөлйөзем елый-елый баланы биләүгә биләде. Хисаметдиннең кайгысы әйтеп бетергесез иде. Ул, биләгән баланы кечкенә генә юкә кабыкка салып, елый-елый, үз куллары белән зиратка илтеп җирләде. Андый балаларга Шәфигулла дип исем бирәләр. Гөлйөзем исенә төшергән саен елый торган иде.

– Шуны гына уйлап кара әле, ахирәткәем! Бәбине кулга алганнан соң, Хисаметдин миңа нәрсә ашатырга, нәрсә эчертергә белми! Шулхәтле бәхетле иде ул! Җимешем, нәрсә ашыйсың килә дип кенә тора. Картайганчы Җимешем диде ул миңа. «Авыз тәмем юк, ашый-

PRESSA.RU

сым да килми», – дип иркәләнгән булам. Нәрсә ашыйсың инде, сайлана торган чакмыни!.. Ипи белән бәрәңге инде, булса әле! Мае да юк, шикәре дә юк бит ул заманнарда. Башкасын әйтәсе дә түгел. Карыйм, Хисаметдин бер табак йомырка пешергән дә алдыма китереп куйды. «Аша, Җимешем!» – ди. Сатарга дип җыйган идек бит, дим! Булыр әле, тавыклар көн саен сала ди. Үзе берсен дә ашамады! Менә шундый иде Хисаметдин! Бәбинең вакытыннан алда тууында үзен гаепле санады, авыр күтәрдең, үзем саклый алмадым сине, диде.

Бәбиләре белән шушы хәлләрдән соң Хисаметдин Гөлйөземгә карата бигрәк тә игътибарлы булды. Әйбер күтәртмәде, печән ташытмады, утын кистермәде, авыл кешесе көлсә дә, суга үзе бара иде. Башта чиләкләр белән йөрсә, соңыннан инде ат арбасына агач мичкә көйләп, шуның белән алып кайта торган булды. Иренең яратканын тоеп яшәгән башка хатын булдымы икән авылда, юктыр! Гөлйөзем бик бәхетле яшәде. Ул үзе дә Хисаметдине өчен ашны кечкенә чүлмәккә салып, тәмле итеп мич куенында гына аерым пешерә иде. Балаларга аш олы казанда пешсә, Хисаметдингә һәр көнне ризык – мич куенында. Гөлйөзем ирен генә түгел, балаларын да әйбәт карады. Балаларына, яратып, «бәбекәчем, кызым, улым» дип дәшә торган иде. Ә менә Мәүҗидә, әллә инде үзе үги ана белән татлы сүзләр ишетми үскәнгә, балаларына андый ягымлы сүзләрне әйтергә ояла иде. Юк, «кызым, улым» дип әйтә иде әйтүен. Ләкин Гөлйөзем кебек артык төчеләнүне өнәп бетерми иде. Үзен карарга да вакыты җитмәде аның. Ә менә Гөлйөзем! Ул үзе турында да беркайчан да онытмый иде. Аның кап-кара чәчләре олыгайган көннәрдә чаларса да, гомер буе яшь чагындагы кебек озын булды, биленә төшеп торды. Ә менә кызыл ахаклы көмеш чулпылар бөтен авылына да бер Гөлйөземдә генә булгандыр. Көмеш тәңкәлеләр бар иде, ә менә ахаклы чулпылар – бары Гөлйөземдә генә! Ул чәчләрен ике толымга үреп сала. Ә көмеш чулпылары, чың-чың килеп, «карагыз, Гөлйөзем килә!» дип, алдан ук тавыш бирә иде. Башка хатын-кызлар чабата кигәндә дә аның аягында ялтыравыклы гәлүш булды. Оекбашлары да, чөеп япкан яулыгы да һәрвакыт ап-ак була торган иде. Ничек яратмасын инде аны Хисаметдин! Боларның барысын да ул иренә ярарга тырышып, яратуын, хөрмәтен күрсәтергә тырышып эшли иде шул!

– Хисаметдиндә сабый бала күңеле, беркатлы кеше инде ул безнең. Минем белән киңәшмичә бер эшен дә эшләгәне булмады аның, – ди торган иде ахирәте. Гөлйөзем эченнән генә көлеп караса да, иренә туры әйтмәгән, хәтта белмәмешкә салышкан бер гадәтен белә Хисаметдиннең. Ул да булса, Хисаметдин үзе генә мунчага керергә курка иде. Бигрәк тә кич белән. Сугышларда йөреп кайткан кеше бит! Медальләре дә бар! Кичке мунчадан курка инде! Шуңа күрә Гөлйөзем мунчаны ире көндез керә торган итеп яга торган булды. Чөнки куркуның да сәбәбе бар. Бервакыт кич белән берүзенә мунча керергә туры килгән Хисаметдингә. Мунчага килеп керсә – мич эченнән ап-ак ялларын җилфердәтеп бер ат башы карап тора икән! Ә инде «пәри бишегендә» (кара мунчада мич ташлары өстенә тарттырылып куелган калайны шаяртып кына шулай дип атыйлар) бер яшь кенә кыз себерке белән чабынып утыра, ди! Хисаметдин бик нык курыккан! Әллә куркуыннан, әллә башка сәбәп белән, мунчада һушсыз егылган бу! Ис тигән дисәң, беренче кергәне дә ул булмаган. Әле өйләнгәнче булган бу хәлләр. Моны көтәләр, көтәләр икән мунчадан! Нәрсә булды моңа дип мунчага керсәләр – лампа сүнгән, мунча кап-караңгы, бусагада телсез калып Хисаметдин ята, ди. Күтәреп алып чыгып, аңына китергәннәр. Шул вакыттан бирле аның кич белән беркайчан да мунчага кергәне булмаган. Гөлйөзем аның бу гадәтенә гаепләп тә, көлеп тә түгел – хөрмәт белән карый иде. Бәлки, ирен яратуның бу бер чагылышы булгандыр. Шуңа күрә мунчаны иртүк ягып, ирен көндез кертә торган иде. Колхоз эшенә кушарга килгән бригадирга: «Бүген эшкә бара алмыйм, мунча ягам, кичкә кадәр мунча кереп чыгарга кирәк!» – дип, эшкә бармыйча кала торган иде. Куркуын ул бер дә кешегә сиздермәскә тырышкан, әлбәттә. Ләкин авылда аның бу гадәтен белмәгән кеше булмагандыр. Кайберәүләр төрттереп кенә көлә иде үзеннән.

Мәүҗидә, бу хәлләрне уйлап, олыларның әйтеп калдырган сүзләрен дә исенә төшерде: «Мунча салынасы урынга җеннәр әле җиде ел алдан урнашып куялар икән. Шуңа күрә мунчага кергәндә әгүзе бисмилланы әйтеп, «мунчада кемнәр бар, мулла белән абыстай килә!» – дип әйтергә кирәк ди. Ашыкмаска, ишекләрне әкрен генә ачарга... Качасы булганнар качып бетсен, күзгә күренмәсен өчен анысы. Ялгыш алар баскан урынга аягың тисә, зәхмәт кагылуын көт тә тор! Ә менә Хисаметдин ул турыда онытканбы, яшь чагы: уптым илаһи бәреп кергәндер мунчага. Хәзер ул турыда сөйләргә соң инде, аннан соң олыгайган көнендә Хисаметдин курыкмый да башлады дип сөйләгән иде Гөлйөзем. Анысы да бер кызыклы вакыйгадан соң булган.

Бервакытны кичкырын Гөлйөзем Мәүҗидәләргә кереп, сер итеп кенә ахирәте колагына болай ди:

– Мәүҗидә, Хисаметдингә Илмәт тавында суктырылган арыш көшелен сакларга кушканнар. Төнгә шунда каравылга барырга тиеш. Үзең беләсең, караңгыдан курка торган кеше бит. Миңа әйтә, көшел үлчәнмәгән, Мәүҗидәне дә алып кил, бер-ике чиләк арыш биреп җибәрермен, ди. Әйдә, ахирәт, барып кайтабыз. Хисаметдингә ашарга да илтермен. Арышы да эчне тишмәс.

Мәүҗидә белән Гөлйөзем, өйләрдә утлар сүнгәч, капчыкларын алып, Илмәт тавына юл тоткан. «Токмач басып, токмач кисеп, бәрәңге турап, май сызгыртып, күкәй туглап, итсез генә булса да аш пешердем, тәмле дә булды инде!» – дип, юл буенча Гөлйөзем Мәүҗидәгә Хисаметдин өчен нинди тәмле аш пешергәнен сөйләп килә. Ул эшләгән эшен күп итеп күрсәтер өчен бар хәрәкәтен дә шулай санап чыга торган була. Боларның килүенә Хисаметдин бик сөенгән. Сугыштан алып кайткан котелогында хатыны алып килгән токмачлы ашны ашарга утырган.

– Кызлар, кайтырга ашыкмагыз әле, сөйләшеп утырыгыз, вакыт бар, – ди икән. Курка инде, яныннан җибәрәсе килми.

– Юк инде, – ди Гөлйөзем, – әнә таң ата хәзер! Яктырып беткәнне көтәсеңмени, Хисаметдин. Күтәреп кайтасы да бар бит әле!

– Кызый, син күп күтәрмә! – дип пышылдый Хисаметдин. – Үзем алып кайтырмын. Мин бит ат белән. Менә шушы котелокка салсаң да җитәр сиңа. Әнә Мәүҗидәгә ярдәм ит.

Тутырасын тутырып, юлга кузгалулары була, тау ягыннан күктә нәрсәдер ялтырап, көчле ут көлтәсен болар өстенә җибәрә, көшелләрен, шулар янында мәш килгән «колхоз каракларын» яктырта. Әле бер, әле икенче якка йөгерешә башлыйлар! Теге ут бер адым калмый артларыннан иярә! Капчыкларын якындагы erганакка ташлап, болар йөзтүбән җиргә каплана. Бер тын баш өстендә селкенми дә торганнан соң, теге утлы очкыч бик тиз генә очып та китә. Шул хәлдән соң болар, хәлсезләнеп, кузгалып китә алмый тора. Нәрсә булганын берничек тә аңлата алмыйлар. Куркуларына үзләренең ачуы да килә!

– Очкычка үч итеп, бер генә түгел, ике тапкыр барып кайттык ул төнне көшелгә, – дип сөйләде Мәүҗидә апа. – Гөлйөземнең ирен үзен генә калдырасы килмәгәндер инде. Иптәшкә мине дә кыстады. Ярый персидәтел очрамады! Исән-имин кайтып җиткәч, и көлдек рәхәтләнеп. Утлы очкычка караганда персидәтел куркынычрак булган шул. Безнең бер таяк хезмәт көненә эшләгән чаклар. Без бит урламадык, үзебезгә тигән өлешне генә алдык. Анысы да тулысы белән булмагандыр әле.

Менә шушы хәлләрдән соң Гөлйөзем, сер итеп кенә, теге Илмәт тавында күренгән һавадагы утлы тәлинкәдән соң Хисаметдиннең мунчадан куркуы бетте бит, дип сөйләгән.

Гөлйөзем белән Хисаметдин җиде бала үстерделәр. Беренчесеннән башка калганнары барысы да исән-имин үстеләр. Ләкин картайган көннәрендә берсе дә яннарында калмады. Язмыш аларны кайсын кая таратып бетерде. Әтисен җирләргә генә барысы да җыелышты балалары.

«Менә Хисаметдин дә ак дөньялардан китеп барды», дип уйлады Мәүҗидә апа. «Ул кара җир эчләрендә берүзе ничекләр ятар инде, – дип өзгәләнде Гөлйөзем. – Дөньяда да караңгыдан курка иде».

Мәүҗидә бүген Гөлйөземгә кунарга керде. Шул көннән башлап ул аның янында куна торган булды. Өйдә малай белән килен. Аларга да иркенрәк булыр. Ахирәтен ул бер генә кичкә дә ялгызын калдырмады. Алар кич утырып, тормышларын искә төшерергә ярата иде. Балаларга оекбаш бәйләделәр, йон эрләделәр – бер генә кич тә буш утырмадылар.

– Мәүҗидә, әйткәнем дә бар бугай инде, Хисаметдиннең үләр алдыннан әйткән соңгы сүзләрен беләсеңме әле син?

Ул бу турыда еш сорый. Әллә оныта инде, әллә һәр көнне исенә төшерәсе килә. Ахирәте, белсә дә, беләм дип әйтми торган иде, кабатласын тагын бер мәртәбә дип уйлый иде.

– Хисаметдинем куллары белән кулымны менә шулай учына алды да, хәлсез тавышы белән: «Җимешем, мин сине шундый яратам...» – диде. Шушы сүзләре белән күзен дә йомды. Кабат бер сүз дә әйтмәде. Беләсеңме, яратам дип гомер буена бер генә тапкыр да әйткәне булмады аның. Шул сүзләре аның авызыннан җаны белән бергә чыкты. Үлгәндә булса да ишеттем.

– И Гөлйөзем! Яраткан кешегә сүзләр нәрсәгә кирәк! Үзең әйттеңме соң?

– Әйттем... Тик мин әйткәнне ул инде ишетмәде бугай... Мин дә яратам сине, Хисаметдин, дидем. Ул мине ишетмәде, ә мин аны ишеттем. Шуңа гына үкенәм. Шулай да, бәлки, ишеткәндер әле дип тә уйлыйм.


– Мин дә ишеткәндер дип уйлыйм, – диде Мәүҗидә. – Ул бит гомер буе синең яратканыңны тоеп яшәде. Бәхетле яшәдегез, Гөлйөзем, үкенечле булмады тормышың. Ярый әле теге вакытта тәвәккәлләп кайттың ул күрше авылдан.

– Яратмаган кеше белән яшимме соң! Гомердә дә яшәмәс идем, – диде Гөлйөзем.

Алар беренче әтәчләргә кадәр кич утырдылар. Ике карчыкның ярату турында сөйләшүләрен тыңлап торган кешегә кызык тоелыр иде. Ләкин бу аларның өлешенә тигән көмешләре иде...




PRESSA.RU



ФИЛЬМОГРАФИЯ

1997 «Биер вакыт» – Катя.
1998 «Чукраклар иле» – Рита.
1999 «Айлы төндәге вакыйга» – Мәмләкәт
1999 «Тувалу» – Ева.
2001 «Арыслан өлеше» – Дина.
2004 «72 метр» – Нелли.
2004 «Арбат балалары» – Варя Иванова.
2005 «Грециядәге каникул» – Мелина.
2005 «Империянең һәлакәте» – Ольга.
2005 «Кукоцкий казусы» – Танечка.
2006 «Доктор Живаго» – Лара.
2006 «Кылыч йөртүче» – Катя.
2006 «Күп нокта» – Урсула.
2009 «Явыз Иван» – Шамил.
2010 «Элизиум» – Черубина де Габриак.
2011 «Достоевский» – Мария Исаева.
2013 «Күл» – Соня.
2015 «Яшерен дәрт» – Нэлла Аххо.
2015 «Җәннәт бакчасы» – Галина.
2015 «Маяковский» – Лиля Брик.



ЧУЛПАН ХАМАТОВА



КИНОДАГЫ БЕРЕНЧЕ РОЛЬ

Бер режиссер Чулпанга, күзләреңдә хис-тойгылар чагылмый, актриса булма син, дигән иде. Ә Вадим Габдерәшитов аны өченче курста укыганда «Биер вакыт» («Время танцора») дигән фильмында баш рольдә уйнарга чакырды. Шушы роль белән «Ника» призына да куелды.

Үзе турында Чулпан: «Мин бәхетле кеше. Һәрхәлдә, бәхетле булырга тырышам. Исән-сау икәнлегемне, янымда тормыш кайнап торуын аңлый алырлык дәрәҗәдә зирәк булырга омтылам. Шулдыр инде ул бәхет», – ди.



ТЕАТРГА КИЛҮ

1998 елда «Современник» театрына чакырыла. Э. М. Ремарк әсәре буенча куелган «Өч иптәш» («Три товарища») спектаклендә Патриция Хольман ролендә беренче мәртәбә тамашачыга күренә.
«Театрда уйнау миңа ныграк та ошый әле! Актриса буларак ачылып бетә алмыйм кебек. Кинода миңа кешеләр белән аралашу гына ошый.
Ә сәхнәдә һәр спектакль саен, үзгәрә барып, ролемне үзем теләгәнчә, үзем күргәнчә башкарам».



ФОНД ТУРЫНДА

«Элек мин гел театр-кино дөньясы кешеләре арасында гына кайный идем бит. «Гомер бүләк ит» дигән фондны оештыру һәм анда эшләү мине үзгәртте – тирә-ягыма бөтенләй икенче төрле карый башладым, дөньяга тагын да ныграк ачылдым. Янымда һәрчак гаҗәеп кешеләр: балалар һәм аларның әти-әниләре, табиблар, волонтерлар...
Бу тормышта нәрсәнең чыннан да мөһим, нәрсәнең чүп-чар икәнен аерырга өйрәндем. Гомердән, исәнлектән дә кадерлерәк бер нәрсә юк икән! Мин шуны аңладым. Сафсата сүзләрне бөтенләй тыңлый алмыйм».



«БОЗЛЫК ДӘВЕРЕ» ПРОЕКТЫ ХАКЫНДА

«Проектта октябрьгә кадәр генә булырмын да китәрмен дип уйлаган идем. Бәхетсезлеккә күрә, без партнерым Рома Костомаров белән алдынгы урынга чыктык. Аннан инде, әйдә, бу программаны гына яздырабыз да, әйдә, тагын берне генә дия башладык. Бозда барып төшәм, тагын торып басам, тагын егылам. Ә табиб... икенче партнерыма әйләнде! Фәкать сул терсәгем генә имгәнми калды бугай. Баш белән дә бәрелдем, оча сөягемне дә чатнаттым. Авыртуны баса торган уколлар гына коткара. Тагын бозга чыгып басам. Башкалар әллә нинди яңа элементлар ясаганда соң!..»



СОЧИ

Сочи. XXII Кышкы Олимпия уеннары-2014. «Фишт» стадионында ачылу тантанасының дулкынландыргыч мизгелләре. 40 мең тамашачы аренага төбәлгән! Музыка!.. Әнә алар, Россия горурлыгы булган шәхесләр Олимпия флагын алып чыга. Олимпия чемпионнары Лидия Скобликова һәм Вячеслав Фетисов, беренче хатын-кыз космонавт Валентина Терешкова, дирижер Валерий Гергиев, режиссер Никита Михалков, журналист Анастасия Попова, киберспортчы Алан Енилеев...
Безнең Чулпаныбыз да алар арасында!



БАЛАЛАР ТӘРБИЯЛӘҮ

«Әйбәт мультфильмнар – йөдәтмичә генә балаларны яхшы кеше итеп тәрбияләүнең иң үтемле чарасы. «Без үзебез иялләштергән затлар өчен җаваплы» дигәнне үзләштерә алган бала юньле кеше булып үсәчәк. Кызларым яшьтәшләреннән шактый аерыла: интернетта утырмыйлар, социаль челтәрләргә исләре китми. Арина белән Ася кино белән дә мавыкмый. Ә менә кечкенәсе – Ия – миңа ияреп, эшкә еш килә».

PRESSA.RU



СЕРЛЕ ЧӘЧӘК



Асия ЮНЫСОВА

ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН ҖЫРЧЫСЫ РЕЗЕДА ШӘРӘФИЕВА – КЫШ КЫЗЫ. КЫШНЫҢ КЫЛ УРТАСЫНДА ГОМЕР БӘЙРӘМЕН ҮТКӘРӘ УЛ. СӘХНӘДӘ. ТАМАШАЧЫСЫ БЕЛӘН!

Тамашачысы дидем. Ә мин үзем аның җырлавын күземне йомган килеш тә бер ялыкмый озак-озак тыңлый алам. Таң атканда чәчкәле болыннар өстеннән шуышкан бөдрә томанга да, җәй көзгә авышканда җаннарны төреп ала торган татлы сагышка да охшатам мин аның тавышын. Әйе, ашыкмый, ярсымый гына агыла торган бу моң табигать күренешләренә дә, күңелләрдәге, Җиһандагы серле үзгәреш, күчеш халәтенә дә тәңгәл килә торган тойгының музыкаль символы, чагылышы кебек тоела миңа.

Резеда Шәрәфиева моннан чирек гасыр элек моң дәрьясына талгын, әмма куәтле агым булып ничек килеп кушылган булса, дулкыннарын һаман шулай салмак кына тирбәтә. Үз кадерен белеп, дәрәҗәсен аңлап кына иҗат итүен белә.

Коңгырт күзле кызга Резеда дигән зәңгәр күзле чәчәк исемен бабасы Миңнеәхмәт куйган. «Баш балага исем миннән булыр, калган балаларыгызга исемнәрне үзегез табарсыз», – дигән, имеш, ул. Димәк, бу педагог бабай тәүге оныгын чәчәк сыман гүзәл итеп күрергә теләгән. Чыннан да, «кичен күзен йомып, иртән керфекләрен ача торган серле чәчәгем» дип җырлана торган җырдагыча чибәр дә, зифа буйлы да, кызларча серле дә булып җитешә Резеда.

Ашыктырабыз. Җитешкәнчегә кадәр сабыйлыктан чыгасы бар әле кыз баланың. Ә кызның «балалар бакчасы», әлеге дә баягы, әби белән бабай йорты. Заманында мәктәп директоры булган бабай да, кайчан гына әле мәктәптә рус теле укытып йөргән Зөһрә әбекәй дә авыл сәхнәсенең Хәлиле белән Галиябануы булган кешеләр. Димәк ки, берсе – гармунчы, икенчесе – җырчы. Бабай гармун уйнап, әби җырлап узган кичләрдә Резеда шым гына утыра. Ә менә алар берәр йомыш белән каралтыкурада йөргәндә Резеда – «сәхнәдә». Тамашачысы – көзге. Тавышын сынап карый бала. Юк тек юк инде, юк! Бабайның гармунын алып утырганда булдыра кебек. Шуңа күрә Резеда мәктәптә иң әүвәле гармунчы, хәтта ки баянчы булып танылa. Сыйныфташларын «Наза»га ул биетә. Үсә төшкәч, авыл клубында түгәрәк уртасындагы чын гармунчы да ул – Резеда!

Тик менә нигә соң әле ул ялгыз калдымы, һаман Әлфия Афзалова җырларын нәкъ аныңча аһәң белән җырларга азаплана? Килеп тә чыга кебек. Резеда Шәрәфиеваның альт дип бәяләнә торган тавышы әллә шул Әлфия апасына охшарга тырышып җырлаудан калды микән дип тә уйлап куям. Бик сирәк тавыш бит ул альт. Сопранолар тулып ята. Ә менә йөрәккә май булып ягылып, колакны иркәләп агыла торган, күкрәктән чыккан тавышлар бик сирәк. Шул сирәк тавышы белән тансык булды бугай да инде бу җырчыбыз.

> *Татар җыр сәнгате күгендә аның үз урыны ызанлап куелган. Инде аның хакында: бу бер балкыр, бер талпыныр да югалыр диясе түгел.*

Аның җырчылыгын иң беренче булып әнисе Рәйханә абайлап ала. Кызының өйгә кайткан һәр җыр тәлинкәсен үз тавышына «әйләндерүенә» берничә мәртәбә шаһит булганнан соң, ул бәбкәченә яратып кына тылсымлы канат белән кагыла: «Ишетеп йөрим, кызым, бик матур җырлыйсың. Гел гармунчы гына булып йөрмәссең. Сыйныфыгыз концерт әзерли бугай. Син бу юлы концертта җыр белән катнаш».

Җырлый, Резеда җырлый! Ул матур җырлый! Әнисе шулай диде бит! Әнисе куйган канатны җилпеп, Резеда очып кына тауга менеп төште, чишмә буйларын әйләнде. Рәхәт иде аңа.

Укытучылар көне уңаеннан куелган концертта хәйләсез, самими җыры белән чыккан иде ул мәктәп сәхнәсенә: Тау астында чишмәбез, / Су алырга төшәбез. / Татлы суын без аның / Бик яратып эчәбез...

Көрән күлмәктән, ак алъяпкычтан, ак бантиктан кыюсыз гына сәхнәдә басып торган кыз белән бүгенге Резеда арасында уртаклыклар эзлим. Киемдә түгел, репертуарда. Әле һаман да аның репертуарында татар эстрадасын 70 нче елларда тоткан җырчыларыбыз җырлаган җырлар күренгәләп китә. Әйтик, «Күл буена килсәң иде», «Китмим әле яшьлегемнән» ише үткәндәрәк калган хитлар. Тик шулай да Резеда Шәрәфиева-

Фото: Р. Шәрәфиева архивыннан

МӘДӘНИ ТОРМЫШ

PRESSA.RU



ның безгә таныш йөзен, имиджын дип, кыландырып әйтергә дә була, билгеләү өчен җырчының иҗатына йогынтысы тигән сәнгать осталарын, ягъни кумирларын ачыклыйсы иттем. «Лариса Долина иҗаты якын миңа. Валерияне хөрмәт итәм. Алла Пугачеваның сәхнәдә образ тудыру осталыгына кызыгам», – диде ул. Ә мин ул беренче чиратта Лайма Вайкуленны әйтер дип көткән идем. Сәхнә киеме җәһәтеннән генә түгел, җырларын театральләштереп тәкъдим итү кадәресе белән дә бу икәүдә охшашлык байтак. Иң беренче охшашлык, әлбәттә, затлылыкта, сәхнә культурасында. Ә бәлки, үз бәяңне, кадереңне белүдәдер.

Сәхнә киеменә һәр артистның үз мөнәсәбәте. Һәр артист костюмнар ярдәмендә үзенең бердәнбер һәм кабатланмас образын тудырырга тырыша. Без Зилә Сөнгатуллинаны принцесса күлмәкләре белән хәтерләп калдык. Мөнирә Булатованың королевалар стилендәге чия төсендәге бәрхет күлмәге күз алдында тора. Ир егетләр дә кием җәһәтеннән бик сайланучан. Резеда Шәрәфиева исә татар эстрада сәхнәсенә Европа стилен алып менде. Киң итәкләр, ялтыр күлмәкләр аныкы түгел. Ул ниндидер модерн стилендә киенә. Лайманың кепкасы, Резеданың эшләпәсе яки чалмасы, һәм һәр икесенең дә бердәнбер дизайндагы күлмәкләре. Охшашлык киемдә генә дә түгел. Җырчыларның икесе дә сәхнәдә бәләкәй генә спектакль уйный. Әле тагын һәр икесе, синең өчен генә сыман итеп, берәр мәхәббәт тарихын сөйли. Ниндидер серле тембр, интим бер аһәң белән тамашачыны үзенә теләктәш, сердәш итә. Мондый якынлыктан күңел кытыкланып, алгысып кала. Якын итеп серләшү кемгә ошамас – шуңа күрә дә башта Чаллыда, аннан Казанда балкыган бу якты талантны барыбыз да яратабыз. Һәрхәлдә, берәүдән дә, туйдырып бетерде инде бу Резеда, дигәнне ишеткәнем юк. Киресенчә, аны телевизион спектакльдә дә күргәч сөенгәннәрен хәтерлим. «Сөю көтә йөрәк» телефильмының уңышын ул тәэмин иткән иде бит инде!

Минзәлә районының Наратлы Кичү авылында туып-үскән кызның бернинди музыкаль белемсез эстрада йолдызы булып китүенең серен эзлим. Җавап, көтелгәнчә, гади. Һәр уңыш – тәвәккәллек, тырышлык, талант җимеше. Әлбәттә, кайбер чакта күктә йолдызларның уңайлы урнашуы да ярап куя торгандыр. Бу кадәресен ничек бәялисең бит әле. Әйтик, мәктәпне тәмам иткәч, әни сүзен тыңлап, Минзәлә педагогика көллиятенә бару – уңай фал. Ә менә укытучы дипломы белән Кадрәк авылына килеп төшкәч, интернатта тәрбияче генә булып йөрүе иҗат юлындагы бер тоткарлык түгелме? Димәк, монысы уңай фал түгел. Әгәренки, кыз шул дипломын тотып, пединститутның музыка факультетына укырга килгән булса... Казанга дим.

Килә ул Казанга. Ләкин бизәүче рәссамнар хәзерли торган профтехучилищега. Артка таба бер адым дияр идем дә... Кыз рәссам итеп тә күргән икән үзен. Хәтта ки, хыялланган! Аннары ул Казанда укыганда «Саз» ансамбленә йөреп ала. Бизәүче рәссам сыйфатында Чаллыдагы «Хатын-кызлар өчен киемнәр» кибетендә



эшли башлавы без белгән нечкә зәвыклы Резеданы тәрбияләгән мәктәп түгелме соң?

Булачак җырчыны Чаллыдагы «Кыйбла» клубы җитәкчеләре манекеннар арасыннан «табып ала». Чакыралар, кызыктыралар. Канында җыр типкән кешене алгысыту кыенмыни соң!

Сәхнәгә, чын сәхнәгә, олы сәхнәгә чыга Резеда. Ә бу вакытта Чаллы җырчылары эстрадада әйдәп бара. Анда Салават җырлый. Фән Вәлиәхмәтов гармун сайрата. Мәскәүдән Хәния Фәрхи кайтып төшкән. Гөлдания Хәйруллина бар, Асия Әхмәтшиналар халыкны «уята». Резеда шулар янына иш булып, тиң булып кушыла. «Торналар киткәндә» (В. Фәттахова, З. Хәйретдинов) белән каршы алды аны тамашачы. Шул җәйдә үк шәһәркүләм конкурста беренче урынны алган иде ул. Тиздән кыз композитор Ренат Гобәйдуллин оештырган «Сердәш» ансамбленең примасына әйләнеп китә. Шул заманнан ук төннәр буе үзенә кием тегә Резеда. Кисә, тегә, боза, сүтә торгач, көтмәгәндә, яңа модель килеп чыга. Әнисенең иске тегү машинасы икенче яшьлеген кичерә.

Шул төнлә туган «модельле» күлмәкләре белән кабул итте инде аны Казан. Бу юлы җырчының адресы – «Казан» милли мәдәният үзәге. Менә унбиш ел инде ул шунда. Татар Конгрессының бер генә мәдәни чарасы да Резеда Шәрәфиевадан башка узмый.

Бу урында, журнал укучыларга бер бүләк булсын әле дип, Резеда белән җәһәт әңгәмә корып алам:

– Синең тормышыңда иң зур урын биләгән нәрсә җырмы ул, әллә...

– Яратусыз яшәп булмый. Минем тормышымда мәхәббәт бар. Шул мине бәхетле итә. Әниемне, туганнарымны, кызымны бик яратам. Әнием кыш минем янда тора. Җәйгә Наратлы Кичүгә кайта. Ул анда йөзләп каз асрый, бәрәңге утырта, җиләк-җимеш үстерә. Без – дүрт баласы җәйгә аңа ияребез. Мәхәббәт дөньямның уртасында – кызым Зөләйха! Без аның белән йоклаганда да җитәкләшеп йоклыйбыз. Җитәкләшкән килеш төнгелеккә дога укыйбыз. Кызым белән бергәләп «Фитнес-планета»га йөрибез.

– Кызың җырлап китәр дисеңме?

– Китмәс дим, бер билгесе дә юк. Йөкле чагымда мине күргән һәр кеше: «Балаң җырчы булыр инде», – ди торган иде. Ә мин көмәнемне, күз тиюдән саклап, учларым белән каплый торган идем. Күрәсең, җырчы юрамасыннан да аралаганмындыр.

– Тормыш шигареңне белик әле.

– «Ашыккан ашка пешкән». Иң яратмаганым ашыгу. Тик һаман ашыгырга туры килә. Ә менә әни миңа: «Үзеңне сакла!» – ди.

– Зөләйхаң синең бердәнбереңме. Димәк, Кадрәктә юлыккан мәхәббәтең димме, ялгышың димме, җимешсез төгәлләнгән.

– Шулайрак булды шул. Җиде ел бергә яшәгән идек югыйсә. Үкенмим. Мин хатын-кыз бәхетен татыдым. Мине яраталар, кайгырталар...

Манекеннарны тегеләй-болай киендерә-киендерә, Резеданың киләчәк сәхнә имиджы тәгаенләнгән.

– Димәк, дөньяң түгәрәк. Ә шулай да, сайлау мөмкинлеге булса, кайсы илдә яшәр идең?

– Үз илемдә! Чит илдә үлеп калудан бик куркам мин. Хәтта ялга да бармыйм.

– Ял димәктән...

– Ял иткәндә җыр тыңламыйм. Өй җыештырам. Тәртип яратам. Киемнәремне берәм-берәм киеп карыйм. Күлмәкләрнең хисабы юк. Туфлиләрем генә дә 30-40 кием.

– Шигырьләр яздырылган дискта синең фамилияне күрдем...

– Нурия Измайлова шигырьләре. Бик яратам мин ул шагыйрәне. Рухи якынлык сизәм. Шигырьләрне елыйелый укыйм мин. Берара, ике айлап булыр, гел шигырь дөньясында яшәдем.

– Алда сезнең бәйрәмнәр – әниеңнең, үзеңнең, кызыңның юбилейлары – 70, 50, 10 яшь – бөтенесе дә шундый күркәм саннар. Бәйрәмнәр, табыннар, алкышлар!

– Зур гаилә булгач, бәйрәмнәр дә матур уза безнең. Табын әзерләргә бик яратам. Майсыз үрдәк, бәлеш, каз пешерәм. Әти ядкаре итеп, бишбармак әзерлибез. Әти яшьлегендә Казакъстанда яшәгән. Бу ризыкны ул өйрәтеп калдырды.

– Яңа елда журнал укучыларга нәрсә теләр идең?

– Илгә-көнгә иминлек! Исәнлек – барыбызга да!

PRESSA.RU

Кайгыда да, шатлыкта да бергә булырга сүз куешкан парларның кайберсе авырлыкны, тормыш сынауларын күтәрә алмый. Гаиләсен ташлап кача. Ирләр генә түгел, хатын-кызлар да шулай итә. Ә шулай да, аларның бер-берсенә терәк-таяныч булырдайлары күбрәк бу дөньяда. Хөрмәтле укучылар! «Кайгыда да, шатлыкта да» дип исемләнгән яңа рубрика тәкъдим итәбез. Сездән кызыклы, гыйбрәтле язмалар көтәбез.

Фото: Евгений Канаев

ӨМЕТСЕЗЛЕК – ҮЛЕМГӘ ТИҢ



Мәдинә
АВЗАЛОВА

МОҢАРЧЫ ЯМАН ШЕШ АВЫРУЫ ТУРЫНДА АЛАР ИШЕТЕП КЕНӘ БЕЛӘ ИДЕ. УЛ ЗӘХМӘТ АЛАР ГАИЛӘСЕНӘ БЕРКАЙЧАН ДА КАГЫЛМАС ШИКЕЛЛЕ ИДЕ. ҺӘМ МЕНӘ, ҺИЧ КӨТМӘГӘНДӘ, ШУНДЫЙ ДИАГНОЗ...

лда ни кѳтәсен, иртәгә ни буласын, язмышыңа ни язганын берәү дә белми. Әйе, тугач та маңгаеңа язылган була, дисәләр дә, белмибез. Кинәт килгән кайгы-хәсрәткә дә адәм баласы әзер түгел. «Ник гел миңа?» – дибез. Бу тынгысыз тормышта безне адым саен ни дә булса сагалап тора. Ул әле ярларына сыеша алмыйча котырган иксез-чиксез диңгез шикелле, әле берәүгә дә комачауламыйча тын гына агып яткан елга шикелле – бүген болай, иртәгә тегеләй. Бәлкем, Аллаһы Тәгалә безне дөнья йөген бергә күтәрсеннәр, шулай җиңелрәк була, дип, парлы иткәндер?! Кайгыны да, хәтта шатлыкны да лаеклы күтәрергә кирәклегенә ишарәдер ул, бәлкем. Кызганычка каршы, тормыш гел син дигәнчә генә бармый. Гел сыный да сыный ул кешене!

Бер-берсе өчен җан бирмәктән

Бу дөньяда бер-берсе өчен өзелеп торган парлар барлыгына, әгәр дә үз күзләрем белән күрмәсәм, әйтсәләр дә ышанмас идем. Алар икесе дә илледән узган. Гомернең яртысыннан күбрәге артта, тынгысыз еллар артында калган, димәк. Әмма үз-үзләрен тотышларына, бер-берсенә шулкадәр дә назлап, яратып караууларына, бер-берсенә җанны эретердәй итеп әйткән җылы сүзләренә караганда, алар – әле, менә әле генә танышкан егет белән кыз шикелле. Бер-бер артлы сорауларымны яудыра-яудыра, үзләрен гашыйклардай тоткан ир белән хатынны читтән генә күзәтәм. Менә гаделсезлек кайда ул?! Матур итеп, башкаларга үрнәк булып күктәге сүнмәс йолдызлар сыман балкыйсы да балкыйсы, яшисе дә яшисе бит әле аларга...

– Мин аннан башка яши алуымны күз алдына да китерә алмыйм, – ди әкрен генә сүз башлап ир. – Без – Сафиннар. Мин Рәис булам, хатыным – Людмила. Икебезнең дә икенче никахыбыз. Әйе, әйе, – ди ул йөземә чыккан гаҗәпләнүне күреп. – Узганыннан аның да ике, минем дә ике бала. Хәзер унбиш ел бергә... Ул бер якты мизгел булып узды да китте. Шашып яраткангамы, аның белән узган һәр көнем димим, һәр сәгатем минем өчен зур бәхет, олы бүләк. Кайчандыр шулай дип әйтсәләр, көләр генә идем. Бар икән ул сөю! Мин аны шундый яратам.

Янәшәсендә аңа сыенып диярлек утырган хатынның күзләренә яшь тула. Ире аңа карата булган хисләрен беренче мәртәбә генә әйтмидер. Әмма чит кеше янында менә шулай мөлдерәмә ташып түгелүе, аны чиксез дулкынландыра бугай.

– Мин дә сине яратам, – ди хатын пышылдауга күчеп. – Аларга яннарында мин булу да комачауламый. – Яратам, – ди дә, сүзне шундук икенчегә бора. – Менә бит... Һич уйламаганда булды. Табиблар: «Күкрәгеңдә яман шеш», – дигәч, еладым да еладым. Янымда ирем булмаса, шул килеш үлеп китәргә дә риза идем. Ишеткәч, яман авыр булды. Аннары тора-тора үземне кулга алдым. Туктале, мин әйтәм, бу бит минем генә кайгы түгел, гаилә кайгысы. Мин алар хакына яшәргә тиеш! Узган ел оныклар белән бергә диңгезгә барган идек. Кояш шулай тәэсир иттеме, белмим... Адәм баласын күрәчәк йөртә бит.

– Бер дә сизелмәдемени, бик соң мөрәҗәгать иткәнсез түгелме?

– Сизелми икән бит ул. Хатын-кызга тыгызланып торган урыннар юк микән, дип, күкрәкне әледән-әле капшап торырга кушалар. Ә мин инде капшамыйча да беленә башлагач кына аңыма килдем. Аркаларым сызлый иде сызлавын. Анысын остеохондроз, диделәр. Мин шуннан тынычландым. Онкологларга күренергә башка да килмәде.

Яман шеш авыруы елан кебек. Астыртын чагып ала. Шуңа без – ханымнарга, туташларга һичьюгы елына бер тапкыр маммологка күренергә әйтәләр дә. Әйтәләр генә түгел, кисәтәләр дә безне. Соңыннан соң була, дип күпме сөйләгәнебез бар. Людмиланың – өченче стадия. «Без өметләнәбез әле, – ди алар, икесе бер булып. – Тереләчәккә ышанабыз. Безгә башкача ярамый».

Алар икесе дә Яшел Үзән районында суднолар, корабльләр проектлау-конструкторлык бүлегендә эшлиләр. Ир – бүлек җитәкчесе, хатын аның кул астында эшли. Икесе дә – конструктор. Гаиләгә шундый бәла килүен белгәч, хезмәттәшләре, дәррәү килеп, ярдәмгә алынган. Сафиннар аларга чиксез рәхмәтле. Кеше менә шундый чакта беленә бит ул. Ул инде алты мәртәбә химиотерапия алган. «Хәзер хәлем әйбәт, – ди Людмила Анатольевна. – Сөякләрне ныгыта торган даруларны да күп эчтем. Сәламәтлекне торгыза торган сеанслар да алдым. Барысы да бушлай. Республика клиник онкология диспансерының Гүзәл Мөхәммәтшина җитәкчелегендәге химиотерапия бүлеге коллективы мине тормышка кайтару өчен барысын да эшләде. Рәхмәт аларга!

Аларның мәхәббәте бөтен каршылыкларны да җиңеп чыгар сыман.

Тормыш – куласа – бер әйләнә, бер баса. «Әле кайчан гына, – дип искә ала ярату һәм яратылу бәхетен тулысы белән татыган ханым – 14 март – туган көнемдә – якын туганнар, балалар, оныклар җыелган түгәрәк өстәл артында: «Бу дөньяда миннән дә бәхетле кеше юктыр. Мин яратам һәм мине дә яратучы кадерле кешем янымда, бөтен теләгәнем тормышка ашты», – дип куанган идем. Шунда кайнанам: «Мондый сүзләрне кычкырып әйтмиләр, күз тияр», – диде. Һәм ни дип уйлыйсыз? Нәкъ унбиш көн узуга – 1 апрель көне иде – аяктан егарлык шундый хәбәр ишетәбез. Бер мизгелдә тормышның асты өскә килде. Көннәребез аңа кадәр һәм аннан соңга бүленде. «Ни өчен миңа?» дигән сорауны үз-үземә кат-кат бирдем. Әллә гөнаһларым күтәрә алмаслык-

PRESSA.RU

мы, дип уйлаган чакларым да күп булды. Тик җавап кына таба алмадым. Бәлкем, Ходайның гел рәхәттә генә яшәмә, болай да яшәп кара әле, дип сынавыдыр. Дөресен әйтәм, әгәр дә Рәисем булмаса, мин инде күптән чиргә бирешкән була идем. Шундый вакытта ышанычлы таянычың-терәгең булу зур табыш, бәхет икән ул! Мин чирне җиңәрмен дип уйлыйм. Һичьюгы беразга гына булса да чигенеп торыр. Мондый хәлдә гомернең бер көне дә кадерле икәнлеген аңлыйсыздыр.

– Юк, юк, алай димә, – дип туктата аны шундук ире. – Без бит инде синең белән бер мәртәбә уздык язмыш сынауларын. Хәтерлисеңме, күзеңә операция ясаткан чакларны. Син ул чагында да төшенкелеккә бирелдең. Барысы да әйбәт булыр, дидем. Һәм шулай булып чыкты ул.

Мондый вакытта кадерле кешеңнең кайгыртуын тою – аеруча мөһим.

Моннан ун ел чамасы элек Федоров клиникасында хатынның күзенә операция ясыйлар. Хәзер аның бер күзе күрми. Ул вакытта да ире Людмила яныннан бер адымга да китми. «Белмим, ансыз нишләгән булыр идем?» – ди ул, авыр сулап. Бүген өйдәгеләр Людмила Анатольевнаны «безнең бәләкәй Людочка» дип йөртәләр. Ире, балалары аңа хәтта өйдәге вак-төяк эшләргә дә кул тидертми. Бөтен эшне ире эшли. «Кухняга кертмиләр, өй җыештыртмыйлар, менә шундый иркә хатын, әни инде мин хәзер», – ди ул, кинәт моңсуланып китеп.

Саубуллашабыз. Озак вакытлар колак төбендә хатыны үлем белән тартышып яшәргә мәҗбүр булган ирнең йөрәк өзгеч сүзләре яңгырап тора: «Бергә узган гомер күз алдына килә дә, авыр булды диярлек бер генә көнне дә хәтерләмим. Юк ул чөнки. Без әйбәт яшибез. Алга таба да яшәргә дә, яшәргә иде әле безгә...»



Республика клиник онкология диспансерының химиотерапия бүлеге җитәкчесе, «Россиянең дәүләт премиясе лауреаты», Татарстанның атказанган табибы, медицина фәннәре кандидаты Гүзәл МӨХӘММӘТШИНА:

«СОЦИАЛЬ ПАКЕТТАН БАШ ТАРТМАГЫЗ!»

– Күкрәктә яман шеш авыруы очраклары әкренләп кимүгә таба барса да, пациентларыбызның 10 проценты маммологка чире соңгы стадиягә җиткәч кенә килә. Мондый авыруларга башта җитди операция, аннан соң озак еллар дәвамында, чир кире әйләнеп кайтмасын, мәкерле ул күзәнәкләр яңадан тамыр җәймәсен өчен, химиотерапия курслары узарга туры килә. Чөнки шешне алсалар да, чирнең килеп чыгу сәбәбе кала бит. Әйе, бу җиңел процедура түгел, күпләр аннан курка. Куркырга да, авыр кабул итәргә дә кирәкми. Кешенең гомерен биш-алты елга, ә кайчак дистәләгән елларга озайту өчен чын мәгънәсендә көрәш алып барабыз. Бүлектә III һәм IV стадиядәге авырулар дәвалана.

Әйтәсе килгәнем: пациентларыбыз социаль пакеттан баш тартмасын иде. Югыйсә амбулатор дәваланулар кыйммәткә төшәчәк. Людмила Сафина бездә май аеннан бирле дәвалана. Алты мәртәбә химиотерапия дә алды, сөяк ныгыта торган уколлар да... Ире дә һәрчак янында. Алар бирегә җитәкләшеп киләләр, җитәкләшеп китәләр. Чирне, кыскасы, бергә күтәрәләр. Хатыны өчен таулар күчерергә торган ирләр сирәк ул. Без аларга карап сокланабыз инде. Ә бит шундый хәлдә калганда, янына бер генә мәртәбә дә килеп карамаучылар очрый. Андый пациентларга икеләтә игътибарлы булырга тырышабыз. Яннарында ешрак булабыз, сөйләшәбез, җылы сүзләребез белән күңелләрен күтәрәбез. Башкача булуы мөмкин дә түгел. Безнең шәфкать туташлары шундый алар... Гомумән, авыру кадерле кешесенең ярдәмен, кайгыртуын тойса, аякка тизрәк баса. Яшәү мәгънәсе барлыкка килә. Төрле хәлләр була, барысы да безнең күз алдында бит.

Кабатлап әйтәм, инвалидлар өчен мондый вакытта социаль пакетның булуы аеруча мөһим. Безнең авыруларның 70 проценты (күз алдына китерәсезме?!) аны кирәкле санамый. Чирне бик мәкерле, дидек. Бүген хәлегез әйбәт, ә иртәгә кинәт начарланып китәргә, ашыгыч рәвештә операция ясатырга кирәк булуы ихтимал. Операциясе бушлай булса да, тернәкләнү чорында әлеге дә баягы социаль пакет кирәк булачак. Үкенерлек булмасын дим...

КЕШЕ КИТӘ – ЖЫРЫ КАЛА, ДИП ЕШ КАБАТЛЫЙБЫЗ. ӘЙЕ ШУЛ, ЖЫРЛАРНЫҢ ШУНДЫЙ ХАСИЯТЕ БАР. АЛАР ГОМЕРНЕҢ БЕР МИЗГЕЛЕН ГЕНӘ ТҮГЕЛ, ТУЛЫ БЕР ГОМЕРНЕҢ ҮЗЕН ДӘ СЫЙДЫРЫРГА СӘЛӘТЛЕ.

Асия Юнысова

СӘФӘР

Кама Тамагы төбәгеннән, Олы Мәрәтхуҗа авылыннан кайтып киләбез. Сәфәрнең максаты – хөрмәтле, мәңге хәтердән җуелмас кешебез Туфан Миңнуллинның тергезелгән нигезен күреп кайту иде. «Тергезелгән» дидем. Әле кай заман гына тормыш кайнаган, иҗат кешеләрен магнит кебек тартып торган нигез иде ул. Юк, магнит хасияте нигездә түгел, Туфан абыйның үзендә иде шул. Туфан абый безне дә, нигезен дә мәңгелеккә ташлап китүгә алмагачлар кыргыйланды, бәрәңге бакчасы кысыр калды, көнбагышларны чыпчык чүпләп бетерде, киртә буйларын алабута, кычыткан сарды. Ул гына да түгел, Туфан абыебыз үзе: «Язучыларга иҗат йорты итәм әле мин аны», – дип хыялланган ике катлы бүрәнә өйгә ут үрләгән. Ярый әле, көлгә әйләнергә ирек бирмәгәннәр...

Олы бер төркем булып килгән әдипләр, Туфан абый ихатасында өлкән остазның үзен генә түгел, бәлки, үзләренең яшьлекләрен дә сагынып йөриләр. Боеклар. Йә кемнең тора салып җорланасы килсен инде. Югыйсә хатирәләре барысы да күңелле: кемдер мунча өчен бүрәнә юнып азапланган, кемдер чишмә юлында трактор арбасыннан тәгәрәп калган, кемдер Туфан күленнән балык тоткан... Һәр хикәят артында Туфан абыйның хәйләкәр елмайган күзе, мөлаем, ягымлы йөзе карап тора. Теге яна башлап калган өйнең күмерләнгән иргәләре генә сагайта. Кемгәдер үпкәлисе килә. Тик кемгә? Туфан Миңнуллин мирасына илтифатсызлыкның адресы кай тарафта.



Ярый, гаеплесе билгесез булса да, җаваплысы табылган. «Таттелеком» хуҗасы Лотфулла Шәфигуллин исеме күп мәртәбәләр рәхмәт белән телгә алынды. Чөнки хәзер нигез Мәрәтхуҗа кешеләрен өркетеп, шомландырып тормый: чистартылган, тергезелгән. «Иншалла, сукмак өзелмәс», – ди ирекледән нигез коменданты булып алган Миңнур Нәбиуллин. Осетин шагыйре Коста Хетагуровныкы яисә латыш әдибе Ян Райнисныкы кебек сокланып таң калырлык булмаса да, ярап торырлык.

Күрдек. Йөрдек, Сагышландык. Инде кайтабыз. Көне дә үзе салкынча, үзе моңсу. Туфан абыйның авылдашлары да нәүмиз генә озатып калдылар.

Микроавтобус эчендә ут кабызып тормадылар. Халәтенә күрә тәңгәл! Шунда Нәбирә Гыйматдинова тыенкы гына җыр башлады. Зөлфәт сүзләренә җырлана торган халык көе – «Чатырлар». Тын да алмый тыңладык. Бу җырга икенчесе кушылды. «Кызыл төлке». Шәмсия Җиһангированың Зифа Басыйрова тавышына охшаш контральтосы. Кызлар җыры егетләрне дә уятты. Матур баритоны белән Рафис Корбан җыр башлады. Аңа башка егетләр кушылды. Кара сана, Газинур Морат яхшы шагыйрь генә түгел, моң иясе дә икән. Төнге тынлыкны ярып, машинаның тыйнак гөрелтесен басып, халык көйләрен сибә генә. Автобус гастрольдән кайтып килүче артистлар хөкемендә диярсең. Шофер янәшәсендә утырып баручы шагыйрь Рөстәм Закуанов та йөрәк түреннән ирек даулаган җыр көченә озак карыша алмады. Бер тын паузадан файдаланып, машинаның йөртүчесе дә матур җырлый белгәнен исбатлады. Барысына да моң, җыр кирәк иде күңел кузгалган бу сәгатьтә. Туфан абыйны бүтәнчә тагын ничек итеп сагынасың?!

Шагыйрьләр Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла, җае белән генә җырга кушылып алалар, күбрәк әсәрләнеп тыңлыйлар. Туфан абый да шулай итә торган иде. «Ватаным Татарстан»га кунакка килгән чакларында әйтер иде: «Йөгез, берәр моңлы җырны әйттерегез әле», – дип. Без аның «Озата барма»ны, «Кошлар тынды»ны яратканын белә идек. Якташы Гажилә апа «Айкала суларыгыз...» белән күңелләрдә бәйрәм ясаганда, Туфан абый да кушылып китә торган иде. Шул күңелле – Туфан абыйлы заманнарны сагындырып искә төшерде бу концерт. Ә бит Туфан Миңнуллин пьесасы буенча куелган һәр спектакльдән халыкка бер җыр кала торган иде. «Мин җырлыймын шырдыйны...» гына түгел. Тергезелгән халык җыры – «Мәдинәм-гөлкәем», «Сибелә чәчәк», «Карлыгачлар ояда»... Туфан абый меңләгән күңелләрдә җыр калдырып китте.

PRESSA.RU



ЕРАК ИКӘНЕН ДӘ БЕЛӘМ...

Мәсгут
ИМАШЕВ

«Таң атканда уйланам, су акканда моңланам...» Аһәңле, ягымлы тавыш, үзенчәлекле бормалар... Якташым, Барда кызы Гүзәл Уразова җырлый. «Утлар яна учакта» спектакленнән Гүзәлия җыры, әйтерсең, нәкъ менә аның тавышына туры китереп язылган. Илле еллар элек минем күңелдә туган моңны, хис-кичерешләрне яңача төсмерләр белән баетып, заманча бизәп, җанга ятышлы итеп тамашачыга җиткерә. Алкышлар! Чәчәкләр! Ә мин күңелем белән ерак 60 нчы елларга китеп барам...

Бу җыр Әлмәттә туды. Гадәттә, җырның өч авторы була, ә бу җырныкы дүртәү иде. Шагыйрь, композитор, җырчыдан тыш, пьесаның авторы Гариф Ахунов та бар әле!

Консерваторияне тәмамлагач, 1964 елның августыннан ачылачак Әлмәт музыка училищесының директоры булып эшли башладым. Ул вакытта Әлмәттә иң зур зал нефтьчеләрнең Техника йортында иде. Төрле конференцияләр, концертлар, спектакльләр шушы залда үткәрелә. Ә сәхнә артындагы бер бүлмәдә Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге урнашкан. Ниндидер концерттан соңмы, әллә берәр җыелыш булды микән, мин Язучылар берлегенә кердем. Бүлмәдә кешеләр байтак. Арадан берсе, елмаеп килеп, миңа кулын сузды:

– Мәсгут, сине барыбыз да беләбез, мин – Әлмәт язучылар оешмасы рәисе Гариф Ахунов, таныш булыйк, – диде.

Шуннан соң Гариф мине бүлмәдәге кешеләр белән таныштырып чыкты. Хәтерем ялгышмаса, анда ул көнне Әдип Маликов, Гамил Афзал, Сәет Кальметов, Юныс Әминов, Саҗидә Сөләйманова, Рафаил Төхфәтуллин, Клара Булатова, тагын кемнәрдер бар иде. Аннары Гариф мине үз бүлмәсенә алып керде, сөйләшә-сөйләшә, эш урыны белән таныштырды. Безнең дуслык шулай

Гүзәлия җыры

Таң атканда уйланам,
Су акканда моңланам.
Таң нурында
син йөзәсең,
Утларыңда мин янам.

Биек тауга менимме,
Агымсуга керимме?
Дусларыма
сөйлим микән,
Үзем генә белимме?

Таулар – текә,
су – тирән,
Тирән булса да, керәм.
Ерак икәнен дә беләм,
Нигәдер якын күрәм!

Фото: автор архивыннан

башланды. Гариф белән кайда гына, нинди генә шартларда күрешсәк тә, тормышның нинди генә хәлләре турында сөйләшсәк тә, миңа рәхәт иде, күңелем тынычлана иде.

Күп тә үтмәде, Әлмәт театры җитәкчеләре мине куелырга әзерләнүче «Утлар яна учакта» дигән спектакльгә музыка язарга чакырдылар. Пьесаны Гариф Ахунов язган икән. Бу инде Гариф белән тагын да якынрак аралашу дигән сүз иде.

Спектакль өчен шигъри сүзләр язарга ул Саҗидә Сөләймановны чакырган иде. Гариф Ахунов мине шагыйрә белән очраштырды. Сары чәчле, зәңгәр күзле мөлаем ханым. Аның шигъри җанлы булуы йөзендә үк балкып күренә. Мин аны әнә шулай кабул иттем. Өчәүләп кайсы образга нинди җыр кирәклеген тәгаенләдек тә, эш башланды. Спектакль нефтьчеләр тормышына багышланган. Мин төрле җырларга, биюләргә музыка язарга тиеш идем. Режиссер сораган музыкаль бизәлешләр нотага салынгач, Гариф Ахунов, Саҗидә Сөләйманова, балетмейстер Марат Камбулатов, режиссер Габдулла Йосыпов һәм мин, театрга җыелып, җыр-көйләр белән таныштык. Хуплап каршы алдылар һәм спектакльгә тагын да музыка өстәргә кирәк дигән фикергә килделәр. Төп рольләрне бик талантлы яшь актриса Луиза Солтанова (Гүзәлия) һәм җырга оста, моңлы тавышлы артист Рафаил Сабиров (Сәлахи) башкарачак иде.

Май алды көннәре. Табигатьтә дә, күңелдә дә нindидер күтәренкелек. Без куеласы спектакль, андагы җырлар дулкынында очып-илһамланып йөрибез. «Гүзәлия җыры» аеруча халыкчан, җанга ятышлы тоела. Бәйрәмгә «Утлар яна учакта»ны чыгардылар. Премьера шаулап үтте. Спектакль Уфада, Казанда күрсәтелгән чакта да яхшы бәя алды. Драматурглар һәм театр сәнгате эшлеклеләре киңәшмәсендә ул 1965 елның иң яхшы спектакле дип табылды.

...Ул чакта Гариф шатлыгыннан очынып йөрде, йөзеннән елмаю китмәде. Хәер, Гариф кына түгел, һәммәбез сөенештек. Әле бүген дә шул спектакльгә язылган «Нефтьчеләр маршы», «Гүзәлия җыры», «Сәлахи җыры» яңгыраганда, күз алдыма һәрвакыт елмаеп-шатланып Гариф килеп баса.

«Утлар яна учакта» спектакленең премьерасыннан соң, Гарифлар өендә банкетка җыелдык. Театр артистлары, режиссер, рәссам гына түгел, кием тегүче, грим салучы, машина йөртүчеләренә кадәр чакырылган. Ахуновлар фатирына, Әлмәт язучыларын да кушсаң, берьюлы җитмеш кеше кереп тулгандыр. Ул банкетта мин гомеремдә беренче мәртәбә «урындыкларсыз кунак»та булдым. Бәйрәмдә катнашасы дус-ишләрнең чамадан тыш күп буласын абайлап, хуҗалар өстәлләрне стена буена (бигрәк тә, почмакларга) терәп куйганнар да, урындыкларны җыеп алганнар – барыбыз да аяк өстендә. Бер кечкенә бүлмәдә арыганда ял итәргә куелган берничә урындык кына бар. Өстәлләр тулы сый-нигъмәт, кайсын ошатасың, шунда барып авыз ит. Ә Гариф белән хатыны Шәһидә ханым, бүлмәләрнең әле берсенә, әле икенчесенә кереп, һәркемне аерым-аерым сыйлап йөриләр...

«Утлар яна учакта»ны кайчан, кайда карагандыр, «Гүзәлия җыры»н үз репертуарына алып, мәшһүр җырчыбыз Әлфия Афзалова бик яратып концертларында җырлады. Бу җырны шулай ук күп еллар инде, җаннарны иркәләп, моңлы тавышлы Флера Сөләйманова да җырлый. Бәхетле җырым булды ул. Күптән түгел Илһам Шакировның дискын тыңлап утырганда, шушы җыр килеп чыкты – Илһам җырга башка исем кушып җырлаган. Гадәттәгечә, Илһам шәп җырлый, рәхмәт аңа!

Шул җыр белән бәйле бер очракны искә төшерәсем килә. Әлмәттә эшләгән чагым. Ашыгыч рәвештә Казанга очарга кирәк. Әлмәттән Бөгелмә аэропортына билетлар беткән. Бер автобус китәргә тора. Бардым шоферына. «Урын юк, мин колхоздан студентлар алып кайтам», – ди. Кердем автобуска, шыплап тулган, гел кызлар гына. «Урын тапсаң, утыр, абый!» – диделәр. Арткы почмакка барып сеңдем. Кузгалдык. Кызлар бәрәңге җыйганнар, күңелләре көр: уен-көлке, шаян сүзләр, көлешүдән автобус селкенә һәм җыр, җыр, җыр... Кыска такмаклар, сузынкы моңлы көйләр һәм кинәт... «Гүзәлия җыры»! Йөрәгемнең сикерүенә чак түзеп барам. Шыгрым тулы автобус кызлары бер тавыштан синең хисең белән тулган, синең моңыңа төрелгән көйне яңгыратып җырласыннар әле – ничек түзмәк кирәк... «Мин монда!» – дип кычкырасым килә, ләкин дәшүем әдәпсезлек буласын аңлап, ләм-мим.

...Ничә еллар инде «Гүзәлия җыры»мны кайларда гына, кемнәрдән генә ишетмәдем! Ул еракта калган яшьлекне, иҗатташ дусларны сагындыра, мине яңа җырлар язарга илһамландыра.

Рәсемдә *(сулдан уңга)*: Мәсгут Имашев, Вазыйх Исхаковның кызы Венера, Вазыйх Исхаков, Рафаил Төхфәтуллин, Вазыйх Исхаковның хатыны Зимфира, Шәһидә Максудова, Гариф Ахунов, Сания белән Фазыл Мостафиннар, Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов. Әлмәт, 1965, сентябрь.

PRESSA.RU

Эш арасында сатучы кыз үзе дә картиналар буйый, алардан кечкенә генә күргәзмә дә ясап куйган — монысы сатып алучыны җәлеп итү өчен кирәктер. Алган әйберләребезгә түләп, яныннан киткәндә, аның буйый башлаган картинасы янында туктадым. «Башлаганга ике ай. Яңа елга тәмамлармын дип уйлыйм», — диде ул. Бер картина белән шулкадәр гомер утырыргамы?! Миннән булмас бу, түземлегем җитмәс...







Гөлнур САФИУЛЛИНА

ҖЕТЕ ТӨСЛӘР КҮШАМ...

Ел саен шулай – чамасыз озын булып тоела да, күз ачып йомганчы узып та китә ул. Сизми дә каласың! Кышкы каникулларны әйтәм. (Соңгы вакытта ел башлануга әллә кайдан килеп чыккан бу ун көн ялны, мәктәп балалары кебек нигәдер «каникул» дип атарга ияләштек бит.) Иртәгә эшкә дигән көнне шаккатасың: булдымы бу ун көн, әллә юкмы? Югыйсә барысын да алдан планлаштырган да кебек идең: кайларга барырга,ниләр эшләргә... Әллә озын ял дип, планны чамасыз күбрәк төзеп ташлыйбыз, белмим. Әмма каникул ахыры гел үзеңнән канәгатьсезлек белән тәгәлләнә.

Югыйсә барысы да ел саен кабатлана. Яңа елның беренче көнендә йөз дә беренче тапкыр «Ирония судьбы...»ны карау. (Ипполит кебек перспективалы кияүдән баш тартып, Надяның Женя янына китүен бүгенге яшьләр аңламый, кабул итми инде. Шуңа күрә аларның бу сериалга исләре китми. Мәхәббәтнең яктылыгын, матурлыгын күрү, тою өчен карасалар да ярар иде дә бит... Үткәне турында ике-өч сүз белән генә: «Ун ел очраштык... Атнага ике тапкыр күрешә идек...



Әйдәгез, аз гына читкә китеп, менә нәрсәне күз алдына китерегез. Сез: «Соңгы вакыт нигәдер җаныма урын тапмыйм, борчу арты борчу... Тынычландыра торган берәр дару язмассызмы?» – дип табибка барасыз, ди. Ә ул... «раскраска» китабы сатып алырга һәм шуны буярга куша. Әйе, әйе, мәктәпкәчә яшьтәге балалар бик яратып буйый торган «раскраска»! Күпләр, мөгаен, аптырап калыр иде. Булмаганны! Югыйсә табибыгыз һич тә «мөгез чыгармый»: гадәти ару-талчыгу, вак-төяк борчулардан «арыну» өчен генә түгел, ә чын психологик тайпылышларны дәвалау өчен дә алар инде күптән рәсем буяу белән шөгыльләнергә тәкъдим итә. Белмәсәгез – белегез менә: олы-олы ир-атлар, хатын-кызлар бүген буш вакытларында җитди кыяфәт белән «раскраска» буйый: Кытайда, Кореяда, Япониядә, Европада... Стресс кагылмаган кеше бармыни хәзер?!

Буяу карандашлары, фломастерлар белән әвәрә килү мөмкинлеге биргән китаплар халыкны шулай күпләп җәлеп итүенә шаккатасы түгел: телефон, ноутбук, компьютер экраннарына көннәр буе карап утырып без инде шулкадәр арган, ялыкканбыз. Барыбызның да күзләренә дә, җаннарына да ял кирәк.

Ялларны, бәйрәмнәрне шуннан бирле яратмыйм», – дигән Надяның киләчәктә бәхетле булачагына безнең исә барыбер ышанасы килә...) Чаңгыда шуу. (Сагындырган! Быел декабрь ахырына кадәр гел яңгыр явып торгач, алар да җәйгә җыеп куйган җирдән әле генә чыкты бит.) Авылга – әниләр, туганнар янына кайтып килү. Чират көтеп яткан китапларны уку. Иркенләп телевизор карау... Аннан, нәрсә генә дисәләр дә, хатын-кыз бу ун көнне барыбер күбрәк почмак якта, аш-су тирәсендә кайнашып уздыра: каникул дип кенә синең өстеңдәге вазыйфалар беркая да китми ләбаса. (Ялның соңгы көннәрендә дус кызым белән бер кечне кафеда утыруны мин, мәсәлән, үземә шуның өчен бирелгән бонус дип кабул итәм. Икәү генә! Ашыкмыйча! «Дүрт сәгать тоташтан ничек сөйләшеп булсын?!» – дип аптырый ирем. «Тагын шуның кадәр вакыт булса да, җитми калыр иде...» – дигән уемны аңа кычкырып әйтеп тормыйм... Ир-ат бу мәсьәләдә безне барыбер аңламый!)

Ел саен бер нәрсә кабатлана дидем дә... Дөрес үк әйтмим бит. Быел ялымның күп өлешендә бер кулымда... кылкаләм, икенчесендә... буяулар булды менә. Картинамны төгәлләдем. Юк, юк, туктагыз: «Картина?!» – дип шаккатырга ашыкмагыз – мин бит «ясадым» димәдем...

Картинаны үземә һәм кечкенә улыма көздән үк алган идек. Күңелдә кайдан мондый теләк туганын, дөресен әйткәндә, инде хәтерләмим дә... Шактый озак сайлаганыбыз истә! Беренчедән, алар зурлыгы белән берберсеннән аерыла. Икенчедән, тематикасы белән. Атаклы рәссамнарның эшләреннән репродукцияләр, табигать күренешләре, төрле чәчәкләрдән композицияләр, фотосурәтләр... Кыскасы, җаның ни тели, күзең кайсына төшә. Ахырда Азат паровоз рәсеменә, мин шәһәр күренешенә тукталдым. Сатучы кыз нигәдер: «Беренче тапкыр гына буярга җыенасызмы?» – дип сорамады. Картиналар, рәсемнең катлаулылыгы ягыннан берничәгә бүленә: мин үзем бу хакта соңрак, буярга утыргач кына белдем: җиңелрәктән башласаң әйбәтрәк, әлбәттә.

Улым кайтуга паровозын буярга да тотынды, ә мин хәтта ачып карарга да шактый гомер узганнан соң гына вакыт таптым. Балаларның «раскраска»ларын хәтерлисезме? Монда да нәкъ шулай: рәсем төрле өлешләргә бүленгән һәм анда саннар куелган. (Әмма өлкәннәр «раскраска»сы күпкә катлаулырак, билгеле. Чынлыкта, күпкә генә түгел, бик күпкә!) Буяу карандашлары яки фломастерлар урынында – чын буяулар! Алар кечкенәкечкенә савытларда, һәрберсенә билгеле бер сан сугылган. Өч төрле кылкаләме дә бар. (Мин алган рәсем катлаулылыгы ягыннан дүртенче дәрәҗәдә булып чыкты: кылкаләмнәрнең иң зурысын кулланмадым да диярлек.)

Кыскасы, каяндыр исемә төште дә, көзен алган шул картинамны Яңа елның беренче көнендә тартып чыгардым. Бер кечне утырып башлап караган идем каравын. Шактый вак, катлаулы эш икәнен дә аңларга өлгергән идем. (Мин бит аның «санлы картина» дип аталуын әйтмәдем әле. Киндергә (яки картонга) сугылган саннарга туры килгән буяулар белән картина буяуны Америкада уйлап тапканнар. Билгеле, моны башта аларда да балалар өчен генә дип чыгарганнар. Әмма еллар үткәч, бу мавыгу өлкәннәргә дә күчкән – бөтен дөньяга таралган. Хәзер шушындый картиналар сату белән шөгыльләнүче интернет-кибетләрнең исәбе-саны да юк әнә! Кытай исә, гомумән, күпләрнең хоббиена әйләнгән бу өлкәне үз кулына алган: моңардан Кояш иленә күпме табыш керүен күз алдына китерү дә кыен.)

Бер сәгать буйыйм, ике, өч... Кызык! Рәхәт! Дөньямны оныттым мин... Иртәгәсен иртүк, өйдәгеләр торганчы тагын буяуларыма тотындым. Көндез дә күңел шунда гына! Буш вакыт чыкканны көтеп кенә торам.

Бу альбомнар стресска каршы чараларның берсе дип санала.

Минем яңа мавыгуыма иң шаккаткан кеше Казан сәнгать училищесында белем алучы студент улым Булат булды бугай. Ул әле генә кышкы сессиясен тапшырды, имтиханнарының берсе, әлбәттә, рәсем иде. «Әнием, шундый җитди кыяфәт белән утырасың! Сине берәү дә мәҗбүр итми ләбаса», – дип аптырады ул. (Җитди булмый хәл юк – контурдан читкә чыгасы килми бит!) Аннан: «Әйдә, сине фотога төшереп, инстаграмга куйыйм әле, рәсем астына сүзен дә уйладым: «Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, дип язам», – дип бәйләнде. Яшьләр инстаграмсыз адым да атламый хәзер. «Кирәкми», – дип баш тарттым. «Арба» дип, әтисе белән үзен атый инде, ике дизайнер янында яшәгәч, буяуга тотынып карарга теләвең табигыйдыр янәсе...

Азат картинаны алуга: «Бу бит фейковый», – диде. Ягъни чын түгел, ясалма. Әмма мин чын-чынлап буярга керешкәч, үзенең паровозын алып, янымда ул да еш кына утыргалады. Куллар эшли, үзебез сөйләшәбез. Улымның сыйныфындагы күпме яңалыкны белдем шул арада, дуслары турындагы мәгълүматка баедым.

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU



2011 елны Шотландия рәссамы Джоанн Бэсфорд бер нәшриятка зурлар өчен «раскраска» бастырып чыгарырга тәкъдим итә. Тегеләре көтмәгәндә ризалашып куя. «Уңышка әллә ни өметем юк иде, – ди Бэсфорд. – Китабымны күп итеп әнием сатып алса гына инде, дип уйладым». Рәссамның «Серле бакча» дигән әлеге беренче китабы бүген инде 1,4 миллион тираж белән таралган! Amazon сайтында ул иң күп сатыла торган китап дип санала. 31 яшьлек рәссам кызның исемен хәзер бөтен дөньяда беләләр. Көньяк Кореяда Ким Ки-бум исемле атаклы җырчылары үзенең инстаграмында (ә аңа 1,8 миллион кеше язылган!): «Сез дә минем кебек Бэсфордның «раскраска»ларын буягыз», – дигәч, илдә чын-чынлап ыгы-зыгы куба – бар да «Серле бакча»ны эзли башлый!

Аралашу җитми шул... Алдагы көнне генә без аның белән Мөхәммәд Мәһдиев китабыннан язучының улы Искәндәр турындагы кечкенә хикәяләрен кычкырып укыган идек. Гаджетларны никадәр яхшы белсәләр, иркен аралашсалар да, эчтә барыбер сабый бала бугай алар: Искәндәрнең авырып, 1 сентябрь көнне беренче сыйныфка мәктәпкә бара алмый калуы турындагы хикәяне Азат тагын искә төшерде, «Шундый жәлләдем мин аны», – ди. Күзләренә хәтта яшь тулды... Күптән түгел җәмгыять белеме дәресендә үзлегеңнән белемеңне күтәрү турында сөйләшкәннәр. «Моның өчен интернетны файдаланырга кирәк», – дигән укытучылары. «Китаплар укырга куштымы соң?» – дим. Балалар: «Ә китап?» – дип сорагач, укытучылары: «Китапларның инде киләчәге юк, булса да, электрон китаплар гына калачак», – дип җавап биргән. Менә шулай...

Буяу балаларны игътибарлырак булырга өйрәтсә, өлкәннәргә тормыштан кечкенә булса да шатлыклар табарга ярдәм итә.

Читкә киттем. Рәсем буяу белән мәшгуль булуымны дус кызларымнан башта Гөлназга гына әйттем. Анда да сак кына, «Юк-бар белән маташып ятасың!» – дип көлмәсме? Ә аның исе дә китмәде. «Минем айфонда да бар андый «раскраска», – диде ул. – Буш вакытта мин дә буйыйм. Нинди төсле буяу кирәген үзем сайлыйм». Минем алда чын буяулар икәнен белгәч: «Кайда саталар андый картиналарны? Алам!» – диде ул.

Аның: «Миңа да шундый «раскраска» кирәк!» – диюе, кыюландырып җибәрде. Дус кызларымның икенчесенә бу хакта инде шактый батыраеп әйттем. «Әле Түбән Камага барган идек. Бер танышларыма кердем – алар син әйткән «раскраска» белән утыра, икенчеләренә сугылдык – анда да шул күренеш... – диде Гөлнара. – Кызым Бану да кызыкты менә. Интернеттан аңа да бер рәсем таптык, инде фломастерлар кирәк». Алай икән...

Юк, фломастерлар белән буяуга караганда, рамга тартылган киндердә, чын буяулар белән картина иҗат итү кызыграктыр. (Мин ялгыш атып, туры китергәнмен: акрил буяулы картина алганмын. Аларны су белән кушарга кирәкми: ачасың да буйый да башлыйсың. Майлы буяу булганда исә башта үзеңә кирәкле төсне эзләп табасың, анысы, әлбәттә, авыррак. Буяуларны ачык калдырырга ярамаганын, кибеп яки куерып киткән очракта, аларга азрак су кушарга мөмкин икәнен рәссам булмасак та беләбез инде. Мин үзем картинаны өлешләп-өлешләп: өстән аска таба буяп төштем. Хәер, анысын кем үзенә ничек җайлы дип табадыр. Бертөсле буяу белән озак эшләмичә икенчесенә күчү ялыкмаска ярдәм итә шикелле – һәрхәлдә, миңа шулай тоелды.)

Бер картинаны буяп чыгу өчен ничә көн, күпме сәгать кирәген әйтә алмам. Каникул азагына чаклы тәмамладым анысы, димәк, ун көн тирәсе җитә. Әмма кайсыбер кичне буяулардан аерыла алмыйча төнге икеләргә кадәр дә утырдым! Юк, бер дә тиз һәм җиңел эш түгел бу. Әмма картинамда йорт, күпер, агачлар, тәрәздәге утларның судагы чагылышы ачыграк күренә, беленә башлаган саен, күңелдә канәгатьлек хисе дә үсә барды. Иҗат тәме шушыдыр ул... Күпләр өчен үз куллары белән нидер булдыру буй җитмәслек хыял кебек тоела. Рәсем ясау сәләте, гомумән, бик сирәкләргә бирелә. Ә монда үз кулларың белән чын картина иҗат итәсең. Өеңдә элеп куя аласың, кемгәдер бүләк тә итәргә була.

Юкны бушка аударып утыргансың дип әйтүчеләр барыбер табылыр анысы. Белгечләр алай дими менә.

Тормыш тоташ стресстан тора хәзер. Күпме генә йөрәгеңә якын алмыйм дисәң дә, җәмгыятьтә булган вакыйгалардан, яңалыклардан читтә калу мөмкин түгел. Рәсем ясау исә безне тынычландыра, баш миебезне ял иттерә, уңай эмоцияләр тудыра.

Рәсем ясау белән шөгыльләнү безне балачакка алып кайта – өстебездә торган йөк-бурычларыбыз күпкә азрак чакка. Димәк, бүгенге борчуларны беразга онытып торуның иң җайлы юлы бу.

Ышанырсызмы-юкмы, әмма рәсем буяу белән мавыгу игътибарны да арттыра, диләр: рәсемегез катлаулырак, сез кулланган буяу төсләре күбрәк булган саен, баш миегез дә яхшырак эшләячәк.

Кулга буяу карандашы, фломастер яки кылкаләм тоту, ягъни вак моторика белән шөгыльләнү балалыктан күптән чыгучыларга да бик кирәк: ул безнең баш миебез өчен үзенә күрә бер күнегү.

...Яңа ел алдыннан «Татарстан–Яңа гасыр»ның «Манзара» тапшыруында бер җырчыбыз турында: «Картиналар иҗат итә башлады», – дип сюжет күрсәттеләр. «Күр, кешедә әллә нинди сәләтләр бар!» – дип, шаккатып карый башлаган идем... Ул да шушы «санлы картина»ларны буйый булып чыкты!.. Картиналар сатучы кыз: «Инде унбишәрне алучылар бар», – дигән иде. Шуның кадәр картина буяганнан соң үзеңне рәссам итеп тоя башлавың да гаҗәп түгелдер анысы. Белмим. Мин әлегә икенче «раскраска»мны гына алырга җыенам. Әмма, күңелем сизә, анысы да соңгысы булмаячак!

РЕДАКЦИЯДӘН: ә сездә нинди мавыгулар бар? Языгыз!



ВАФИНА Зәния

Казан дәүләт университеты, филология факультеты (1993)

Кияүдә, ике кызы бар.

Карьера:
Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм химая бүлеге баш белгече.

Тормыш шигаре:
Чын матурлык йөрәктә яши, күзләрдә чагыла һәм эшләгән эшләрдә күренә.

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Иң мөһиме – тормышым түгәрәк!

Тормыш кыйммәтләре турында һаман-һаман уйламыйсың. Ә бит дөньяда иң зур бәхет – пар канатлы булу. Әнием безнең белән бергә яши.
Ике кызым да үзләре яратып сайлаган һөнәрләре буенча белем ала: олысы Эльвира Казан дәүләт медицина университетында, кечесе Альбина Казан федераль университетының юридик факультетында укый. Яратып сайлаган һөнәрем – тәрбияче, укытучы, үксез, ятим балалар яклаучысы – җир йөзендә иң мәрхәмәтле һөнәр.
Кайда гына эшләсәм дә, ирем Ирек – һәрвакыт таянычым, ярдәмчем, илһам бирүче терәгем.


Баш өстендә түбәләре бар!

Республикабызның ятим балаларга фатир бирү программасын бик хуплап кабул иттек. Дәүләт аларга, ниһаять, йөз белән борылды. Күңелләре китек, җаннары яралы бу балаларның сөенеченә карап ничек шатланмыйсың?! Безнең районда гына да соңгы өч елда 27 ятим Сарманның үзендә һәм якын-тирә шәһәрләрдән фатир алды. Бу – районыбыз җитәкчеләренең «Бөтен яхшылык – балаларга» дигән шигарне тормышка ашыруы да. Минем кебек бик күпләрнең иксез-чиксез хезмәте, йокысыз төннәре, борчулы көннәре...

Ана батырлыгына һәйкәл куярлык!


Кызының рәттән бер-бер артлы өч авыры төшкәч, Техас шәһәрендә яшәүче 54 яшьлек Трейси Томпсон ныклы карарга килә: «Сезгә суррогат әни үзем булам!» – ди ул. Үзенең бала тапканына – 28 ел, ә менопаузасы башланганга 7 ел үткәч! Табиблар, йөкләлек аның исәнлегенә зыян китермәячәк дип табалар. Һәм барысы да, чыннан да, чагыштырмача әйбәт уза. Баланы ярып алганнар. Кызчык өч килограммлы булып туган. «Кызым өчен шушы адымга бара алуым, оныгымны аларга үзем бүләк итүем белән бик бәхетлемен!» – ди Трейси.

сөендерде






көендерде




сөендерде






көендерде



сөендерде



көендерде

Гомер – нибары бер мизгел...

Бергә җыелышларда утырган, аралашкан бер танышым үлеп китте. Икебез бер яшьтә идек. Яман чир... Башка берәү белән бутыйлардыр дип уйладык башта. Алты ай гына авырган, кешегә белгертмәгән. Ире, ике баласы ятим калды. Яңа гына өйләр салып кергәннәр иде. Үзләре өчен яши генә башлаган чаклары... Эш, дөнья мәшәкате дип, кайчак якыннарыбызның хәлен белергә вакыт тапмыйбыз, гаиләгә игътибар, наз, җылылык биреп җиткермибез кебек. Ә гомер шулкадәр кыска – кеше бүген бар, иртәгә юк...

Исереккә диңгез тубыктан...

Чакырып та Яңа ел бәйрәменә килмәгәч, ул гаиләдәге балаларны котларга дип өйләренә барган идек. Ишекне әниләре ачты. Исерек... Ике, дүрт һәм алты яшьлек өч бала ач, ялангач. Бетләп беткәннәр. Әтиләренең кем икәнен өчесенең берсе белми... Әниләре безне кертмәс өчен пычакка кадәр күтәрде. Полиция чакырырга, балаларны хастаханәгә алып китәргә туры килде. Мондый чакларда йөрәкнең ничек әрнегәнен, сабыйларның моңсу карашы үзәкне ничек өзгәнен белсәгез иде?! Әниле, әтиле килеш үксезләр бит алар. Бер гаепсезләр.

Өзүе тиз, ә ялгавы?!

Җан тыныч түгел әле... Гаиләбез белән берничә тапкыр Истанбулда, Төркиянең башка шәһәрләрендә булырга туры килде. Төрек мәдәнияте, тарихы белән якыннан таныштык. Татарстан һәм Төркия арасындагы бәйләнешләрнең нык булуы өчен бар көчен салган Гөлтан Ураллы кебек затларыбыз белән аралаштык. Заманында күпме татар зыялыларын үзенә сыендырган бу дәүләт?! Инде боларның барысын да онытабызмы? Югарыдагыларның уйлап бетерелмәгән сәясәте аркасында тугандаш ике халык арасындагы дуслык бозылырмы? Килешәсе килми!..

PRESSA.RU

АЛСУ ЧҮЛ, ҖИРӘН КЫЯЛАР





Эльза
НӘБИУЛЛИНА

ТУРФИРМАЛАР КИРӘК ТҮГЕЛ БЕЗГӘ. ҮЗ ЮЛЫБЫЗ, ҮЗ МАРШРУТЛАРЫБЫЗ БУЕНЧА ЙӨРЕРГӘ ЯРАТАБЫЗ.

Бер елны Дагстан, Әзәрбайҗан аша Грузиягә барып, аны аркылыга-буйга урадык, аннары Төркиягә барып чыктык. Икенче юлы Таиланд, Индонезия, Австралия... Якын Европа илләре инде безнең өчен ындыр арты кебек кенә тоела.


Юл башы

Петра. Бу серле шәһәр турында бер галим кызыктырып та, мавыктырып та сөйләгән иде. Берничә айдан соң шушы җиргә аяк басармын дип уема да китермәгән идем әле...


Елларыбызны сәяхәттә уздыру инде бездә гадәткә әйләнгән. Без ул – мин һәм ирем Искәндәр. Шундый сәяхәтебезнең берсе турында иркенләбрәк сөйлим әле.

2012 елның җәе иде. Бу юлы икебез дә, никтер, Мисырга тартылдык. Беләм инде, хәзерге заманда Мисыр белән берәүне дә шаккаттырып булмый анысы. Тик безнең очракта бу бераз башкачарак. Турфирмалар аша түгел, үз юлыбыз белән йөрибез бит без! Бу юлы да алдан ук хәстәрен күрә башладык: башта диңгез ярында бераз ял итәрбез, аннары, биштәрләребезне асып, җәяүле сәяхәткә чыгып китәрбез. Юк, бер ил белән генә чикләнмәячәкбез. Якында гына Иордания, Фәләстин, Израиль... Тукта, Петра да шул тирәдәрәк ләбаса!

Петра турында үзем укыган-белгәннәрне, тарих дәреслекләреннән туплаган мәгълүматларны күңелдән барлыйм. Әйе, бу шәһәр бик борынгы. Кыяларны уеп эшләнгән биналарны мин фотодан күреп беләм. Стивен Спилбергның Индиана Джонс турындагы фильмнарының берсен исегезгә төшерегез әле: вакыйгалар нәкъ менә шунда бара! Агата Кристиның «Үлем белән очрашу» әсәрендәге геройлар да шушы тирәләрдә йөргән... Искәндәр тарихтан укып белгәннәрен миңа җиткерә: «...Безнең эрага кадәр якынча VI гасырда Петра Нәбатиләр патшалыгының башкаласы булган. Шәһәргә керү юлы үзе тар, үзе биек кыялар арасыннан узган. Дошман явына күренмәс өчен, халык махсус шундый урынны сайлаган... Безнең эраның 106 елында шәһәр Рим империясенә керә. 663 елгы җир тетрәүдән соң







аның күп өлеше җимерелә. Халык моннан китә башлый. Әкренләп бу урыннар онытыла, истәлекләр дә сакланмый... 1812 елда гына бәдәвиләр яшәгән бу шәһәрне Швейцария сәяхәтчесе өр-яңадан ача!..» Петра хәзер Иорданиянең гаҗәеп истәлекле урыны, музей-тыюлык. Туристлар гел шунда агыла, диләр. Димәк, юлга кузгалыр чак җиткән!

...Хургада, Луксор, Искәндәрия, Каһирә шәһәрләрен аркылыга-буйга гиздек. Алда – Петра. Иң уңай юл Мисыр белән Иордания арасында урнашкан Эйлат шәһәре (Израиль) аша уза икән. Без Каһирәдән Табага (Синай ярымутравында, Мисырның Израиль чигендә урнашкан) бара торган автобуска утырдык. Чикне җәяүләп кичтек. Аннары Эйлатка илтә торган маршрут автобусында шәһәр үзәгенә юл алдык. Эйлат зур шәһәр түгел, бирегә гадәттә диңгез буенда ял итәргә киләләр. Әлегә без монда транзит (узып барышлый) туристлар гына. Озак тукталып тормыйча, Иордания чигенә юнәлдек.

Гарәпчә дә яхшы бел!

Үзлегеңнән сәяхәт иткәндә, еш кына нинди шартларда каласыңны белмисең бит. Шуңа күрә һәр нәрсәгә әзер булырга кирәк. Беренчедән, аяк киемеңең уңайлы булуы шарт. Минем кедалар җайсыз булып чыкты. Җәяү йөреп, аяклар тәмам шешенде, кедалар кыса башлады. Мин аларны салып, чүплеккә атарга әзер идем инде. (Соңрак шулай эшләдем дә!) Уңайлы аяк киемен тиз генә табарга да кирәк бит әле, ә минем аякларга ял бирәсе килә. Эйлаттан узып барышлый гадәти «чәпелдек» сатып алдым, калган юлымны да шуның белән уздым. Кара, йөри-йөри, аркага аскан биштәр дә авырайды бит! Алдагы еллар әйбәт сабак бирде үзе: багажның күләмен киметергә өйрәтте. Иң кирәкле нәрсәләр генә алына, алмашка ике-өч кием – шул җиткән! Шуңа күрә артык нәрсә (сувенирлар, киемсалым, башкасы...) сатып алу урынсыз. Иртәме-соңмы аларны барыбер берәр җирдә калдырасың. Боларына инде йөри-йөри күнектем. Сүз дә юк, ир кешегә күпкә уңайлырак. Әнә, Искәндәр – һаман шул бер футболкадан, бер үк шортыдан... Ярар, юлыбызны дәвам итик.

Эйлаттан Иордания чигенә җәяүләп барганда бер машина туктап, безне утыртты. Шунысы кызык: Израильгә керү – бушлай, чыгу – түләүле. Кеше башына 100 әр шеккельне калдырып, җиңел генә ил чиген кичтек. Аның каруы, Иорданиягә керү визасы 25 доллар тирәсе, ләкин Акаба чиге «аерым икътисадый зона» булу сәбәпле, илгә керү өчен түләү кирәк булмады.

Яңа илләр ачу, дөнья белән танышып йөрү безнең хобби дисәң дә була!

Гадәтләнгәнчә, шәһәргә кадәр тәпи-тәпи генә атламакчы идек тә, бар нәрсә дә без теләгәнчә генә булмый шул әле. Хәрбиләр: «Моннан машинада гына узарга ярый», – дип, такси машинасына утырырга боердылар. 10 минуттан без Кызыл диңгез ярындагы Акаба шәһәрендә идек инде. Иордания бер күрүдә үк ошады. Диңгез – янәшәдә. Су коенып, әлсерәүне баскач, утырып ял иттек. Тирә-якны күзәттек. Миңа кызык: суга ялангач керүчеләр бик аз, күбесе суда чыланып кына чыга. Йөзеп йөрүчеләр бөтенләй күренми. Гарәп илләренең зур бәласе – ул пычраклык. Бирeдә дә ашаганнан калган чүпләрне яр буенда ташлап, комга күмеп калдырганнар. Бөтен яр буе чүпкә баткан. Шулай да, Мисыр белән чагыштырганда, күпкә чистарак монда.

Бераз ял итеп алгач, кабат кузгалдык. Юл чатында озак торырга туры килмәде, Маан шәһәренә бара торган машина безне Вади Мусага таба алып китте. Машина хуҗасы бик ачык кеше булып чыкты, безне сораштырды. Иордания элеккеге Британия колониясе булуына карамастан, илдә инглизчә сөйләшүчеләр күп түгел, шуңа күрә аралашканда кайчандыр мәктәптә, соңыннан үзлектән өйрәнгән гарәп сүзләрен искә төшердем.

PRESSA.RU





«Мөгаллим», «әдәбият», «җәмил» кебек уртак сүзләребезне кулланып, әдәбият укытучысы булуымны, тирәяктагы матурлыкны аңлата алдым кебек.

Абзый безне Вади Мусага илтә торган юл чатында калдырды. Караңгы төшкән, инде ай калыккан. Күз алдында гаҗәеп серле бер күренеш ачыла. Бәхетебезгә, бу юлы да юл буенда озак көтәргә туры килмәде: ике егет бик шатланып безне юлдаш итте. Ярты сәгать дигәндә, еракта, кайдадыр түбәндә утлар күренде. Караңгыда беленми, ләкин машина барышыннан сизелә: без таулы борма юллардан түбән төшеп килә идек. Төшкән саен, вак утлар күбәя, якыная. Күңелне кызыксыну катыш шатлык хисе биләп алды. Без Вади Мусага килеп җиттек!

Хатын-кыз яраткан күлмәк-итәкләр, ялтыравык бизәнчекләр хакында беразга онытып торырга туры килә.

Мәгарәдә

Вади Муса – Петра янәшәсендә урнашкан кечкенә генә шәһәр, биредә халык бер-берсен яхшы белә. Шуңа күрә монда безне кунак итәсе Гасаб исемле егетнең йортын табуы авыр булмады. Юлчыларыбыз безне шушында калдырып, хәерле сәфәр теләп саубуллаштылар.

Гасабның өендә күп сөйләшми торган карт әтиәнисеннән һәм сагыш тулы күзле сеңлесеннән башка беркем юк иде. Алар килүебезгә бер дә шаккатмады. Бары тик без килүне хәбәр итеп, улларына шалтыраттылар. Күңелгә ниндидер шом кереп урнашты. Юк, бу гадәти көн генә булмастыр, ахрысы.

Озак та үтмәде, машинасына утырып, күтәренке кәефле Гасаб үзе дә кайтып җитте. Ул безне күптәнге дуслары кебек: «Хееей! Хәлләрегез ничек?» – дигән сүзләр белән каршы алды. Аның үз-үзен тотышы «Пираты Карибского моря» фильмындагы капитан Джек Воробейны хәтерләтә. Чыннан да, Гасаб бик колоритный кеше булып чыкты, биредә яшәүчеләрдән ул кискен аерыла, инглизчәсе дә шактый саллы. Егет сүзен кыска тотты: «Моннан ерак түгел минем мәгарәм бар. Анда машина белән барып була. Әлбәттә, сез биредә дә кала аласыз, монда душ бар, йокларга уңайлы. Ә мәгарәдә сезнең кебек үк төрле илләрдән килгән тагын җиде кунак бар. Сайлагыз – сезгә ничек ошый?»

Бу тәкъдимгә шикләнеп карадым, ләкин нидер уйлап өлгергәнче, Искәндәр хәл итеп тә куйды: «Әлбәттә, мәгарәгә!» – диде ул.

Гасабның ал төстәге джибына утырып кузгалдык. Юлда барганда ул безгә бу мәгарәнең бабасыннан ук калган булуын, үзенең күп еллар Алман илендә яшәпэшләп, кабат шушы урыннарны, кыргый табигатьне сагынып кайтуын тәмләп сөйләп барды. Тәрәзә аша төрле кыялар, мәчетләр, яссы түбәле өйләр, калкулыклар күренеп калды. 15-20 минуттан без учак ягылган урында идек инде.

Кешеләр төрле шартларга җайлаша. Янәшә урнашкан ике мәгарә әнә: берсе – аш бүлмәсе, икенчесе – йокы бүлмәсе. Мәгарәләр тирәли каралты-кура кебек урын корылган. Ташлардан өеп ясалган баскыч мәгарә өстендәге балконга алып менә.

Учак тирәли утырган халык ниндидер күңелле уен уйный иде. Болар – Фәләстингә волонтер булып килгән Австралия һәм Америка яшьләре, Даниядән килгән апалы-сеңелле сәяхәтчеләр. Хуҗа безгә үлән чәе тәкъдим итте.

Мәгарәнең эче дә бик кызык бизәлгән. Диварда танылган регги башкаручы Боб Марли портреты (Гасабның тышкы кыяфәтеннән чыгып, моны алдан ук көтәргә була иде), төрле корама юрган, мендәрләр.

Чәй эчеп алганнан соң, йокларга урын әзерли башладык. Гасаб безгә юрган һәм матрас атты да, кем кайда йоклый – сайлагыз дигән ишарә ясап, безне үз иркебездә



калдырды. Гаҗәп, әмма бар халык ачык һавага – мәгарә тышындагы төрле урыннарга таралды. Без дә тигезрәк урын сайлап, йокларга яттык. Бераз шүрләтә: ачык һава, кыялар, билгесез урын, кайдадыр этләр өрә. Күккә карагач, бар шик-шөбһәләр онытылды: йолдызлар шундый күп һәм алар бик якын иде.

Менә нинди икән син, Петра!

«Уау! Кара монда ничек матур!» – дигән сүзләргә уянып киттем. Караңгыда берни күренмәгән икән. Кояш чыккач, кыялар тагын да матуррак, тагын да серлерәк күренде. Төркиянең Каппадокиясен хәтерләтсә дә, кыргый табигатьтә бөтенләй башка халәт икән шул! Пейзаж бер үк: кыялар, төпсез зәңгәр гарәп күге.

Һәр иртә намаздан башлана! Сәфәрдә йөргәндә нинди катлаулы шартларда яшәсәң дә, фарыз гамәл турында онытырга ярамый. Алдан әзерләп куйган суларыбыз белән тәһарәтләнеп, намазыбызны укыдык. Ә ул арада Гасаб инде ун кешелек иртәнге ашны да әзерләп куйган! «Good morning, my friends!» дип, киң елмаеп каршылады ул безне.

Көн вакыйгаларга бай булырга охшап тора. Без Петрага барабыз. Тик гади туристлар кебек түгел, ә биредә яшәүчеләр генә белгән кыялар өстеннән узган сукмактан. Гасабның танышы безне машинада Петрага якынрак урынга илтеп куйды. Моннан юлыбызны җәяү дәвам итәчәкбез.

Юлга үзебез белән берничә шешә су алдык. Гасаб аны Вади Мусадан канистр белән ташый. Эссе көнне су күп эчелә, ләкин чаманы да белергә кирәк: чөнки күбрәк эчкән саен, ешрак тирлисең; аннары суның күләме дә чамалы бит.

Тезелешеп Гасабка иярдек, бүген ул – безнең юлбашчыбыз. Өстән бик матур манзара ачыла. Риваять буенча, шушы кыяларның иң биегендә Һарун пәйгамбәр җирләнгән, аның кабере ерактан күренә. Югарыда тормышка башкача карыйсың икән. Уйландыра. Кыяларга яшеренеп утырган алсу шәһәр меңнәрчә еллар элек гөрләп яшәгән бит инде.

...Гадәти юл белән килгән туристлар түбәннән югарыга күтәрелсә, без, урау юллар аша менеп, инде кыялар өстендә идек. Тар гына тарлавыклар. Кыяларның биеклеге 90–100 метр. Ә һава тар зәңгәр тасма булып күренә. Энергетикасы бик көчле бу урыннарның! Каршыбызга очраучы тәмам хәлдән тайган кешеләргә сәлам бирәбез. Бик арыганнары – төрле төстәге җәймәләргә төренгән ишәкләр өстендә. Җирле халык аларны ат, ишәк, дөяләргә утыртып алып менә. Биредә уелып ясалып, яхшы сакланып калган биналар да бар, кайчандыр кешеләр яшәгән вак-вак мәгарәләр дә күренгәли – тулы бер шәһәр. Уңда да, сулда да – тарих. Дөньяның яңа җиде могҗизасыннан берсе шул инде! Төсләр балкышыннан хыял, фантазия уйный. Алсу чүл, кызгылт-җирән, кайчак – шәмәхә, кайчак соры-көрән төскә манылып күренгән кыялар... Аларны әле филгә, әле балыкка, әле чит планета вәкиленә охшатам. Кыяга уелган дөяләр кәрваны шәйләнә. Әллә нинди космик шәһәр бу!

Петраның могҗизалы урыннары белән танышып йөргән арада намаз вакыты җитте. Мәчеткә юл күрсәтүче укны күрдек, баксаң, мәчет тә аерым бер мәгарәдә икән. Идәненә келәмнәр җәелгән, кыйбла юнәлеше күрсәтелгән.

Гасабны без интернет аша каучсерфинг сайтыннан таптык, ул безне кабул итәчәген алдан ук белдереп куйган иде.

Йөри торгач, көн дә үтеп китте. Без Вади Муса ягына җәяүләп, ком өстеннән атладык. Көн буе кояшта йөреп, бик әлсерәгән идек. Яныбыздан ике ишәкле бер бәдәви кардәш узып бара, арыганыбызны күреп, ишәгенә әйдәкләде. Вади Мусага кадәр мин шулай кайттым.

Вади Мусада безгә тагын дүрт алман егете, ике француз кызы кушылды. Шулай итеп, тагын да зуррак төркем белән машинага төялеп, кабат Гасабның мәгарәсенә кайтып киттек. Мәгарәнең тышына чынлап та «Gasap's cave» дигән язу эленгән. Юлда кайтышлый, анда-санда палаткалы лагерьлар күренеп калды. Ә без, алардан аермалы буларак, чын-чынлап табигый мәгарәдә кунак булабыз.

Гасаб һәм аның иордан милли киемле кардәше безгә кичке аш әзерләде. Мәклүбә бөтен кешегә җитте. Әлбәттә, без дә ярдәм иттек. Шешәләргә су тутырып, намазга әзерләнеп йөрүебезне күргән Гасаб гаҗәпләнү катыш соклануын яшермәде. Безгә карап, уйлангандыр, күрәсең. «Без үз өебездә, мөселман илебездә динебезнең кадерен белми яшибез кебек», – диде ул кардәшенә.

Икенче көнне инде без Иордания башкаласы Амманга юл тоттык. Ә бу инде бөтенләй башка сәяхәт, башка җир, башка ачышлар.

PRESSA.RU

16+

БЕЗНЕ... ХАТЫН-КЫЗЛАР САЙЛЫЙ



Исмәгыйль ШӘНГӘРӘЕВ, эшмәкәр. өйләнгән; гаилә стажы — 34 ел; унбер бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребез-не күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Яшең алтмышка якынлашып килгәндә, бу хакта сөйләп утыру бик үк дөрес булмастыр ул. Мәрьям минем икенче хатыным, беренчесе Гөлсем исемле иде. Яман шеш авыруыннан вафат булды ул. Ике балабыз калды... Гөлсем кебек чибәр хатын-кызны башка очратканым юк минем. Аңа күз тигәндер дип уйлыйм, ул чакта башка яулык бәйләп йөрүләр дә юк иде әле. Самара өлкәсенең Гали авылы кызы иде Гөлсем. Алар район үзәгендә – Похвистневода тордылар. Ә мин Оренбург өлкәсенең Богырыслан шәһәрендә тора идем. Безнең аралар 17 чакрым гына. Бер туйда очраштык без. Мин аңа шунда ук гашыйк булдым. Икебез дә яшь идек әле... Аннан менә Мәрьямгә өйләндем. Тагын бер елдан безнең уртак балабыз туды һәм ул 18 яшендә өч бала анасы булды. Улым белән кызым аңа тиз ияләштеләр, Мәрьямгә «әни» дип эндәшә башлаулары шуңа күрә беркемне шаккатырмады. Вафатына кадәр – 86 яшькәчә әни дә Мәрьям тәрбиясендә булды.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Хыянәттән кала, барлык сыйфатларын да гафу итәргә буладыр. Дөрес, ир-атлар арасында хыянәтне кичерүчеләр дә бар. Әмма мин бит үзем өчен җавап бирәм.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручылар...

– Миңа боларның икесе дә якын, икесе дә кирәк... Мәрьям белән еш кына икәү утырып хыялланабыз, киләчәккә планнар төзибез. Гаиләсендә бик күркәм тәрбия алган минем Мәрьям: ир кешене – атаны зурлау аның канына сеңгән. Хатын-кызның иң зур вазыйфасы – бала табу, иргә, гаиләгә хезмәт итү дип саный ул. Бер-беребезгә терәк булмасак, тормышыбызны бүгенгедәй бөтен, түгәрәк, бәрәкәтле итә алыр идекме икән?! Мәскәү үзәгендә коттеджыбыз бар. Хәзер менә Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә яшибез. Кунакханә, ресторан тотабыз. Аллаһы Тәгалә: «Хәрәкәт кылыгыз», – дигән бит. Кайбер хатын-кызлар: «Башта укыйм, карьера төзим, аннары бала табармын», – дип яши һәм... күп вакыт әни булырга соңга кала. Болай чиратка салсаң, чыннан да, бер гомер җитми. Ә Мәрьямнең бер сүзе бар аның: «Берьюлы берничә эш башкарырга кирәк», – ди ул. Балаларыбызны да шуңа өйрәтә. (Сүз уңаеннан, безнең җиде оныгыбыз бар – Мәрьям инде әби. Ә аның әле үз әбисе дә исән!)

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Хатын – хатын урынында инде ул... Дуслыкның мәгънәсе дә, эчтәлеге дә башка аның. Кайчак егет белән кыз авызыннан: «Без дуслар гына», дигән сүзне ишетәсең. Мин андый чакта гел уйлыйм: «Әллә читләрне алдыйлар болар, әллә үз-үзләрен?!» Теләсәгез нәрсә диегез, әмма мин мондый дуслыкка ышанып бетмим!

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Гөлсемне соңгы юлга озаткан идек инде... Бөгелмәдән хәл белергә дусларым килде. Мин бу вакытта өйдә түгел идем. Кайтып керсәм, бер яшь кенә кыз бала өйдә эшләп йөри: тузаннар сөртә, савыт-саба юа... Мәрьям булып чыкты ул. Аның безнең өйдә үз кеше булып йөрүе миңа шунда ук ошады. (Без балаларыбызны да шулай өйрәтәбез: кунакка баргач, олыраклары – инде башлы-күзле булганнары гына олылар янына утырып, сүзгә кушыла ала. Ә яшьрәкләр, һичшиксез, хуҗаларга ярдәм итәргә тиеш). Ислам дине буенча, тол калган ир кулында балалар бар икән, ул кабат өйләнә ала, моның өчен нииндидер бер вакыт узганын көтәргә кирәкми. Мин дә үгезне мөгезеннән тоттым: «Әти-әнисеннән Мәрьямнең кулын сорар идем», – дидем. «Ташкентка барырга кирәк булачак», – диделәр. Мин инде бу вакыт шактый билгеле кеше идем. Казаннан Мәрьямнең әбисе Рәшидә абыстайны, бабасы Гомәрне алып Ташкентка очтык. Август ае иде бу. 20 сентябрь көнне Мәрьямгә 17 яшь тулды, ә икенче көнне без никах укыттык.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Бик дөрес сүз бу! Алай гына түгел, кызлар да әтиләренә охшаган егетне сайлый. «Булачак ирем синең кебек булсын иде, әти!» – дигән сүзне үземнекеләрдән дә ишеттем. «Юк, алар миннән күпкә әйбәтрәк булырга тиеш!» – дидем гел. Улларым да әниләрен эталон дип саный. Ә Мәрьямне мин Гөлсемгә охшатып якын иттем...

7 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Чынлыкта, алар башлап белдерә дә! Без үзебезне сайлаган хатын-кызны гына сайлыйбыз... Гашыйк булуны белдерү – сүз белән генә әйтү түгел бит ул. Мәсәлән, Мәрьям мине елмаеп каршы алды – мин шуннан барысын да аңладым. Әгәр аның ягыннан бернинди җылылык сизмәсәм, сүз дәшәргә җөрьәт итәр идемме икән?! Без, ир-атлар, әллә кем булып йөрсәк тә, бу мәсьәләдә күңелебез бик нечкә. «Юк», дигән җавап ишетүне бик авыр кичерәбез. Ә хатын-кыз ир-атка бер генә күз сала да: «Мин аның булачак балаларымның әтисе булуын телимме-юкмы?» – дип хәл дә итеп куя...

Бүгенге ир-егетләрнең күбесе инфантиль. Гаиләдәге тәрбия шулай ясый аларны: күреп торалар бит – өйдә әниләре хуҗа. Шуңа күрә хатын-кызның, килеп, үзләрен җитәкләп китүен көтеп утыралар да. Ислам дине буенча инициатива күбрәк кызның әти-әнисе ягында булырга тиеш. Ир-ат кырыкта да өйләнә ала, ә кыз баланың вакыты уза... Башлы-күзле булыр вакыты җиткән егетне өйгә кунакка чакыруның бер ояты юк: өйдәге чисталыкны күрсен, аш-суны авыз итсен... Болар, аңлаган кешегә, елмаеп караудан күбрәкне сөйли.

8 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип санйсыз?

– Кемне нәрсәдер... Мин үзем ир-ат, беренче чиратта, иманлы булырга тиеш дип саныйм. Иманлы, намазлы ир-егет хатынын кыерсытмый, кимсетми, ул аны зурлый, кадерли. Балаларына чын әти булырга тырыша. Ә өрлектәй буй-сын, чибәрлеккә килгәндә... «Манара да озын буйлы, шуннан ни файда?» – дия иде безнең әти.

9 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Әйткәнемчә, миңа тиздән алтмыш тула инде. Әмма үземне карт итеп сизмим, йөрәк тә һаман унсигездә! Хатынымның: «Син әле һаман егетләр кебек яшь, көчле», – дип әйтүен көтәм. Мине шулай гына канатландырып була!

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Анысы бар... Чибәрлек булган җирдә, аңа ия булу, үзеңнеке итү теләге – ярыш бар бит, шуңа куркытадыр.

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигәнәкъ менә шулай эшләгәнен, үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Ир-ат күлмәге белән хатын-кыз блузкасының якасы икесе ике төрле үтүкләнә бит. Ә Мәрьям болар арасында аерма күрми! Дөресрәге, ул минем күлмәк якаларын да блузканыкы кебек үтүкли. Никадәр күлмәгемне бозды шулай! «Стрелка»ны дөрес салмыйча ничәмә-ничә чалбарымны кимәслек ясаганын әйтмим дә... Аңлый алмыйм: ул чыннан да ничек үтүкләргә икәнен белмиме, әллә...

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Без милек сату белән шөгыльләнәбез. Дизайнерларыбыз клиентларга ремонт белән дә булыша. Яңа хуҗаларын кабул итәргә әзер булган шундый фатирларның берсенә кердем дә, тәрәз пәрдәләрен күреп аптырап киттем: бер дә туры килми. Хуҗабикә: «Ирем шулай теләде», – дип җавап бирде... Мин дә өйдә кайчак үз фикеремне әйткәлим. Ләкин бу: «Мин кушканча эшләгез», – дигән сүз түгел. Йорт эченә кирәк-ярак, кием-салым, ризык алу, балаларны мәктәпкә озату-каршы алу – барысы да Мәрьям өстендә. (Авырсынмый ул! Аңардагы энергия! Йорт эчендәге җиһазларның урынын ай саен бер алыштырып тормаса, күңеле булмый.) Кыскасы, аның – үз фронты, минеке – үземнеке. Вак-төяккә кысылсаң, башка, зуррак эшләрне башкарырга өлгермисең. Вакытым була икән, балалар белән уйныйм. Иң яраткан шөгылем шул.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Хатын-кызның өйдә тавык чүпләп бетермәслек эшен иң рәхмәтсез эшләрнең берсе дип саныйм. Йортның зур булса, бер яктан җыеп чыкканчы, икенче яктан кабат туза башлый бит ул... Әгәр хатыны вак-төяк эшләргә чумып, үзе турында бөтенләй оныта икән, моңа ире гаепле! Аның чибәр булып калуы, үз-үзен гел үстерүе, шөгыльләре, кызыксынулары күп булуы хатын-кызның үзе өчен генә түгел, ире өчен дә кирәк. Балаларга үрнәк була алу өчен кирәк... Мәрьям, миңа кияүгә чыккач, югары белем алды.

Ә өйдә беркайчан ач булмам дип уйлыйм. Беренчедән, Мәрьямнең булышчылары бар. Икенчедән, минем бит беренче һөнәрем – аш-су остасы. Үзем дә яхшы пешерәм. Дөрес, бу минем өчен хәзер күбрәк хобби гына. Үз рестораныбыз булса да, көндезгә ашка һәрвакыт өйгә кайтам. Якыннарым белән аралашу өчен тагын бер мөмкинлек бит.

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Мәрьям турында түгел бу сүзләр! Әйткәнемчә, ул бик җитез, өлгер: балаларны да киендерә, шул арада үзе дә әзер була. Мин исә пошмасрак кеше. Күп нәрсәгә елмаеп карыйм.

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Мәрьямнең миңа иң зур бүләге – балалар!

PRESSA.RU

Корама япма тегәргә күптәннән кызыга идек. Аның белән ныклап торып шөгыльләнүче чын осталарга да мөрәҗәгать итеп карадык. Ахыр чиктә, тәвәккәлләп, корама тегәргә үзебез алындык. Дөресен генә әйткәндә, бик катлаулы эш түгел ул, бераз вакыт кына кирәк тә, тукыма кисәкләрен төсе белән бер-берсенә яраштыра белергә генә кирәк. Корама тегү өчен ситсы, бәз кебек табигый тукымалар яхшы. Алар шумый, кырыйлары тиз генә сыпылмый, юарга да ансат. Корамадан япмалар гына түгел, юрган, мендәр тышлары да, хәтта киемнәр дә тегәләр. Без бүген балалар кәнәфие өчен тәгаенләнгән кечерәк япма тегәбез. Димәк, башлыйбыз.



Мастер-классны Лилия ГӘРӘЕВА үткәрә.



КОРАМА ДИП КАРАМА

Кирәк:

- иңе – 150 см, буе 24 см булган дүрт төрле тукыма. (Өске ягы тузган күлмәк итәкләре яки уртасы тузган матур урын-җир җәймәләрен дә кулланырга мөмкин. Гадәттә, аларның чит-читләре әле таза була);
- иңе 150 см булган ике төрле тукыма. Берсенең буе – 21 см, икенчесенеке 28 см (болары кайма кисү өчен);
- буе – 160, иңе 90 см зурлыгындагы бер катлы синтепон;
- япманың аскы ягын тегү өчен иңе – 90 см, буе 160 см булган тукыма;
- тегү җебе;
- үрнәк кисү өчен катыргы кисәге.

Әзер япманың буе – 158 см, иңе – 86 см.






Эш барышы:

■ катыргы кисәгеннән 12х12 см зурлыгындагы шакмак кисеп алабыз. Ул безгә тукымаларны шакмаклап кисү өчен кирәк, чөнки линейка белән үлчәп утыру күп вакытны ала. Тукыманы бер катлап, сул ягын өскә каратып өстәлгә салабыз да, өстеннән катыргы кисәген куеп, гади карандаш белән эз төшерәбез. Шушы эздән тукыманы кисәбез. Кибетләрдә моның өчен махсус пычак та сатыла.

■ Әлегә өч төрле тукыманы гына кулланабыз. Тукымаларның төсе дә, бизәге дә бер-берсен ачып, тулыландырып торырга тиеш. Гел караңгы төсләрдән генә торган япма күзне иркәләмәс, тукымалар ачык җете төсле булса, матур. Тукыма кисәкләре бер-берсенә зигзаг җөй белән ялгана. Корама пөхтә килеп чыгуның тагын бер сере – үтүк кул астында гына торсын. Теккән һәр җөйне үтүкләп куябыз.








Урта өлеш:

■ ул 22 шакмактан һәм 20 өчпочмактан тегелгән. Башта икешәр шакмакны бер-берсе белән тоташтырабыз. Аннары шул турыпочмаклыкларны үзара тоташтыргач, зур бер шакмак хасил була. Аны ромб рәвешендә кыйгачлап салабыз.

■ Шуңа башка шакмакларны ялгыйбыз. Аскы һәм өске якта, читчиттәге шакмак араларына өчпочмаклар тегелә *(өченче рәсем)*. Нәтиҗәдә, иңе 33 см, буе 128 см булган турыпочмаклык килеп чыга.

Кырый өлеш:

■ Дүрт төрле тукымадан 12x12 см зурлыгында сигезәр шакмак кисәбез. Аларны диагональ буенча ике өчпочмакка бүләбез. Төрле тукымадан киселгән дүрт өчпочмакны бергә тоташтырып, 16 зур шакмак тегәбез. Теккәндә игътибарлы булырга кирәк, өчпочмаклар бер тәртиптә генә ялгана. Шакмакның зурлыгы – 16x16 см.

■ Сигез шакмакны горизонталь буенча тегеп тоташтырабыз – киң генә тасма килеп чыга. Калган сигез шакмактан икенче тасманы тегәбез. Бу тасмалар урта өлешнең ике читенә ялгана.

■ Әлегә кагылмыйбыз дигән тукыманың берсеннән иңе – 7 см, озынлыгы 71 см булган ике тасма теләбез (кисәргә тотынганчы, үзегезнең япманы үлчәп, озынлыгын тәгаенләгез, чөнки без биргән үлчәм туры килеп бетмәскә мөмкин). Тасмаларны япманың башбашларына тегеп куябыз.

■ Шул ук тукымадан киңлеге янә 7 см, озынлыгы 131 см булган ике тасма кисеп, аларны япманың ике читенә тоташтырабыз. Икенче тукымадан да шундый ук 4 тасма кисәргә кирәк. Аларның да киңлеге 7 см булса, икесенең озынлыгы – 85 см, калган икесенеке – 142 см. Бу тасмалар да япманың читчитләренә тегеп куела.

■ Хәзер инде япма зурлыгында синтепон һәм тоташ тукымадан аслык кисик. Аслыкның үлчәме дә япма зурлыгына тәңгәл.

Җыю тәртибе түбәндәгечә: аслыкны уң ягы белән өскә каратып, идәнгә җәеп салабыз. Аның өстенә сул ягын өскә каратып, корама япманы салабыз (алар бер-берсенә уң яклары белән капланган, соңгы рәсемдә ачык күренә).

■ Корама өстеннән синтепонны түшибез. Тегү энәсенә җеп саплап, өч катын да япма кырыйлатып бергә типчеп чыгабыз. Аннары шул эздән машина белән җөй салабыз. Җөйне аслык ягыннан салырга кирәк, синтепон өстеннән җөй салуы кыен.

■ Япманы уң ягына әйләндерү өчен аскы итәктә бер араны текми калдырабыз. Соңыннан аны белендерми генә кулдан тегеп куябыз.

■ Ахырдан япманы яхшылап үтүклибез.

PRESSA.RU

ЧҮЛМӘКТӘГЕ ГӨМБӘ АШЫ



«Йолдызлы» мастер-классны Татарстанның халык артисты Венера ШАКИРОВА дәвам итә.
Иҗат юлын Г. Камал театрында Н. Исәнбәтнең «Зифа» спектаклендәге Эсмеральда роле белән башлап җибәргән Венера ханым театр сөючеләргә Фәүзиясе (М. Гыйләҗев, «Казан егетләре»), Зөләйхасы (Ш. Хөсәенов, «Әни килде»), Саҗидәсе (З. Хәким, «Килә ява, килә ява»), Зөлкагыйдәсе (Т. Гыйззәт, «Кыю кызлар»), Ак Бүресе (Ч. Айтматов, «Ахырзаман») аша яхшы таныш.
35 елдан артык гомерен театрга багышлаган артистка әле бүген дә сәхнәдә — И. Зәйнинең «Бабайлар чуагы», Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр» спектакльләрендә уйный. Иң зур хыялы — алга таба да театрдан аерылмау, тагын да кызыклырак рольләр башкару. Аш-су турында сүз кузгаткач, шаяртып: «Әле ундүрт яшемдә макарон да пешереп ашый белми идем. Ашарга пешерергә ирем Рәниф өйрәтте (Петров Рәниф Андреевич, Г. Камал театрының директор урынбасары — *ред.*)», — дисә дә, бүген инде Венера ханым теләсә кайсы тәмлетамакның күңеленә хуш килерлек ризыклар әзерли белә. Ул пешереп күрсәткән гөмбә ашын сез дә әзерләп карагыз әле. Шундый тәмле-е-е!



Кирәк:
(дүрт кешелек гаилә өчен)

- 200–250 г шампиньон гөмбәсе;
- 200 мл сөт өсте (20% майлылыктагысы);
- 300 г йомшак сыр;
- 1 баш суган;
- 1 баш сарымсак;
- 30 г атланмай;
- 250 г ак шәраб (шәраб урынына без 1 бал кашыгы алма серкәсе кушылган ак йөзем суты салдык);
- 400 г катлы камыр;
- 0,5 л су;
- ак борыч (ул булмаса, башкасы да ярый);
- 1-2 бал кашыгы он;
- төменчә тоз.









Фото: Ксения Богданова

Эш барышы:

■ Ваклап туралган суган белән сарымсакны атланмайда кыздырып алабыз. Суган үтәкүренмәлегә әйләнә башлагач, туралган гөмбәне кушабыз. Бер-ике гөмбәне турамый калдырырга кирәк булыр, алары – ашны бизәү өчен. Гөмбә кызган вакытта онны да салып, яхшылап болгатабыз. Он ашны куерту өчен кирәк, аны салу мәҗбүри түгел.

■ Кәстрүлдә су кайнатып, шәрабны өстибез (без исә серкәле йөзем суты салдык), аннары сыр куштык. Гөмбә тәме килгән сыр алсаң, аш тәмлерәк була. Кашык белән болгата-болгата, сырны эретеп бетерәбез.

■ Сырлы шулпага сөт өстен салып, табадагы гөмбәне кушабыз. Тәменчә тоз сибәбез. Бераз кайнаганнан соң, кәстрүлне уттан алып, гөмбәле шулпаны блендер белән сыек ботка хәленә китерәбез.

■ Хәзер бу шулпаны балчык чүлмәкләргә бүлеп салабыз. Аш өстенә юка телемләп туралган гөмбә салып чыгабыз.

■ Катлы камырны җебетеп, чүлмәк авызыннан бераз зуррак шакмакларга кисәбез. Һәр шакмакны уклау белән тәгәрәтеп җәеп, чүлмәк авызына каплыйбыз. Чит-читләрен яхшылап бөрергә кирәк, аш өстенә килеп төшәрлек булмасын.

■ Гөмбәле чүлмәкләрне 200 градуска кадәр кыздырылган мичкә тыгып, 15-20 минут чамасы пешерәбез. Камырның йөзе килгәч, аш әзер була. Табынга ашны чүлмәгендә килеш чыгаралар. Теләгән кеше борыч сибә. Ашларыгыз тәмле булсын!

Бәйге



Мин — Гөлүсә Батталова. Ирем Алмаз белән Әтнә районы Күәм авылында яшибез. Кызыбыз Диләрәгә — 8, улыбыз Аязга 2 яшь. Бәйгедә катнашу өчен нинди ризык әзерләргә икән, дип, озак баш ваттым. Яңа еллар артта калды, ә бәйрәмнәр гел булып тора! Туганнар, дусларның очрашу-күрешүләре шашлыктан башка узамыни безнең заманда?! Әтиемнән өйрәнгән, үзем бик яратып әзерләгән шашлык рецепты белән уртаклашыйм әле! Аның тагын бер сере бар — итне кыздырганда тимер таяклар урынына ирем тал чыбыклары да куллана. Болай тагын да тәмлерәк кебек.

Эш барышы:

3 тавыкны эре булмаган кисәкләргә турыйбыз, 1 аш кашыгын өеп тоз салабыз, боҗралап туралган 5-6 баш суган, ваклап туралган ярты лимон кушабыз. 3 тырнак сарымсак белән 2 учма укроп та турап салабыз. Карлыган, кура җиләге яфраклары өстибез (кыш көне кипкәнен кулланабыз).

Соус:

0,5 стакан аш яки алма серкәсе, 2 аш кашыгы томат пастасы, 1/3 чәй кашыгы аджика, 0,5 чәй кашыгы кара борыч, кибетләрдә сатыла торган бер кап шашлык тәмләткече. Шушыларны бергә кушып, аз-азлап кына ит өстенә салабыз, шәпләп болгатабыз һәм 1 тәүлеккә маринадланырга куябыз.

PRESSA.RU



БУЫННАР СЫЗЛЫЙ. НИШЛӘРГӘ?

Ревматоидлы артритны дәвалап булмый торган чирләр исәбенә кертсәләр дә, дәвалауның яңа ысулларын куллану куандырырлык нәтиҗәләр бирә. Йөрәк һәм кан тамырлары, яман шеш авыруларының нинди хәтәр чир булуын белгәнгәме, без инде бу чирләргә каршы көрәшергә, шундый диагноз белән яшәргә өйрәнеп киләбез. Ә менә ревматоидлы артритның кеше язмышы белән рәхимсез уйнавын, дөресен әйткәндә, белми дә идем әле.

Мәдинә
КАШАПОВА

Казан шәһәренең 7 нче клиник хастаханәсендә «Ревматоидлы артрит. Хатын-кыз. Җәмгыять» дип исемләнгән түгәрәк өстәл янындагы сөйләшүдән соң күп нәрсәгә күз ачылды. Сөйләшүгә җыелган хатын-кызларның барысы да Ревматология һәм остеопороз үзәге пациентлары булып чыкты. Ерак араны якын итеп, авырту-сызлануларына карамый, кайсы инвалид коляскасында, кайсы таякка таянып, кайлардан гына килмәгәннәр: Алабуга, Яшел Үзән, Әлмәт, Казан... хәтта Йошкар-Ола шәһәреннән дә бар. Әйе, чит регионнан килүчене дә кабул итәләр биредә. Авыру сиңа ышанып, өметләнеп шулкадәр җир килсен дә! Ә бит еш кына андыйлар өчен бер адым атлавы да зур сынау.

Шулай да... Нәрсә соң ул ревматоидлы артрит? Ни өчен без аннан сагаерга, беренче билгеләре күренүгә үк белгечкә йөгерергә тиеш? Сузмаска, тартмаска, соңгы көнгә калдырмаска?! Гәрчә бу хакта язганыбыз булса да, әлеге мәкерле яман чир турында тагын бер кисәтүнең артыгы булмас.

Мәскәү кунагы – профессор Андрей Гордеев, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Социаль мәсьәләләр комитеты рәисе Светлана Захарова, 7 нче клиника хастаханәсенең баш табибы Марат Садыйков, хастаханәнең хирургия, травматология, ортопедия бүлекләре җитәкчеләре, танылган хирурглары катнашында башланып киткән әлеге очрашуда Ревматология һәм остеопороз үзәге җитәкчесе, Татарстанның атказанган табибы Равия Мухина: «Ревматоидлы артрит белән җәфаланучы хатын-кызларның 72 проценты сызланып яши. Аларның күбесе сызлануны баса торган дару эчә, бертуктаусыз эмоциональ тетрәнү кичерә. Бу – безнең социаль пробле-

ма да, – дип башлады сүзен. – Пациентларыбызның бер үк вакытта әни дә, актив җәмәгать эшлеклесе дә, кемнеңдер сөекле хатыны булуын да онытмыйк. Сораштырулар вакытында хатын-кызларның 40 проценты шушы чир аркасында үзенә иптәш таба алмавын әйтә. 22 проценты аерылышуларының төп сәбәбе итеп чирен атый. Кызганычка каршы, буыннар сызлаудан күбрәк хатын-кызлар интегә.

Мәскәү кунагы бу чирне тикмәгә генә «сөрелмәгән җир» белән чагыштырмагандыр. Белгечләр аның сәбәбен бүгенге көнгәчә ачыклап бетерә алмыйлар. Ревматоидлы артрит вакытында организм үз күзәнәкләренә үзе һөҗүм итә башлый. Нигә бу чир кайсыбер кешедә яшен тизлеге белән кузгала соң? Бүген бу сорауга берәү дә анык кына җавап бирә алмас иде. Иммун системасы үз организмына әнә шулай «бәйләнә» торгач, ялкынсыну барлыкка килә, дип аңлата табиблар. Ул буыннарның күзәнәкләренә һәм тукымаларына үтеп кереп, кешене түзә алмаслык сызлануларга дучар итә.

Чирне нәрсә уята, нәрсә «котырта»?

Әйткәнебезчә, буыннар сызлауның сәбәбе билгесез булса да, аңа «ярдәм итүче» факторлар җитәрлек. Әйтик, аның геннан килүе; төрле йогышлы авырулар нәтиҗәсе; психик һәм эмоциональ кичерешләр, авыр физик эшләр, организмга химик тәэсирләр, нурланыш, агулы матдәләр эләгү... Остеопорозлы кешеләр дә әлеге чирдән ерак йөрми. Безгә артритны аздыра торган шушы тискәре күренешләрдән сакланырга кирәк, диләр. Профессор Андрей Гордеев билгеләп үткәнчә, ни өчен нәкъ менә хатын-кыз бу очракта аутоиммун мишеньгә әйләнә? Чөнки аның бу дөньяда миссиясе, бер уйласаң, ирләрнекенә караганда күбрәк тә, олырак та. Бала тапканнан соң, хатын-кыз организмындагы үзгәрешләр, иртә климакс (45 яшькә кадәр) башлану, бөтен нәрсәне йөрәгеңә якын алу берсе дә файдага түгел. Чир аның сәламәтлегенә җитди зыян салып кына калмый, ә бәлки, психологик хәленә һәм социаль статусына да тискәре йогынты ясый.

Шушындый диагнозлы кешенең гомере 10–15 елга кыскара. Ул соңгы сулышынача дәваланырга мәҗбүр була. Һәм, әйтергә кирәк, сызлануларны киметеп яшәү, бары аның үзеннән тора. Әгәр дә инде авыру, буыннарда үзгәрешләр башланып, хәрәкәтләнә алмас хәлдә кала икән, ул чагында аңа ярдәмгә хирурглар, травматологлар, ортопедлар килә. Ул көнне дә залда утыручылар арасында икешәрөчәр мәртәбә операция өстәленә яткан пациентлар бар иде. «Табиблар ярдәме белән генә аякта басып торабыз, үзебезне үзебез йөртәбез», – ди алар.

Тагын бер мөһимнән-мөһим нәрсәгә игътибар итик: ул да булса, тәмәкенең зарары... Тәмәке тарткан хатын-кызда инфекция организмга сидек юллары аша үтеп керә һәм буыннарны зарарлый. Кайда гадәт, ә кайда чир, диярсең... Белгечләр фикеренчә, ревматоидлы артрит озак еллар тәмәке тарткан кешедә ешрак була һәм андый пациентны дәвалау авыррак бара. Төз, чандыр гәүдәле булуның да үзенә бер хикмәте бар икән. «Иң беренче булып әнә шул сылу ханымнар авырый башлый да инде, – ди профессор. – «Дюймовочка» булырга омтылмагыз!» – дип тә кисәтә ул безне, шаярткандай итеп.

Ничек башлана?

Ревматоидлы артрит төрле кешедә төрлечә башлана. Кемнедер ул көтмәгәндә аяктан ега. Ә кемдер аның ревматоидлы артрит икәнен белми дә. Ник дисәң, билгеләре бөтенләй икенче була. Күп очракта чир буыннан-буынга күчеп, көчле авыртулар белән дәвам итә. Хәл бераз җиңеләеп торган вакытлар (ремиссия) да булгалый.

Чирнең алга таба үзен ничек күрсәтәчәген, үзен ничек «тотачагын» алдан фаразлап булмый. Хәлне җиңеләйтүнең бердәнбер чарасы – вакытында диагноз куеп, шундук дәвалый башлау. Очрашуга килгән кунаклар – Ревматология һәм остеопороз үзәгенең даими пациентлары, әлеге зур һәм дус гаиләнең кадерле кунаклары да шул турыда сөйләп тора ич әнә.

Туктап калмаска!

Сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле бу кыз өчен яшәүнең һәр мизгеле кадерле, һәр мизгеле елга торырлык. Артритсыз – сызлану-авыртынуларсыз яшәүнең ни икәнен белми дә ул. «Башка тормышны күргәнем булмады», – дигәндә, йөрәк кысылып куя. Юк, кызганудан димим. Ул үзен кызгандырмый. Аның бу дөньяда үзен өзелгән яфрактай түгел, ә бәлки, иң кирәкле кеше итеп хис итә алуыннан... Өч яшеннән шушы чир ятьмәсенә эләгеп, хәтта урын өстендә калган чакларында да ул укуын ташламаган. Казан финанс-икътисад институтына укырга кергән. Тик менә ул баскычлардан менүләре генә... Йөрүләре мең газапка әверелгәч, читтән торып укый башлаган.

Ул арада оча һәм бот сөягенә дүрт операция ясаткан. Урынга калган җирдән аягына баскан. Көндезгегә күчеп, укуын тәмамлаган. Бухгалтер булып, белгечлеге буенча эшкә урнашкан. Әйтүе генә ансат: хәзер аның 27 ел эш стажы бар! Таисия Козько-

ТЕСТ

Түбәндәге сорауларның берничәсенә «әйе» дип җавап бирәсез икән, ул чагында сезгә, кичекмәстән, табиб-ревматологка күренергә киңәш итәбез:

- Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк буын авырта.
- Буыннар, капшап караганда, җылы тоела.
- Ялкынсыну нәтиҗәсендә салкын тиюгә яисә гриппка охшашлы билгеләр барлыкка килә.
- Иртәнге якларда кул буыннары йөрми, богауланган шикелле.
- Артык арып киткән сыман – ниндидер бер хәлсезлек.
- Авырлыгыңны югалтасың, ябыгасың.
- Тире астында, терсәктә, кулларда, үкчәдә төеннәр барлыкка килә.

PRESSA.RU

ва 2014 елны «Татарстан энҗеләре» дип исемләнгән республика бәйгесендә җиңүче булган. Ул – Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының җәмәгать ярдәмчесе.

«Минем икенче чирем»

– Иммун системасы белән бәйле мондый чир хакында ишеткәнем дә юк иде әле, – дип сөйли Айгөл Исмәгыйлева. – Артымнан кара шәл булып сөйрәлеп йөрүче бер хәсрәтем – церебраль параличым бар иде инде минем. Инде менә... монысы. Авырту бөтен җанымны-тәнемне биләп алгач, моңарчы коточкыч тоелган церебраль паралич онытылды. Артритның миңа гомерлеккә тагылуын белгәч, дөресен әйтим, яшисем килмәде. Үлсәм, яхшырак дидем.

Аннан шушы үзәккә килдем, табиблар белән таныштым. Алар мине тормышка кайтардылар. Өр-яңадан яшәргә өйрәттеләр. Хәзер мин бөтенләй икенче кеше: үземне күбрәк яратам дип әйтимме. Кемнең ничек каравы да кызыксындырмый мине. Бер сүз белән әйткәндә, ДЦП минем өчен проблема булудан туктады. Чөнки чирнең тагын да зәһәррәге эләктереп алды.

Озак вакытлар депрессиядә булдым. Аннары аңладым: чир беркая китмәячәк, тормыш дәвам итә. Минем гаиләм, ирем, җан атып торган әнием бар, авыр чакларда таяныч булырдай ак халатлы фәрештәләрем бар.

«Чигәм, рәсем ясыйм, телләр өйрәнәм»

– Тормышым тоташ сызланулардан тора, – дип сөйли Инна Храмова. – Кәефемне кешегә күрсәтмәскә, йөземә чыгармаска тырышам. Төрле кеше бар: кайсы кызгана, ә кайсы, үзегез беләсез... Шулай да, бирешмим, булган бар мөмкинлекләрдән файдаланырга тырышам: институтны кызыл дипломга тәмамладым. Ике белгечлек алып чыктым. Мине үзем укыган институтка француз теле укытырга чакырдылар. Эшемне, һөнәремне бик яратам. Бүген мин – техник фәннәр кандидаты һәм чит телләр кафедрасы доценты. Бүгенге көн белән яшим. Сәяхәт итәргә яратам. Бик күп җирләрдә, шул исәптән Франциядә дә булдым. Чигәм, рәсемнәр ясыйм, кайчак шигырьләр дә язгалыйм һәм... телләр өйрәнәм. Гел хәрәкәттә, гел үсештә булырга кирәклеген күңелем белән тоям.

Ничек дәваланырга?

- Рецептсыз җибәрелә торган бигүк көчле булмаган дарулар;
- Стероид булмаган ялкынсынуга каршы препаратлар (артрит вакытында авыртуны басар һәм шешне бетерер өчен);
- Буыннар таркалуын әкренәйтү өчен препаратлар;
- Вакытлыча гына һәм бәләкәй дозада буыннарның шешен бетерү өчен глюкокортикоидлар да кулланырга була;
- Шешне һәм сызлануларны киметү, буыннарның зарарлануын булдырмый калу өчен генно-инженер биологик препаратлардан файдаланалар. Гадәттә, әлеге дәваны башка дарулар булышмаган очракта билгеләлиләр. Ул кемгәдер берничә көннән, йә берничә атнадан, ә кемгәдер 3-6 айдан соң ярдәм итә. Дәвалау барышы бары тик ревматологларның, участок терапевтларының җитди күзәтүе астында алып барылырга тиеш.

– Иртә диагностика технологиясе кертүнең халыкара тәҗрибәсе һәм шул тәҗрибәне кулланып, ревматик авыруларны дәвалау, вакытлыча эшкә сәләтлелекне югалтуны ике мәртәбә диярлек киметергә мөмкинлек бирде, – ди Равия Гаязовна. – Илдәге вазгыятьне искә алганда, безгә дә бу мөмкинлектән файдаланырга, проблеманы шул рәвешле гамәлгә ашырырга кирәклеге көн кебек ачык.

Җитәкченең тел төбе аңлашыла. Үзәктә янә бер бүлек – чирне башланып кына килгәндә белеп ала торган иртә диагностика бүлеге кирәклеге турында чаң кага ул. Аны ишеттеләр һәм бу юнәлештә эшли дә башладылар инде. Бүген югары технологияле дәвалау ысулларын куллану өчен хөкүмәттән (100 очракка) акча бүлеп бирелде.

Элек ревматоидлы артритны дәвалап булмый диләр иде. Соңгы елларда бу чирне дәвалауда шактый ук алга китеш сизелә. Әлбәттә, бирегә нәтиҗәле, алдынгы ысуллар, әйткәнебезчә, халыкара тәҗрибә, камил технологияләр ярдәмгә килә. Безнең белгечләр аларның һәркайсын кулланып карау, һичьюгы пациентның хәлен җиңеләйтү өчен барын да эшләргә әзер үзе...

ЕЛМАЮ ДА ДӘВА

* * *

Бер хатын икенчесенә: «Кичә ирем белән гомеремдә бер тапкыр балыкка бардым. Анда да талашып, кычкырышып кайттык». – «Нигә тагын?» – «Башта кычкырып сөйләшеп бөтен балыкны качырып бетердем. Аннары кармакка җимне дөрес эләктермәгәнмен. Аннан кармак җебен чуалттым. Ә иң яманы – мин тоткан балык иремнекеннән күбрәк булып чыкты».

* * *

Бер ир китап кибетендә: «Хатын-кызны буйсындыручы ир» дигән китап бармы сездә?» Сатучы, илтифатсыз гына: «Почмактагы «Фантастика» бүлегендә булса гына...»

* * *

Әбисе, оныгын йоклатырга теләп, бишек җыры көйли. Бер сәгать көйли, ике сәгать, өч... Ахырдан тәмам арып, теле аңкавына ябышкач, көйләүдән туктый. Оныгы күзләрен ачып: «Дәү әни, хәзер йокласам ярыймы инде, ә?» – ди.

* * *

Бензин заправкасына коточкыч гөрелдәп өйрәнчек машина килеп туктый. Руль артындагы кыз, ашыгып:

– Тулы бак һәм тизрәк!

– Бер генә минут! Башта моторыңны сүндер!

– Мин аны сүндердем... Инструктор шулай калтырый!


КУЧКАР. Ниндидер мөһим адымнар ясамый торуыгыз яхшырак. Әлегә бар да үз җаена бара торсын. Бик күп яңалыклар ишетерсез, ләкин аларның барысы да дөрес дип уйламагыз. Үз-үзегезне кулда тотарга туры килгән чаклар күп булыр.


ҮГЕЗБОЗАУ. Ниятләрегез бик тиз генә тормышка ашар кебек тоелса да, бераз көтәргә туры килер. Уйламаган кешеләрнең ярдәменә юлыгырсыз. Кызыклы идеяләрегезне бераүгә дә белгертми торыгыз. Яңа эшкә керешер өчен әлегә кулай вакыт түгел.


ИГЕЗӘКЛӘР. Әллә кайчаннан бирле күңелегезне бимазалап торган эшләрне җайлы гына башкарып куя торган ай. Бу форсатны кулдан ычкындырмагыз. Сәләтегезне, талантыгызны ачу мөмкинлеге дә булыр. Яңа эш тәкъдим итү ихтималы зур.


КЫСЛА. Тормышыгызны үзгәртү өчен бик шәп мөмкинлек килеп чыгачак. Карьера баскычыннан югарырак менү ихтималы да юк түгел, тырышлыгыгызны күреп алачаклар. Күп теләкләрегез тормышка ашар.


АРЫСЛАН. Күп кенә эшләрдә игътибарыгыз җитеп бетмәве ихтимал. Башкаларның вазыйфаларын да сезгә йөкләмәкчеләр. Шунлыктан, үзара аңлашылмаучылыклар килеп чыгарга мөмкин. Бәхәсләрдән, низаглардан ерак торырга тырышыгыз, алар сезнең файдага булмас.


СӨМБЕЛӘ. Мәшәкатьләр җиңел генә хәл ителер. Күптән борчыган сорауга җавап табарсыз. Йолдызбагарлар башкаларның фикеренә колак салырга куша. Мөһим карар кабул иткәнче, бик ышанычлы кеше белән киңәшләшеп алсагыз, отарсыз.


БИЗМӘН. Мөһим карарлар кабул итәргә туры килер. Үзегезнең чынлап та нәрсә теләгәнегезне ачыкларга тырышыгыз. Көтелмәгән вакыйгаларга таруыгыз ихтимал. Гаиләгездә бәхет хөкем сөрә, моңарчы тоймаган җылылык тоярсыз.


ЧАЯН. Үзегезне үзегез танымассыз. Моңарчы үз сүзләрендә нык торган «чаян»нар һәркемгә юл куярга омтылыр. Әлегә яңа эшләр башламый торыгыз, башкарып чыгуы катлаулы булыр. Ялгызларның гомерлек мәхәббәтләрен очрату ихтималы гаять зур.


УКЧЫ. Вакыйгаларны үзгәртергә омтылуыгыз үзегезгә зыян гына китерер. Күзәтүче ролендә генә булыгыз. Күңелегезгә рәхәтлек бирә торган эш белән мәшгуль булырга тырышыгыз – көтелмәгән уңышка ирешерсез.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Дөньяга карашыгызны үзгәртеп җибәрердәй мөһим хәбәр ишетерсез. Бер генә нәрсәнең дә тиктомалдан булмавына иманырсыз. Айның уннарыннан соң күңел күзегез ачылып китәр. Тәвәккәлрәк булудан курыкмагыз.


СУКОЯР. Катлаулы булмаса да, үзегез өчен көтелмәгән берәр вакыйгага тару ихтималы бар. Моңа артык игътибар итмәгез, ди йолдызбагарлар, аның сезгә зыяны тимәячәк. Яңа эш тәкъдим итәргә мөмкиннәр. Кабул итсәгез, отарсыз.


БАЛЫК. Уңышлы ай булырга тиеш. Үзегезгә җаваплылык алудан курыкмагыз – мөмкинлекләрегезне раслар өчен моннан да яхшырак форсат тагын кайчан була әле. Теләсә кайсы омтылышыгыз уңышлы тәгаллләнәчәк.

Гыйнварда кабынган йолдызлар

Татарстан



Эльмира Хамматова (11.01.1946) – **Татарстанның халык, РФ атказанган артисты, профессор.**
Казанда туа, татар мәктәбендә белем ала. Кечкенәдән хорга йөри. Казанда телевидение ачылу аның тормышында мөһим роль уйный. Режиссер Гали Хөсәенов белән театр белгече Халит Кумысниковлар аларның мәктәбенә килеп, тапшыру алып бару өчен балалар җыялар. Ягымлы тавышлы Эльмираны «Пионерстан» тапшыруын алып бару өчен сайлыйлар. Шушы тапшырудан аның илһамлы иҗат юлы башлана. Театр училищесында укыганда ук аны телевидениегә эшкә чакыралар. Ул алып барган «Яшьлек», «Замандаш», «Йолдызлар чакыра», 1999 елда аның урынына чыга башлаган «Йолдызда тудыңмы әллә?» тапшыруларын тамашачы хәтерлидер әле.

Россия



Вера Глаголева (31.01.1956) – **Россиянең атказанган һәм халык артисты, режиссер.**
Мәскәүдә туа. Кечкенәдән спорт белән шөгыльләнә. Спорт мастеры. Кино сәнгатенә кереп китүе очраклылык аркасында гына. 1974 елда аны «На край света» фильмын төшерүчеләр күреп ала. Фильмнан соң актрисаның һөнәре генә түгел, тормыш юлы да үзгәрә: фильмның режиссеры Родион Нахапетовка кияүгә чыга. Актерлык белеме булмаса да, ире аңа үзе төшергән күп кенә фильмнарда төп рольләрне тапшыра: «Враги», «Не стреляйте белых лебедей», «О тебе»... Иң зур уңышны «Выйти замуж за капитана» (1983) фильмыннан соң казана. «Одна война» фильмында ул үзен режиссер сыйфатында да сынап карады.

Чит илләр



Дайан Китон ((5.01.1946) – **актриса, продюсер һәм режиссер.**
Американың Лос-Анджелес шәһәрендә, дүрт балалы гаиләдә туа. Мәктәпне тәмамлап, драма сәнгате көллиятенә укырга керә. Актерлык карьерасы артыннан куып, аны тәмамламый кала. Дөньяга таныткан эше – «Энни Холл» комедиясе (1972). Бу фильмда башкарган роле өчен «Оскар», «Алтын глобус» һәм BAFTA премияләренә лаек була. Америкадан читтә яшәүче тамашачыларга иң элек «Крестный отец» трилогиясе һәм режиссер Вуди Ален фильмнары аша таныш. 1969 елда «Волосы» дигән атаклы мюзиклда катнашып, тәүге тапкыр сәхнәгә чыга. «Комната Марвина», «Любовь по правилам и без» фильмнарында да уйнап уңыш казана.

PRESSA.RU







ИҖАТ ИРЕГЕ

Ул балачактан буяу исен яратып, рәссам әтисе киңәшләрен күңеленә сеңдереп үскән. Карандашны ничек тотарга, арымас өчен, беләк белән түгел, кулны беләзектән генә кыймылдатып эшләргә кирәген кем аңлатыр иде югыйсә. Соңрак шул ук киңәшләрне ул сәнгать осталарыннан да ишетә, һәм алар онытылмаслык булып күңелгә кереп кала. Ринат Анимаев дигән талантлы рәссам иҗатында болар һәммәсе бик мөһим. Таҗикстанның Дүшәмбе шәһәрендәге сәнгать училищесы да, андагы искиткеч педагогларның дәресләре дә, В. И. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сәнгать институтында уку еллары да... 1986 елда СССР Рәссамнар берлегенә кабул ителә. 1989 елда инде Франциягә үк китеп бара... Франция рәссамнар берлеге әгъзасы, Монмартрның Почетлы гражданины, картиналары – Пьер Карден салоннарында эленеп тора. Хәер, табигый талант, тырышлыктан башка гына андый югарылыкка ирешеп тә булмас иде. Күргәзмәләре, күр, Мәскәүдә, Парижда, Мюнхенда, Амстердамда уңыш казана!

Ринат Анимаев иҗатында портрет сәнгате аерым урын алып тора. Мин портретлар язарга яратам, бу эшне бөтен җанымны салып башкарам. Портрет ясаучы кешенең холкын аңлый һәм шуны ача, шәхеснең күпкырлы якларын, эчке матурлыгын чагылдыра белергә тиеш. Аның җаны бар! Кызыксыз кешеләр булмый! Портретта ямьсез йөзләр юк!» «Ни өчен һаман портретлар язасыз?» – дип сораучыларга Ринат әнә шулай дип җавап бирә. Күп атаклы галимнәр, язучылар, артистлар, дипломатлар – Ринат Анимаев геройлары. Лев Гумилев, Равил Бохараев, Рудольф Нуриев, Владимир Высоцкий, Людмила Гурченко, Александр Солженицын... Барысы да Анимаевның кылкаләме һәм буяулары аша «уза». Портретын язганда, Солженицын теләмичә генә позага баса. Шуңа да карамастан, язучының портреты иң уңышлылардан булып чыга. Владимир Высоцкий эш барышында рәссам белән һаман шаяртып сөйләшә: «Син мине яса, ә мин синең өчен җырлыйм», – ди. Рудольф Нуриев портреты исә атаклы балет йолдызы инде авырый башлагач, 1991 елның җәендә языла. «Карашы каядыр бушлыкка төбәлгән иде. Соңгы портреты булыр дип башыма да китермәдем», – дип искә төшерә рәссам.


Төньяк-көнбатыш Франциянең Бретань пейзажы Ринат Анимаев иҗатында шулай ук зур урын алып тора. Андагы табигать «Диңгез пейзажы» сериясе картиналарын язарга илһамландыра. Рәссам – талантлы маринист остаханәсендәге бәләкәй үлчәмле киндер тукымаларда «диңгез шаулый, дулкыннар чайкала»...

Ул чәчәкләргә, табигатькә гашыйк җан да әле!

«Тормышны рәсемгә төшерәсең дә, аны кечкенә чемоданыңа салып остаханәгә алып кайтасың, яңадан кабат табигатьтәге төсләр, яктылык гармониясеннән таң каласың... Бәхет – шул инде ул! Бер-берсенә охшаган көннәр дә, бер үк төрле кояш та, җил дә булмый... Хисләрне аңлап, тоеп кына белдереп була. Шунсыз алар киндергә күчмәячәк. Рәссам дөньясы – иҗат иреге ул! Һәм ул ирекне бернигә дә алыштырып булмый! Без алсу таң атканны, шәфәкъ кызыллыгын күрәбез, чәчәкләргә карап хозурланабыз, кояш нурларында уйнаган чык бөртекләренә сокланабыз, табигатьтәге төсләр балкышыннан биһуш калабыз...»

Ринат Анимаев үзенең истәлекләрендә шулай яза. Аның белән килешмәү мөмкин түгел.

Лия ПРОНЭР.
Париж.











Эшләпәдә — кызыл карлыган.
Әтием Мансур Анимаев портреты.

Кар өстендә күләгәләр.
Абу портреты.
Муллык эшләпәсе.
Яңалыклар.
Сары сливалар.

РИНАТ АНИМАЕВ

PRESSA.RU



2016 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

(һиҗри буенча 1437—1438 еллар)

8 апрель — мөселман календарендә изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаж, гомрә хажы кылына.

14, 15 апрель — Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич — Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

3, 4 май — Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә — Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

21 май — Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

21, 22 май — Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтүл-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәлләре һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

6 июнь — изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн.

1 июль — Кадер кичәсе.

5 июль — Гайдел-фитыр көннәре. Ураза гаете.

11 сентябрь — Гарәфә көне. Хаж кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

12 сентябрь — Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә.

13, 14, 15 сентябрь — Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап, махсус догалар укыла.

2 октябрь — 1438 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн.

Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына. Бу көнне Аллаһы Тәгалә игелек кылган кешеләрнең гөнаһларын ярлыкар, савапларын арттырыр.

11 октябрь — Гашура бәйрәме. Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләрә хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәен (626—680) җәзалап үтерелгән көнне изге вә хөрмәтле санап, ураза тоткан.

11, 12 декабрь — Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе — Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, сәдака (зәкят) өләшенә.

Төзүче — Хаҗи Абдулла ДУБИН.